PRESSA.RU

1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН



2016 АВГУСТ № 8

СӨЮМБИКӘ

ISSN 0869-1398

«ӘТИ, БЕЗ СИНЕҢ БЕЛӘН ТУГАН!»

гадәти булмаган гаилә

АККОШ КАНАТ КАГЫНА

Маринкада – татар кызы

ЛӘЙЛӘ ГАФФАРОВА СЫЙЛЫЙ:

тансыкка – томат ашы

Рузилә ҺАДИУЛЛИНА:

ИГЕНЧЕНЕҢ УҢГАНЛЫГЫ КЫРЛАРЫННАН КҮРЕНӘ...



PRESSA.RU



БЕРГӘ ЧАКТА... Бу мизгелләр күп тә түгелдер, бәлки — атналарны тыгызлаган бетмәс-төкәнмәс эш, мәшәкать ыгы-зыгысында гаилә белән үткәргән бәхетле минутлар һаман сирәгәя, кыскара барадыр. Әмма аларның һәрберсе кадерле, һәркайсы безгә тормышның ямен-тәмен тоеп яшәрлек көч, җан җылысы бирәдер. Бу тансык вакытны һәркем үзенчә үткәрә – алар мәгънәле, күңелле, онытылмас якты булсын өчен әллә ни кирәкми дә кебек...





ҖӘЙ КИТЕРГӘН СӨЕНЕЧ

Сәгъдәтшиннар гаиләсе


Казан

Татарстан китап нәшрияты директоры Илдар Сәгъдәтшин гаиләсендә кышкы озын кичләрдә... китап укып ял итәләр. Үзе дә, хатыны Гүзәл дә, 9 яшьлек кызлары Илсинә дә, хәтта бер яшьлек уллары Сәлим дә (әнисе инде аны матур рәсемле әкият китаплары белән таныштыра башлады!) китап ярата. Үз йортлары белән яшәгәч, кышын да, җәен дә эш бетеп тормый. «Шөгыль төрләндерү үзе ял инде. Бакчада бәрәңге казу да, чүп утау да, яшелчәләргә сулар сибү дә, чәчәкләр үстерү дә... Бездән күреп, балалар да эшкә өйрәнеп үсә», — ди гаилә башлыгы. Елларда гаилә белән театр-концертларга баралар. Җәй чыкканда шәһәрләр, илләр күреп йөрергә яраталар. Балык тоту, җиләккә йөрү, су коену, йөзү — болары җәй китергән сөенечләр. Илдар үзе — шәп балыкчы. Гүзәлнең һәр минуты нәни Сәлимгә багышланган. Бала йоклаган арада ул мең эшкә өлгерә: чиясен, карлыганын җыя, компотын яба, кыяр-помидор тозлый. Алар урамында 19 бала яши икән — Илсинә көннәр буе шулар белән әвәрә килә. Әтисе аны, яратып, «су кызы» дип йөртә. Хикмәте шул: Илсинә йөзәргә ярата. Сәгъдәтшиннар өчен иң рәхәте — Идел буенда ял итү.













Ә сез БЕРГӘ ЧАКТАниләр эшлисез, сезнең гаиләнә нинди эш-гамәлләр, үзенчәлекле бәйрәмнәр, берәүдә дә кабатланмый торган, әмма башкаларга да үрнәк булырдай матур йолалар берләштерә? Яңа фотопроектыбыз шундый мизгелләрне яктыртуга багышланган.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2016

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электронное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.



Директор-баш мљхђррир
Ләйсән Рәфикъ кызы ЮНЫСОВА

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нәбирә Гыйматдинова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Айрат Сибагатуллин, Иркия Төхвәтуллина, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Эльвира Әхмәтова.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77
Директор урынбасары
Рәмзия Кашапова 222-09-78
Баш мөхәррир урынбасары
Гөлнур Хәсәншина 222-09-78
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова

Сайт мөхәррире:
Сөмбел Гаффарова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Дизайн-макет:
«ASAFIN GROUP»
Верстка:
Лариса Маликова

Тышлыкта:
Рузиля Һадиуллина
Фото: Ксения Богданова

Бүлек мөхәррирләре:
Мәдинә Авзалова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Асия Юнысова
Фәнзилә Мостафина
Фотокорреспондент
Ксения Богданова
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Ленар Хәкимов

Формат: 225х290 мм.
Күләме 64 бит.

Басарга кул куелды: 4.08.2016 ел.
Заказ М-1918.
Тираж 6148.

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77
Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
р/с 40702810700000005657
к/с 30101810100000000815
в ПАО «Татфондбанк» г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205815
КПП 165802002



PRESSA.RU

30 АВГУСТ — ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КӨНЕ

Гамил АФЗАЛ

Ватаным Татарстан

Татарстан, күңелләргә өмет тулып,
Бәйрәмеңдә котлыйм сине улың булып,
Көлеп торган чәчәкләрдән букет сузып,
Сиңа, илем, иң мөкатдәс гөлләрем бар.

Җанга сеңгән кызыл колны куып чыгар, –
Түрә булып утырмасын узгынчылар,
Бәхет теләп иссен җилләр, аксын сулар,
Кулың алтын, җитмеш төрле
һөнәрең бар.

Туган илем, җанга якын булганда син,
Суык түгел кышкы җилең, бураның да.
Чәчәк тулы болыннарың уйларымда,
Сахраларда сөеп искән җилләрең бар.

Туган ягым, чирәм үскән урамыңда
Гармун уйнап, таңга чаклы урадым да,
Шөкер, дидем, шушы җирдә туганыма,
Күреп туймас таңнарыңны күргәнем бар.

Туган илем, алга таба юллар ачык,
Ярышларда иң алдынгы мәйданга чык,
Тату илләр арасында горур басып,
Бәйгеләрдә байрак тотар көннәрең бар.

Ата-баба гомер иткән яшел урам,
Билне буып, ил күрергә юлга чыгам,
Татарстан, байрагыңа хәер-догам,
Шатлык тулы, иман тулы йөрәгем бар.





Фото: Алмаз Закиров

Асия ЮНЫСОВА

Ипекәй

Алла сүзе кебек күп исемле:
Ашлык, иген, икмәк, ипекәй!
Аш сүзеннән күчкән ант сүзенә –
Ант иткәннәр тотып ипекәй.

Урак урган татар хатыннары,
Бәбәй йөрткән килеш карында.
Иген урган урак кендек бавын
Ничә кискән арыш кырында!

«Солы урагында таптым сине,
Апаң туды борчак чапканда», –
Икмәк календаре белән көне,
Ашлык гены халкым канында.

Ә ул генда тук башаклар шавы,
Калач йөзле көләч таңнар бар.
Ил тамагын уйлап кырда куна
Арыш урагында туганнар.

Кемдер анда кылыч кайраганда –
Саллы корал, димәк, дәлилгә –
Татар хатыннары яңа оннан
Камыр изә икмәк-хәләлгә.

«Ипекәй!» – дип илдә ант иткәндә,
Йөзе якты, сүзе хикмәтле.
Башка дәлил аңа кирәк түгел,
Татарстан кулы икмәкле!

PRESSA.RU



БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА





12 ШУШЫ ҖИРДӘ ҖЫРЫМ КАЛСЫН
Л. Гәрәева

ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ





8 ГЕОЛОГ
Г. Хәсәншина

ТАТАР ДӨНЬЯСЫ





20 АКТАНЫШ ДИГӘН ИЛ БАР...
Э. Закирова, Ф. Мостафина



16 ЗӨЛФИЯ РӘҮПОВА: «ҖЫР ЯЗУ – ҖАН РӘХӘТЕ УЛ»
М. Сәфәров



24 «ЯРАТЫП ТУЙМЫЙЧА КИТӘБЕЗ...»
Г. Сафиуллина

ЭЧТӘЛЕК

МӘДӘНИ ТОРМЫШ





30 АККОШ КАНАТ КАГЫНА
Л. Әбүдәрова

ЯШӘЕШ





40 «ӘТИ, БЕЗ БИТ БАРЫБЕР ТУГАН!»
Г. Хәсәншина



50 АНДА ТАҢНАР ЯКТЫРАК
Э. Нәбиуллина

ШУЛАЙ УК:



36 ӘЧКЕЛТЕМ ШОКОЛАД
Э. Садыйкова

46 АСЫЛБИКӘ
М. Авзалова

ХАТЫН-КЫЗ ГАЛӘМЕ





58 ТАНСЫККА — ТОМАТ АШЫ

КИЛӘСЕ САНЫБЫЗДА:



ТУЙЛАР: ХЫЯЛ ҺӘМ ЧЫНБАРЛЫК. ГАМИЛ НУР

БЕЗНЕҢ КӘЕФ ХАТЫН-КЫЗГА БӘЙЛӘНГӘН...

СӘЛАМӘТЛЕК ТЕЛИМ МИН СИҢА. БЕР ҖЫР ТАРИХЫ

ЯШЬ ҖЫРЧЫ АЗАТ АБИТОВТАН МАСТЕР-КЛАСС



PRESSA.RU

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!



Бүген мин кайнанам турында язарга булдым. Мактап язарга. Горурланып. Сөенеп. Яратып. Ул моңа лаек.

Мин, ун еллык килен стажы булган кеше, бу юлларны язарга, кайнанам турында бер-ике авыз сүз әйтергә үземне хаклы дип саныйм. Юк, минем Әнкәй заманында әллә нинди постлар биләгән эшлекле ханым да, танылган шәхес тә түгел. Гап-гади авылда яшәүче, гап-гади татар хатын-кызы, татар әбисе ул. Әллә кайларда түгел, үзебезнең Әтнәдә, үзебезнең Күәм авылында гына яши. Чишмәле Сап авылында туып, 17 яшендә Мәхмүт әткәйгә кияүгә килгән дә, төшкән урынында таш булган: колхозда эшләгән, балалар үстергән, дөнья көткән Һиндия Хәбибулла кызы Батталова. Исеме дә үзе кебек ягымлы аның. Дөресен әйткәндә, Әнкәйнең мине кат-кат уйландырган, гаҗәпләнеп-сокландырган сыйфатлары бихисап.

Шуларның берсе – аның дингә мөнәсәбәте. Кайнанам үз гомерендә дин сабаклары алмаган, мәдрәсә тәмамламаган, әмма аның көндәлендәге Аллаһка ихлас мәхәббәте, тәкъвалыгы, дин кануннарын төгәл үтәве күпләргә үрнәк итеп куярлык. Шәһәрбану әбисе, Гарифәбану әнисе бишектән үк сеңдергән иман нуры, дин нигезләре Әнкәйне гомере буе озата бара. Бик дини булган аның әнисе. Ачлыктан тилмергән авыр елларда да, кайчак сәхәрдә бер йотым су эчеп, уразасын тоткан, дүрт кызына да үзенең белгәнен, үзенең инанганын бөртекләп өйрәтеп калдырган. Әнкәй балачагын менә ничек искә төшерә: «Ризыкның бик кадерле еллары. Әнкәй миңа, кызым, иртәгә уразага керсәң, сәхәргә йомырка пешереп бирермен, дип әйтә. Мин, шул йомыркага кызыгып, ураза тотарга ризалашам». Менә кайдан килә ул 75 яшьлек Әнкәйгә әле бүген дә бер көн калдырмый ураза тотуы, биш вакыт намазын төгәл үтәве. Аңа бит ул әнисенең күкрәк сөте белән кергән! Соңгы вакытта традицион ислам дигән төшенчә еш яңгырый. Иң кызыгы, дөресрәге, иң кызганычы, әлифне таяк дип тә белмәүчеләр авыз суы корыта әлеге гыйбарә белән. Минемчә, традицион ислам – буыннан-буынга, нәселдән-нәселгә күчкән, гаиләнең яшәү рәвешенә әйләнгән дини кануннар булырга тиеш бит инде. Нәкъ безнең Әнкәй мисалындагыча.

Мине тагын гаҗәпкә калдырганы – Әнкәйнең мәгърифәткә мөнәсәбәте. Кайнанам белән кайнатам биш бала тәрбияләп үстергәннәр һәм аларның бишесенә дә югары белем биргәннәр. Җиде класс белемле, гомере буе үз авылыннан читкә чыгып йөрмәгән Әнкәй балалары мәсьәләсендә әнә шундый зирәклек күрсәткән. Әнкәйнең бүген ике кызы медик, ике кызы журналист, улы физик-радиотехник. Һәркайсы тормышта үз урынын тапкан кешеләр. Кайнанам өчен моннан да зуррак бәхет юк дөньяда.

Әнкәйнең ризыкка, аш-суга мөнәсәбәте дә үзенчәлекле. Әйтеп узганымча, ул бик дини. Әнә шуңадыр, кайнанам исрафчылыкка нык каршы. Бер валчык икмәк, бер кабым ризык әрәм булу Әнкәйнең бәгырен кисә, кайгыга сала. Мин дә аннан сакчыллыкка өйрәнәм. Шунысы куанычлы, әлеге сыйфат Әнкәй тәрбиясе белән балаларыбызга да күчә бара. Кайнанам аш-суга да бик оста. Аның пешергән өчпочмак-гөбәдияләрен бер авыз иткән кеше гомер онытмый. Әмма зирәк татар хатыны булган Әнкәй аш-су әзерләүне тулысы белән миңа тапшырды. Нәрсә генә пешерсәм дә, ни генә әзерләсәм дә, хисапсыз тәмле булган бу, дип, мактап туялмый. Рәхмәт аңа. Әйе, нәрсәгә тотынсам, шуны пешерә алырлык тәҗрибәле килен инде мин, тик шулай да әле һаман Әнкәйдән өйрәнәм. Борынгыча әзерләнгән балан катыгы, корт, кабартма... Күбесен дәфтәремә теркәп куям. Онытылмасын! Аның киңәше, хәер-фатихасы белән әзерләнгән ризыклар тәмле дә, бәрәкәтле дә була. Әнкәй беркайчан кеше гайбәтенә кермәс, урам сүзен җыярга капкадан да атлап чыкмас. Үз тормышы, үз дөньясында кайнаган, кешенекенә кызыкмас, башкалардан көнләшүне белмәс зат ул. Матди байлыкка җаннарны сатарга әзер бүгенге заманда кайнанам күңелен әнә шулай саф килеш саклап яши белә. Балаларыбызны бар җан җылысын, йөрәгенең яктысын биреп тәрбияләшә. Чыгып китсәк, өебезгә йозак эләсе юк, кайтып керсәк, чәй кайнаган, балалар караулы. Безгә хәер-дога теләүче, өебезнең нуры булып яшәүче Әнкәйгә, җырдагыча, кояш гомере телим. Дөнья бәһасе торырлык, гаиләм, балалар дип җан атып яшәүче иремнең Әнисе бит ул!

Гөлүсә БАТТАЛОВА.
Әтнә районы, Күәм авылы.

Гомер-гомергә укырга да, язарга да бик яраттым. Үзебезнең Минзәлә районының «Яңарыш» газетасында төрле мәкаләләрем еш басыла.

Шуның бер санында Минзәләдә 3 ел бер парта артына утырып белем алган курсташым Һиндия турында да язмам басылып чыккан иде. Шуннан соң озак та үтми, мине аның ире Әхнәф эзләп тапты. Һиндиянең вафаты турында ишеткән булсам да, тормышларының бөтен нечкәлекләрен белми идем.

Һиндия дә, Әхнәф тә икесе бер көнне дөньяга килгәннәр икән. Һиндия Әхнәфне армиядән дә көтеп алган. Өч елдан өйләнешкәннәр. Тату гаиләдә бер-бер артлы кызлары һәм уллары туган. Бәхетләре бер көн эчендә чәлпәрәмә килә аларның. Сукыр эчәгесенә ясалган уңышсыз операциядән соң 1972 елда – 8 яшьлек Резидәсен, 5 яшьлек Илфагын ятим калдырып, бакыйлыкка күчә курсташым. Соңгы сүзе «балаларым» була. Иренә: «Син, Әхнәф, гомереңне ялгыз кичерә алмассың. Алладан да, синнән дә шуны үтенәм: балаларны ятим итмә. Миңа охшаган юлдаш табарга тырыш», – ди.

Ходай Тәгалә ишеткәнме, язмышына шулай язылганмы, Һиндияне җирләп ике ел узгач, ул Ижауга күчеп килә. Мотозаводка шофер булып эшкә урнаша. Шунда Зөлфияне очрата. Бер күрүдә ошата аны Әхнәф. Бергә яши башлаганчы, Зөлфияне балалар белән таныштырырга карар кыла. Инде монысын Зөлфия үзе сөйли: «Таныштык. Йокларга җыенабыз. Резидә белән Илфак, икесе ике ягымнан кочаклап, миңа сыендылар. «Син безнең әни бул әле», – диләр. Шулай, кочаклашып, өчәү бергә йоклап киткәнбез. Башта бик курыктым. Ул вакытта миңа инде 39 яшь булса да, бала тәрбияләүдә тәҗрибәм юк бит».

Аның үз язмышы да бик гыйбрәтле булган. Ул Актаныш районы Әтәс авылы кызы. Әтисе сугыштан әйләнеп кайтмаган. Әнисе дүрт баланы ялгызы үстергән. Зөлфия 19 яшендә Мотозаводта эшли башлаган. 20 яшендә кияүгә чыккан. Ире «Ижсталь» заводында тимерче булып эшләгән. Бик тырыш кеше булган. 13 ел бергә яшәп, яңа йорт җиткерәләр. Зөлфияләр ишеген дә кайгы көтмәгәндә шакый: үзе эшли торган озын саплы кыскыч аның башына бәрә. Коткарып кала алмыйлар, баш сөяге, чәрдәкләнеп, миенә кадалган була. «Ичмаса, балабыз да булмады бит», – дип сыктап, биш ел ялгызы гомер итә Зөлфия. Аннары Әхнәф белән танышып, ике сыңар канат бер пар булып яшәп китәләр.

«Аллага шөкер, шул ике баланы башлы-күзле итеп, шуларга сөенеп яшибез. Зарлана алмыйбыз, балаларыбыз тәүфыйклы булды. Без эштә булганда мичено дә яктылар, ашарга да әзерләделәр, суын да ташыдылар. Укулары да яхшы булды», – ди ул.

Хәзер ул балаларның икесенең дә үз тормышы, икесенең дә үз балалары. Атна саен әни-әниләре янына мунчага киләләр, бакча эшләренә булышалар.

Август аенда Зөлфиянең туган көне. Моннан ике ел элек аның 80 яшьлек юбилее булды. Балалары бик зурлап уздырдылар.

«Күке әниләр» турында еш ишетәбез. Ә менә Әхнәф белән Зөлфиянең балалары, үги, ятим дигән сүзләрне ишетмичә, әти-әниләренә рәхмәтле булып яши. Һиндия дустымның да рухы шат-тыр моның өчен, ак күлмәктән икән дип төшемдә дә күрдем аны.

Тагын бер вакыйганы әйтми кала алмыйм, Илфак әнисен, туган көн бүләге итеп, Минзәлә районындагы Рус Мөшегесе авылы янында типкән «Шифа чишмәсе»нә алып барган. Бик сөенгән Зөлфия бу бүләккә. Ул чишмә янында үземнең дә булганым бар. Чыннан да, урман эчендә ул, биек тау күкрәгеннән кыйблага карап ага. Теләгән һәркемгә анда юл ачык, М-7 юлыннан өч кенә чакрым керәсе. Барыгыз да рәхим итегез!

Дания БОРҺАНОВА.
Ижау шәһәре.



Үзем яратып укыган «Сөембикә» журналы укучыларыннан яшьлек дустымны табарга ярдәм итүләрен үтенәм.

Мин, Абдулхакова Наилә Мингали кызы, 1957 елда Казанга килеп, ФЗОда укыдым, штукатурлаучы һөнәренә өйрәндем. Бергә укыган иптәшләрем белән баштарак Октябрьнең 25 еллыгы урамындагы тулай торакта яшәдек, 1958 елның апрелендә безне 3 нче трестның Дементьев урамындагы торагына күчерделәр. Бүлмәдәшләрем – тумышы белән Әлки районының Түбән Әлки авылыннан Мәүлихә Нуретдинова белән Җәүһәрия (кызганычка, фамилиясе исемдә калмаган) бик ипле, тыйнак, тәрбияле авыл кызлары иде. Бик тату яшәдек без. Аларны бик сагынам, гел күрәсем килеп яшим.

1959-1960 елларда иптәш кызларымның берсен – Мәүлихәне абыйсы Караганда шәһәренә алып китте, ә инде 1962 еллар тирәсендә дус кызым Казанга кунакка кайтты. Аның белән күрешүем күңелдә әле дә якты бер хатирә булып саклана. «Эх, тагын бер күрешәсе иде!» – дим, дусларым исемә төшкән саен. Хөрмәтле «Сөембикә» журналы укучылары! Бәлки, арагызда минем дус кызларымны белүчеләр бардыр. Бер-беребезне табышырга ярдәм итегез әле безгә. Дусларымны кабат күрүемә бик тә өметләнеп калам. Хәбәрләшү өчен телефоным – 89377730269.

Казан.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru

PRESSA.RU

– Романтика?! Нишләп булмасын, бездә дә бар! Скважинаның син көткәннән артык нефть бирә башлавы, беләсезме, нинди зур сөенеч! Хатын-кызның күбесен алтын-көмеш, бизәнү әйберләре, затлы кием-салымнан гайре берни сөендерми диләр тагын. Ялгышалар... Әнә бит: «Нефть!» – ди!

Гөлнур ХӘСӘНШИНА

ГЕОЛОГ

Үзеннән зур биштәр аскан, йөзен сакал-мыек баскан ир-ат тайга (кыр, урман, дала...) буйлап атлый яки тауга күтәрелә... Менә ул арып-талып кичен учак янында утыра, ут өстендәге казанда үлән чәе кайный, ә аның кулында гитара – ул әкрен генә җыр суза... «Геолог» дигәч, сез дә шушындый күренешне күз алдыгызга китерәсезме? Ул, һичшиксез, ир-ат һәм каядыр моңарчы кеше аягы басмаган кыргый табигатьтә. Бу һөнәр турындагы һәр белешмә: «Геолог – ир-ат һөнәрләреннән санала...» – дип башлана.

Әңгәмәдәшем мине шунда ук туктата: «Сез кыр геологлары турында сөйлисез. Алар башка... Әмма анда да хатын-кызлар сирәк булса да очрый. Бер дус кызым бөтен гомерен Магаданда уздырды менә. Партия белән нәкъ шулай айлар буе каядыр кырда эшләде, яшәде. Юк, алай булдыра алмас идем. Мин нефтьче-геолог!»

Таныш булыгыз: Изида Җиһангир кызы ЧУПИКОВА – Татарстанның атказанган геологы, «Елховнефть» нефть һәм газ табу идарәсенең баш геологы, идарә начальнигы урынбасары. «Мин – башка», – дисә дә, аның да иң беренче экспедициясе кырлар, таулар белән бәйле. Беренче курстан соң алар бер айга Төньяк Кавказга баралар. Яшь чакта авырлыклар сизелми, әмма группадаш егетләр өчен «өстәмә йөк»кә әйләнмим дисәң, физик яктан нык булырга тиешсең. Палаткада йоклаулар, төнге учаклар... Өйдә бүген дә саклanучы минераллар – шул иң беренче партия хатирәсе. Тәүге экспедициядән соң, «бу минем һөнәр түгел икән», дип кайбер кызлар китеп тә бара. Ул кала. И. М. Губкин исемендәге нефть һәм газ институтында (Мәскәү) уку беркайчан да җиңел булмый: белемне тау кебек өеп бирәләр һәм студенттан да бик күпне таләп итәләр.

Икенче курстан соң геофизика экспедициясенә – Ленинград ягына, өченчене тәмамлагач – Казакъстанга чыгып китәләр. Дүртенче курстан соң практика узу өчен ул туган ягына – Әлмәткә кайта. Иң җаваплысы шушы ел булмадымы икән? «Әхмәтов кызы» – Әлмәттә аңа барысы да шулай эндәшә.

«Татнефть»тә эшләүчеләргә «Әхмәтов мәктәбе» дигән термин яхшы таныш. Күптән, «Сөләйнефть» нефть һәм газ идарәсендә скважинага су кудыртуның традицион булмаган ысулларын куллана башлаган чорда ук телгә керә ул. Дөресрәге, аны Татарстан нефтьчеләренең эш тәҗрибәсен өйрәнергә дип Себердән килгән белгечләр кертеп җибәрә. Изида ханымның әтисе Җиһангир Мансур улы Әхмәтов турында: «Легенда!» – диләр. «Татнефть» предприятиеләрендә 44 ел баш геолог булып эшләгән, РСФСРның атказанган геологы исемен йөрткән, Ленин ордены, күпләгән медальләр белән бүләкләнгән. Аны искә алганда бүген дә: «Кырыс, әмма гадел, кул астында эшләүчеләргә генә түгел, беренче

ЯЗМАГА КЕРМИ КАЛГАН ЮЛЛАР.

- Мәктәптә укыганда... космонавт булырга хыяллана!
- Нәфис гимнастика буенча беренче разряды бар.
- Студент елларында Александров исемендәге хәрби ансамбльдә бии.
- Әтисе биргән иң зур сабак: беркайчан да белә торып кешегә начарлык эшләмәскә. Җир түгәрәк – барысы да үзеңә әйләнеп кайтачак.
- 2010 елда Изида Чупикова Бөтенроссия конкурсында «Ел инженеры» исеменә лаек дип табыла. Бүләкләнүчеләр арасында ул бердәнбер хатын-кыз була.
- Аның егермеләп уйлап табу патенты бар.
- Ул – «Татнефть» компаниясенең мактаулы нефтьчесе.
- Соңгы укыган китабы – «Подсознание может все» (Джон Кехо). Китапларга мәхәббәт тә гомер буе китап җыйган әтисеннән күчкән.
- Ял көннәрендә бассейнга йөри. Быел «Татнефть» зур акция оештырган – якшәмбе көнне Әлмәт паркларында инструкторлар халык өчен «Яшел фитнес» уздыралар. «Мин дә барам. Кәеф күтәрелеп кайта аннан!» – ди.
- Кызларыннан кала, аның иң кадерле ике кешесе – оныклары: Әминә белән Ясминә.
- Аның эш сәгате иртәнге җиденче ярты-җидедә башлана. Кайчан тәмамлануын әйтеп булмый...
- Тормышта – эштә дә, гаиләдә дә үз урынын тапкан бәхетле хатын-кыз ул.
- Геолог һөнәрен мәрхүм энесенең улы дәвам итәчәк.



Реклама хокукында

чиратта үз-үзенә карата гаҗәп дәрәҗәдә таләпчән җитәкче иде», – диләр.

– Әтинең хезмәттәшләре безнең өйдә еш булалар иде. Филановский, Григорян, Шелкачев, Мөслимовлар – бүген корифейлар саналучы затлар! – дип сөйли Изида Җиһангир кызы. – Атаклы Хезмәт герое Дамир Нуретдинов исә – терәлеп торган күршебез. Әтиләр – Татарстан нефтен күтәргән кешеләр, алар башка, авыр шартларда эшләгән. Мин бүгенгәчә шаккатам: чын белгечләр булганнар – чорына күрә ни генә башкармаганнар! Без бүген дә алар тәҗрибәсенә таянабыз, әмма мөмкинлекләребез, әлбәттә, күпкә күбрәк. Сөйләшүләр, бәхәсләшүләр, ачышлар... Нефть белән бәйле терминнар энем Наилгә дә, миңа да кечкенәдән таныш. Күп нәрсәне аңламасак та, шул әңгәмәләрне тыңлап үстек. Икебезнең дә әти юлыннан китүе гаҗәп түгел... Әйе, безнең эштә хатын-кызга авыррак. Югары уңышка ирешкәннәр бәлки шуңа сирәктер. Бик күпне белергә, күп нәрсәне истә тотарга кирәк. Без кабул иткән һәр карар – җаваплылык дигән сүз. Җаваплылык зур булганга таләп тә көчле. Әгәр карарың ялгыш икән, ул аварияләр белән дә тәмамланырга мөмкин. Әмма миңа эшем ошый. Бик ошый! Әтидән күчкән ярату бу. Холкым да аныкы минем...

Мәктәпне алтын медальгә тәмамлаган кызының табиб булуын тели Җиһангир ага: «Кешене кызгана беләсең, кирәк чакта нык та булып каласың, яхшы табиб чыгар иде синнән», – ди. Әмма Изидасының: «Геологка укыйм», – диюенә дә каршы төшми. Дипломлы белгечне Әлмәткә алып кайтасы юллар гына... Төрекмәнстанга таба борыла.

Геолог күпкырлы шәхес булырга тиеш.

Урта Азиядә 13 ел яшиләр алар. Изида Чупикованың фәнни-тикшеренү институтында эшләгән еллары бу. Нефть ятмаларын эзлиләр: командировкадан, юлдан кайтып керми. «Геолог хатын-кыз иреннән уңса гына бәхетле була», – дию аңа бик тә туры килә! Юлыма гел яхшы кешеләр генә очрады, дигәндә, ул үзе дә иң элек мәрхүм ирен күз алдында тота бугай. Кая, кайчан гына чыгып китәргә туры килсә дә, ике баланы берсүзсез ире алып кала. «Урта Азиядә менталитет башка иде ул вакытта, – дип искә төшерә Изида ханым. – Кирәк чакта, лезгин күршебез тыныч күңел белән дүрт баласын миңа калдырып тора иде. Башка чакта исә – мин аңа. Шулай тиеш кебек иде бу... Бер үкенечем калды: Төрекмәнстанда кандидатлык диссертациямне якларга өлгермәдем. Анда бик кызу бит, сәламәтлек белән проблемалар килеп чыкты да, Татарстанга күченергә

PRESSA.RU

туры килде. «Зәйнефть» нефть һәм газ идарәсе оешкан чак иде, шунда күчендек...

Зәйдә ул әйдәп баручы геолог булып эшли башлый. Ә баш геолог булып китүе... Искә төшерүе дә кызык. Яңа вазыйфа тәкъдим иткәч, Изида Җиһангир кызы шунда ук баш тарта: «Бу урында ир-ат утырырга тиеш...» Ул арада җәйге ял вакыты җитә. Гариза белән кергән белгечкә идарә башлыгы Геннадий Шариков: «Ярый, әмма эштән китү турында гариза да яз һәм җаның теләгәнчә ял ит, – ди. Аннан, елмаюын күрсәтмәскә тырышып кына өсти: – Яки баш геолог булырга ризалаш...» Күндерә. Эштән ничек китә алсын инде ул?!

«Татнефть» компаниясе эшендә геологлар мөһим роль уйный.

– Безнең эштә бернәрсәне дә өстән-өстән генә белү ярамый. Мин лаборант та, оператор да булдым, буровойда да эшләдем... Барысы да таныш булганга эшләү җиңелрәк. Идарәләрне кушкач, әти-әнигә дә якынрак булырмын, дип, Әлмәткә килдем. Миңа тагын ышаныч күрсәттеләр... Баш геолог булуыма унбишенче ел инде. «Елховнефть» – көчле җитәкчеләре белән дан тота. Планнарны үтәп, арттырып үтәп барабыз. Татарстандагы иң зур ятмаларның берсен эшкәртәбез.

Компаниядәге геологларның төп бурычы – нефть ятмаларының геологик төзелешен өйрәнү, геологик-технологик чаралар: скважиналар бораулау, объектларны рациональ куллану һәм башкаларны планлаштыру... Әңгәмә башыннан ук күңелне кытыклап торган сорауны бирергә, ниһаять, җай чыкты: «Татарстанда яңа нефть ятмалары табылмыйдыр инде хәзер?»

– Табыла! – Әңгәмәдәшем балкып елмая. – Бүген нефть сәнагате, бигрәк тә безнең «Татнефть» компаниясе бик нык алга атлады: барлык юнәлешләрдә яңа технологияләр кирә. Тәҗрибә зур, белгечләрнең профессиональлеге үсә. Инде мөмкинлекләр бетте, дигәндә, яңа – моңарчы башкармаган тикшеренүләр үткәрәбез дә кабат нефтькә тап булабыз. Менә дигән нефтькә! Безнең ятмалар – уникаль!

«Елховнефть» нефть һәм газ идарәсенең гомуми мәйданы өч мең квадрат километр. 5800 скважина урнашкан анда. Разведка скважинасына барып кайтыйм дисә, баш геологка бер көн кирәк. Скважиналарның күбесен күреп беләм, янына баргач, хәтерләп каласың, картага карауга, кая куелганы шунда ук исеңә төшә, ди ул. Эшнең торышын үз күзләрең белән күргәч, кайчак бөтенләй башка төрле карарлар кабул ителә. (Безнең кебек читтән караучыга кырдагы «качалка»лар бернинди тәртипкә буйсынмаган кебек. Чынлыкта, алар өчпочмак «сетка» эченә, мәйданына карап, берберсеннән 150 метрдан алып 400 метрга кадәр ара белән урнаштырыла. Скважиналарны янәшә кую – запасларны эшкәртү өчен кирәк. Бер ятманы бер генә скважина суыртып бетерә алмый – моның өчен аңа 300 еллап вакыт кирәк булыр иде.)

«Тәҗрибә һәм интуиция – геолог өчен иң мөһиме шулар, – ди ул. – Кайчак анализлар да син теләгәнчә булмый, әмма күңелең көтә, ышана: бар монда җир мае, бар! Һәм нефть килә! Биш ел, ун ел килә... «Исеңдәме, шикләнеп тә торган идек ул чакта», – дип сөйләшәбез бер-беребез белән. Әмма хәзер ахыргы нәтиҗәнең әйбәт булуына ышанмыйча, «бәлки...» дип акча түгә, скважина бораулый торган заман түгел. Без күпмедер дәрәҗәдә икътисадчылар да булырга тиеш. Чөнки кабул иткән карарларыбыз турыдан-туры матди чыгымнар белән бәйләнгән. Зур чыгымнар белән! Дистәләгән миллионнар турында сүз бара монда...»

«Татнефть»тә хатын-кыз баш геологлар бүген нибары икәү. Беренчесе – ул, икенчесе Азнакайда – Венера Таипова. (Компания тарихында исә тагын ике баш геолог булган – Галина Кандаурова һәм Минадора Иванова). Ир-ат нефтьчеләр белән бер дәрәҗәдә, бер телдә сөйләшү өчен геолог хатын-кыз алардан күпкә күбрәк белергә тиеш, дип саный әңгәмәдәшем. Гомумән, геолог химия, математика, физика, гидродинамика, петрофизика, катламнарның коллектор сыйфатларын биш бармагы кебек белергә, логик фикер йөртүе – көчле, хәтере әйбәт булырга тиеш.

«Скважиналар – тере. Алар безнең кайгыртуга, яратуга мохтаҗ», – дип шаккаттыра ул мине. Аннан дәвам итә. – Әйе, тере! Алар да вакыт-вакыт дәваланууга мохтаҗ. Әйтик, скважина нефть бирә-бирә дә, кинәт су чыгара башлый. Нигә? Каян килә бу су? Геофизик тикшеренүләр үткәрәбез: суга химик анализ ясала. Һәр катламның үз составы, шуңа күрә суның төгәл кайсы метрдан чыгуын ачыклау бик авыр түгел. Аннан инде карар кабул ителә – башка горизонтка күтәргәме, калыргамы? Еш авырыйлармы? Кызык сорау... Скважиналар «чирләмәсен» өчен без барысын да эшләргә тырышабыз: чирне дәвалаганчы, булдырмау хәерлерәк бит. Алар көн саен даими игътибар көтә. Менә монда кеше факторы зур роль уйный инде: кемдер үз эшенә салкынрак караса, теге яки бу эшне вакытында башкармаса, әллә нинди аварияләр килеп чыгарга мөмкин... Шуның өчен операторлар, яңгыр диме, кар диме, көн саен скважиналарны урап әйләнә дә инде».

Изида Чупикованы таләпчән җитәкче, диләр. Әтисе кебек! Аның соравына җавабың юк икән, дәшми калуың яки «белмим» дип дөресен әйтүең хәерлерәк. Бигрәк тә скважиналар белән бәйле булганда. Ялганны яратмый! Яшьләр, кул астында эшләүчеләр белән белгәннәрен бик теләп уртаклаша ул. «Алар күбрәк белсә, миңа да эшләү җиңелрәк», – ди.

...Кайчандыр үзенең акылына һәм кулындагы чүкечкә (көрәк, кәйлә...), тагын күзенә һәм аякларына гына ышанган геологның «ярдәмче»ләре бүген бихисап: компьютер, космостан төшерелгән сурәтләр, яңа программа продуктлары, электрон микроскоп, геофизик аппаратуралар... Әмма заман ничек кенә алга атласа да, кеше үзе, аның белеме, тәҗрибәсе барыбер беренче урында кала!

ҖӘМГЫЯТЬ





■ Иннополис шәһәрендә «Президент академиясе җәйге кампусы» ачылды. Анда Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Россия хөкүмәте җитәкчесе урынбасары Аркадий Дворкович, РФ мәгариф һәм фән министры урынбасары Александр Повалко, Россия Президенты каршындагы халык хуҗалыгы һәм дәүләт хезмәте академиясе ректоры Владимир Мау катнашты. Рөстәм Миңнеханов әлеге чарада республиканың 10 елдан соң нинди булачагын фаразлады. «Безнең 2030 елгача каралган стратегия бар, һәм анда иң мөһиме: кеше капиталы. Безгә мохит, шартлар тудырырга, белем бирү үзәкләре булдырырга, кешеләрнең яшәү дәрәҗәсен яхшыртырга кирәк», – диде ул.

■ «Балалар парады» гаилә фестивале Казанда бишенче тапкыр үткәрелә. Кремльнең Казансу ярында уза торган бәйрәмдә Казанның яшь гаиләләре теләп катнаша: 2 мең гаилә инде гариза биргән, бу – 8 мең катнашучы дигән сүз. Бәйрәм кысаларында «Балалар – балаларга» хәйрия акциясе «Рональд Макдоналд йорты»ндагы онкологик авырулы балаларны дәвалауга ярдәм йөзеннән оештырыла.

КОТЛЫЙБЫЗ

■ Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры солисткасы Аманда Гомес Варнада узган XXVII Халыкара балет конкурсында I премия лауреаты һәм Алтын медаль иясе булды.



МӘДӘНИЯТ

■ Татарстан китап нәшриятының яңа проекты тест рәвешендә эшләвен дәвам итә. «Татар әдәбияты үзәге» Татарстан халкы арасында гына түгел, бөтен дөньяга чәчелеп яшәгән милләттәшләребезгә татар әдәбиятын таратуны максат итеп куя. Әлеге порталда интернет-кибет һәм бушлай онлайн-китапханә булдырылган. Электрон китапханәдәге басмаларны төрле параметрлар буенча сайлап алырга һәм шәхси китапханәләрне формалаштырырга мөмкин.



■ Халкыбызның яраткан җырчылары Рәшит Ваһапов белән Хәйдәр Бигичевка Түбән Новгород өлкәсенең Кызыл Октябрь районы үзәгендә – Уразавылда һәйкәл-бюст ачылды. Аны ачуда Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов белән Түбән Новгород губернаторы Евгений Шанцев катнашты.

■ «Созвездие-Йолдызлык» республика телевизион яшьләр фестивале җиңүчеләре Кара диңгез флоты хәрби базасында концертлар куйды. Биредә Татарстан Республикасының 17 район һәм шәһәреннән 180 яшь башкаручы җыр, бию, нәфис сүз буенча иң яхшы чыгышларын күрсәтте. Әлеге җәйге концертлар 12 ел уздырылып килә. Быел Сүриядә хәрби операцияләрдә катнашучылар Татарстан балалары концертын тамаша кылды. Яшь артистларга Диңгез пехотасының күкрәк билгесе тапшырылды.

ДИН

■ Коръәнне татар теленә тәрҗемә итәргә ниятлиләр. «Аны Россиядә яшәүче барлык милләттәшләребез дә укый алачак», – ди ТР Диния нәзарәте вәкилләре. Изге Коръән китабын бүгенге татар теленә тәрҗемә итү буенча эшче төркемне раслады. Ел ярым дәвамында Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендә нәзарәтнең махсус оештырылган Коръәнне өйрәнү бүлеге белгечләре «Казан басмасы»ның яңа нөсхәсен эшләде.

СПОРТ

■ Мәскәүдә «Шереметьево» аэропортында Россия спортчыларын Рио-де-Жанейрода узачак 2016 елгы Олимпия уеннарына озаттылар. Спортчылар арасында волейбол, гандбол, өстәл теннисы җыелма командасы вәкилләре, синхрон йөзү, бокс, ат спорты буенча Россия җыелма командасы бар иде. Уеннарда Татарстаннан 14 кеше катнаша. Волейбол җыелма командасында республика вәкилләре аеруча күп.

МӘГАРИФ

■ Татаристика югары мәктәбе филология, тарих, археология һәм культурологияне берләштерергә тиеш. ТР Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев бу хакта КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында әйтте. Анда татар телен, милли мәдәниятне, тарихны һәм гореф-гадәтләрне саклап калу турында сөйләштеләр.

■ «Мәктәбеңә булыш!» республика акциясе барышында быел меценатлар 36 райондагы 420 мәктәпкә һәм балалар бакчасына булышып, 7 миллион 285 мең сумлык яшелләндерү, буяу, ремонт эшләрен башкардылар, мультимедиа җиһазлары, мебель, канцтоварлар сатып алдылар.

PRESSA.RU



БУ КЫРЛАР, БУ БАСУЛАРНЫҢ ҺӘР КАРЫШЫ КАДЕРЛЕ АҢА. ҮЗ ГОМЕРЕНДӘ НИЧӘ КАТ УРАДЫ ИКӘН УЛ АЛАРНЫ.

Язын – чәчү вакытында, җәен – арышлар серкә очырганда, көзен – урак урганда, ә кышын... Кышын да тик ятмагандыр, кар тигез ятамы, уҗымнар өшемиме дип, күңеле һаман шул газиз басуларга әйдәгәндер. Игенченең алы да, ялы да шушы кырларда аның...

ШУШЫ ҖИРДӘ ҖЫРЫМ КАЛСЫН



Лилия ГӘРӘЕВА

Алабуга районының Дөм-Дөм авылындагы «Яшь көч» агрофирмасы җитәкчесе Һадиуллина Рузилә Мирсәет кызын шулай җиңел генә игенче дидем дә бит, ә чынлыкта, үзе үк игенче дә, терлекче дә, агроном да, укытучы да, психолог та, өч баласына – Ландыш, Марат, Рөстәмгә – әни, оныкларына әбекәй дә әле ул.

Тормыш бәянын Галимҗан Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр» романындагыча башлаган иде Рузилә Мирсәет кызы: «Без тирәннән, тормышның төбеннән күтәрелдек. Әти-әни гади кешеләр... Әти гомере буена фермада терлекче булып эшләде, көтү көтте». Мөслим районының Тойгелде авылында, җиде балалы гаиләдә туып-үскән Рузилә ханым үзе турында сөйләргә яратмый. Эше турында, авылдашлары, басу-кырлар, фермадагы терлекләр турында – менә алар хакында рәхәтләнеп сөйләргә риза. Ярты гомерен биргән хуҗалыгы күңеленә газиз баласыдай якын. Ире Әмирнең әманәте дә, авылдашларының ышанычы да бу хуҗалык.

Реклама хокукында

Дөм-Дөм туфрагына тәүге тапкыр 1973 елның 14 июлендә – үзләренең туй көнендә аяк баса ул. Ире Әмир белән дүрт кенә ай йөриләр дә, өйләнешәләр. Бигрәк тиз дияргә ашыкмагыз, Казан дәүләт авыл хуҗалыгы институтында гыйлем ташын бергә «кимергән»нәр бит. Кешеләрне уртак хыял берләштерә, диләр. Әмиренең исә хыялы бер – үзе туып-үскән авылга кайтып эшләү, үз авылын күтәрү. Ул чорларда яшәүчеләр белә – партия синең хыялларың белән исәпләшеп тормый, аның үз планнары. Әмир белән Рузиләнең дә яшьлек еллары республикабызның төрле авылларын күтәреп уза. Кайда гына, нинди генә яхшы нәрсә күрмәсен: «Эх, безнең Дөм-Дөмдә дә булсын иде бу», – дип яшәгән Әмир абый 1985 елда үз авылына эшкә кайта – өч авылны берләштереп төзелгән «Красный луч» колхозы таралып, Дөм-Дөм хуҗалыгы «Яшь көч» кооперативы булып аерым эшләп киткәч, Әмир Гыйльмулла улын аның җитәкчесе итеп куялар. «Яшь көч» – әби-бабайлар мирасы. 1929 елда Дөм-Дөм халкы оештырган беренче колхоз да шушы исем белән аталган. Колхозны кабат күтәрү, авылны яңадан аякка бастыру өчен күп көч куя Әмир абый. 160 балага исәпләнгән ике катлы мәктәп төзетә, юлларга асфальт түшәлә, газы, суы үткәрелә. Авыл башындагы элеккеге алма бакчасын да кабат шау чәчәккә күмәргә хыяллана ул. Яңа үсентеләр алып кайтып утырта. Ә инде язмыш Әмирен тагын да зуррак эшләргә – башта Алабуганың икътисад идарәсе җитәкчесе, аннары район башлыгының авыл хуҗалыгы буенча урынбасары итеп чакыргач, аның эшен Рузилә ханым дәвам итә. Шушы хуҗалыкта икътисадчы булып эшләгән кеше өчен колхоз рәисе вазыйфасы да башкара алмаслык эш булып тоелмый. 1998 еллар бу. 2000 елда исә өч колхозны берләштергән «Вятка» ассоциациясе оеша. Аны җитәкләргә тагын Әмир Гыйльмулла улы алына. Бер гаиләдә ике җитәкче. Тормыш гел шулай матур барыр сыман була да бит... Йөрәгенең авыртуын элегрәк тә әйткәләгән ул. Авыл кешесенең үзен кайгыртырга вакыты бармыни? Бүген чәчү, иртәгә печән, аннан инде уракка төшәсе. Елның дүрт фасылы урынына бишенчесе булса да, өлгерерлек түгел. Шуңа күрә аның вакытсыз үлеме барысын да өнсез итә. Алабугадан авылга кайтышлый, рульдәге ирнең йөрәге туктый. Нибарысы 56 гына яшь була аңа. 2005 елның 11 октябре Рузилә апа тормышындагы иң кара көн – газиз кешесеннән мәңгегә аерылган көн! Ире вафатыннан соң, дөньяда бернигә күтәрелеп карыйсы килмәсә дә, йөрәк әрнүләрен эчкә йотып, Рузилә Мирсәет кызы «Яшь көч» колхозын ассоциациядән аерып чыгару артыннан йөри. Әмиренең хыялларын инде берүзенә тормышка ашырасы. Хуҗалыкны таркатырга, эшне ярты юлда калдырырга вөҗданы кушмый.

Бу авыр көннәрдән соң да дистә елдан артык вакыт үтеп киткән инде. Рузилә апа әманәткә бүген дә тугры – «Яшь көч» агрофирмасы замана җилләренә каршы тора-тора, үз көенә яши бирә. Ялгыз түгел Рузилә апа, янында ярдәмчесе – кечे улы Рөстәм, килене Лиана бар. Алары үзе белән бергә яшәсә, кызы Ландыш белән улы Маратның тагын үз тормышлары, берсе – Алабугада, икенчесе – Мамадышта.

Без Дөм-Дөмгә килгән көнне «Яшь көч»ләр уракка чыккан иде. «Безнең белгечләр инде болар», – дип сөенеп тә, горурланып та таныштырды Рузилә ханым агрофирманың яшь агрономы Рафат Нотфуллин белән. Аксубай егете икән, «Яшь көч»тә икенче елын эшли. Эшчеләр темасы җитәкченең куанычы да (куана, чөнки ул аларга ышана), иң авырткан җире дә. «Кешеләр җитешми, – ди ул. – Хуҗалык бетә икән, авыл бетәчәк. Авылны бетерәсе түгел иде. Теләгән эшне эшләп булмау да ачуны китерә. Барысы да акчага барып төртелә. Сөтнең бер литры 17 сум 50 тиен. Кибеттә минераль су да сөттән кыйммәтрәк тора. 1170 баш мөгезле эре терлек асрыйбыз. 330 савым сыерыбыз бар. Аларны баштарак алты кеше сауды. Хәзер тагын бер



Марат ӘХМӘТОВ, ТР Премьер-министры урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры:

«Татарстан Республикасы хөкүмәте авыл хуҗалыгы тармагына ел саен дәүләт ярдәме чараларын раслый, республика бюджетыннан бирелә торган дәүләт ярдәме төрләрен һәм шартларын билгели.

Крестьян (фермер) хуҗалыкларына дәүләт ярдәме – «Крестьян хуҗалыклары базасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерү», «Эш башлаучы фермерларга ярдәм»; авыл хуҗалыгы кооперативларына «Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү» программалары буенча күрсәтелә. Ярдәм күрсәтү авыл хуҗалыгы корылмаларын төзү һәм булганнарын төзекләндерү, терлек, хуҗалык өчен техника һәм авыл хуҗалыгы өчен кирәкле эш җиһазлары сатып алуга грантлар бирүдән гыйбарәт.

Гамәлләрен раслый торган тиешле кәгазьләре булган очракта, фермерлар үсемлекләр белән шөгыльләнүгә (орлык бәрәңге һәм ачык туфракта яшелчә үстерү, яхшы орлыклар сатып алу), 1 кг тапшырылган сөткә, токымлы терлекләр үрчетү өчен тотылган чыгымнарга, авыл хуҗалыгы җиһазлары, техникасы һәм башка кирәк-яраклар (35 юнәлеш) сатып алуга субсидия ала алалар. Хосусый хуҗалыкларга ярдәм итү чаралары «Татарстан Республикасында хосусый хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме турында»гы канун нигезендә башкарыла. Әлеге канун быел кабул ителде.

Ярдәм итү төрләре арасында: хосусый хуҗалыкны үстерү өчен алынган кредит процентларына; бозаулар һәм таналар, токымлы кәҗәләр, бәбкәләр һәм чебешләр (күркә, каз-үрдәк, бройлер чебеше) сатып алуга; сыерларны ясалма орлыкландыру чыгымнарының бер өлешенә; өч яшьтән олырак бияләрне асрау өчен азык сатып алуга; сыерларга профилактика ясау буенча күрсәтелгән ветеринария хезмәтенә; сөтчелек юнәлеше буенча кече фермалар төзүгә субсидияләр каралган.

Болардан тыш, авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә субсидияле кредитлар бар. Хуҗалыкны техник һәм технологик яктан яңарту өчен тотылган чыгымнарның бер өлеше субсидияләнә. Шулай ук «Лизинг грант» программасы, терлекчелек объектларына юл салу, фермаларны, яшелчә саклау урыннарын төзекләндерү буенча да программалар гамәлгә ашырыла.»

PRESSA.RU







Агрофирма пай җирләрен арендага алып эшли. Җирдән файдаланган өчен салымын да үзләре түли, халыкка печән-саламын да, ашлыгын да мулдан өләшә.



кеше алдык. Бик авыр хезмәт бит бу. Гел аммиак иснәп, тирес арасында эшләргә кирәк. Европача мегафермалар салырга көч җитми бит. Инде булган сыер савучыларыбыз да олыгаеп бара. Алар киткәч, бу фермаларда эшләргә, белмим, кемнәр генә килер. Килер өчен авылда яшьләр дә юк. Әмир ни тырышып мәктәп төзетте. Уңайлы, җылы, якты булды дип куанды. Баштарак аны башлангычка калдырдылар, инде хәзер авылда башлангыч мәктәп тә юк. Элек авылда бер генә укучы булса да, мәктәпне япмый сакладылар. Ә хәзер... Хәзер безнекеләр Шурнәк авылына автобус белән йөреп укый. 26 бала китте ул мәктәпкә. Быел Дөм-Дөм авылыннан бер генә чыгарылыш укучысы да булмады. Ярый инде, бинасы булса да халыкка хезмәт итә. Хәзер анда китапханә, медпункт, балалар бакчасы. Авылда 280 ләп кеше яши. Аның 80 е – пенсионер. 40 лап кешесе бездә эшли. Үз җирләрен алып, үзләре эшләүчеләр дә бар».

Агрофирмада даими эштә иллегә якын кеше эшләсә, чәчү, урып-җыю вакытларында вакытлыча килеп эшләүчеләр белән йөздән артып китә. Үзләренең Дөм-Дөменнән генә түгел, күрше Шурнәк, Үмәк, Морт, Елово авылларыннан вахта белән килеп эшләүчеләр бар. Эшләгән кешенең кадерен белә торган кеше Рузилә апа. Бушлай ашату-эчертү белән генә чикләнми ул, колхозчыларны санаторийларга җибәреп, дәвалау юлларын да табарга тырыша. Авылдашларының хәл-әхвәле белән кызыксынып яшәгән, ярдәм сорап килсәләр, ничек тә булышу әмәлен табарга тырышкан җитәкчеләр тагын бардыр барын, ләкин сирәктер. Мактап та, арттырып та әйтү түгел – Рузилә ханым нәкъ менә шундый җитәкче. Аңардан печән дә, икмәк тә сорыйлар, такта да, түбә калае да... Хәле авырлар дәвалануга акча сорый. Үзе дә авыл кызы – хәлләрен аңламыймы соң?!

Агрофирма конторыннан чыгуга, иген басулары башлана. Көз алтын башаклар арасына поскан зәңгәр чәчәкләрне эзли. «Чәчәкле басулар юк бездә, – дип сүзгә кушыла хуҗалыкның баш бухгалтеры Асия Нәбиуллина. – Чәчәк булгач, чүпле басу була бит ул».

«3 мең гектар җиребез бар, – ди Рузилә Һадиуллина, алтын басуларга ишарәләп. – 5 комбайныбыз, 18 тракторыбыз гөрләп эшләп тора. Шулай да техника җитә дип әйтеп булмый. Авыл хуҗалыгы техникасы бик кыйммәт. Кредит алырга тырышмыйбыз. Булган техниканы карап, төзәтеп, вакытында чәчәбез, агулыйбыз, эшкәртәбез, ашламасын кертәбез. Элегрәк ашламаны гектарына физик нисбәттән 4-5 центнер керткән чаклар бар иде. Ник физик нисбәттән димме – 1 центнер ашламаның 34 килосы гына җиргә тәэсир итә. Калганы игенне яндырмасын өчен кушыла торган катнашмалар гына. Хәзер чәчү вакытында 1 центнер кертергә тырышабыз. Үскәндә тукландырабыз. Шуның белән бергә 2 центнерга туладыр. Быел гектарыннан 25–30 центнер уңыш булыр дип торабыз. Елына күрә начар түгел. Безнең туфрак – көлсу ярлы туфрак. Мөслим якларындагы кара туфракка без керткән ашламаларны кертмәсәң дә, без алган уңышны алып буладыр дип уйлыйм мин. Туфрагыгыз ярлы, дип, беркем дә ташлама ясамый. Чәчүлек орлык җитештерүче хуҗалык булып саналсак та, хәзер орлыкка бөртек сатып алучылар

12 августта Рузилә Мирсает кызы Һадиуллинаның 65 яшьлек юбилее. «Яшь көч» агрофирмасы коллективы аны туган көне белән ихластан тәбрик итә: «Хөрмәтле Рузилә Мирсаетовна! Ничә еллар Сез безнең өчен гадел җитәкче генә түгел, сабырлык, тугрылык үрнәге дә булып торасыз. Олылар янында – олы, кечеләр янында кече була белгән киң күңелле, олы җанлы кеше Сез. Күңел тынычлыгы, тормыш иминлеге, саулык-сәламәтлек телибез».
Котлауларга «Сөембикә» журналы редакциясе дә кушыла.

сирәк. Дөрес, сатарга алай артык күп ашлыгыбыз да калмый. Терлек саны күп бит. 100 гектар авыл хуҗалыгы җиренә кайдадыр 5-7 баш мөгезле эре терлек туры килсә, бездә ул 35-37 баш. Бик күп инде бу. 2010 елгы корылык елны да баш санын киметмәдек. Киметәбез икән, эш урыннары кыскара. Авыл кешесен ничек эшсез калдырасың? Шушы авыл яшәсен, кешеләргә эш булсын, дип, төн йокламый уйланып чыккан чакларым бар».

Килгән-килгән, анда да сугылыйк, дип, Рузилә ханым белән фермага юл тотабыз. Малларны ике көтүгә бүлеп, көнаралаш чиратлаштырып көтәләр икән. «Кигәвен чоры бит, малларны бик каһәрли, – дип аңлата моны 26 ел буе шушы фермаларның мөдире булып эшләгән Хәбибуллин Илдар Нәбиулла улы. – Безнең бар да үзенчәлекле», – ди ул, радионың «колагын» борып. Сыерларга матур җыр тыңлатмакчы, ахрысы, нияте. Заманча «Де-Лаваль» системасы белән савалар икән. Сыер савучыларның эшен шактый җиңеләйткән ул. Фермада барысы бергә 21 ләп кеше эшли. Терлекчеләрне көнгә ике тапкыр ашаталар. Монысы – бушлай. Бәйрәмнәр уздыру өчен фермада ук зур зал бар.

Бәйрәмнәр, дигәннән... «Авыл кешесе, хуҗалыгын ташлап, әллә кайдагы концерт-театрга чыгып китә алмый. Әмма гел авыр эштә эшләгән кешегә анысы да кирәк. Бәйрәмнәрдә концертларны үзебез оештырабыз, спектакльләр куябыз. Эстрада артистлары да үз итә авылыбызны», – ди Рузилә ханым.

Балачагында артист булырга хыялланган ул. Анда гади колхозчы баласын алмыйлардыр дигән уе гына хыялына йөгән салган. Тик күңеленә яшерелгән шул кузлар һаман пыскый, күрәсең. Сәхнәне яратам ди. Бергә эшләүчеләре сер итеп кенә аның бик матур җырлавын, спектакльләр куйганда төрле рольләрне оста уйнавын әйткәннәр иде инде. Әмирнең баянда уйнап, Рузиләнең өздереп җырлаганын алар әле бүген дә сагына.

Рузилә ханымның эш бүлмәсендәге фотоларга күз салам. Күбесенчә авылдашлары арасында Сабантуйда төшкән сурәтләр. Сабантуйлар бик матур уза икән Дөм-Дөмдә. Сүз уңаеннан, аны да агрофирма тулаем үзе уздыра. Әнә 2012 елгы Сабантуй мизгелләре, 2013, 2014, 2015, 2016 елгылар... Һәр елга аерым альбом багышланган. Сәхнәдә – эстрада йолдызлары, ә түрдә – хуҗалыкның иң тырыш эшчеләре. «Сабантуй – тырыш игенчеләр, терлекчеләр бәйрәме ул, – ди Рузилә ханым. – Бездә бу көнне беркем дә бүләксез калмый. Шәһәргә үзем барып, үзем сайлап алып кайтам ул бүләкләрне». Ни җитте генә бүләкләр түгел – яхшы телевизорлар, кер юу машиналары, суыткычлар... Кыскасы, эшне дә оештыра белә Рузилә Мирсает кызы, ялны да...

Аның белән аралашкан шушы ярты гына көн эчендә дә мин аның авыл дип җан атуын, авылларның картаюына пошынуын, яшәр өчен, эшләр өчен шартлар булса, авыл үзен-үзе дәвалар иде дип өметләнүен, шуңа омтылуын, җан-фәрман тырышуын күрдем. Яшерен-батырын түгел, җитәкче кешеләр, гадәттә, кырыс була. Рузилә ханым да таләпчән җитәкче. Ләкин таләпчәнлеге ышыгында аның нечкә күңеле, кайгыртучан, мәрхәмәтле йөрәге бар! Күңелендә – җыр, йөрәгендә матурлыкка мәхәббәт йөрткән кеше каты бәгырьле була алмый.



Әлфия КОГОГИНА, РФ Дәүләт Думасы депутаты, «Бердәм Россия» фракциясе әгъзасы:

«Авыл хуҗалыгы өлкәсендә ирешкән уңышларыбыз – Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов җитәкчелегендә бөтен республика белән ирешкән уңышлар ул. Монда һәркемнең: депутатларның да, министрлыклар һәм муниципалитетларда эшләүчеләрнең дә, ә барыннан да бигрәк – авыл хезмәтчәннәренең эше мөһим. Тырыш хезмәтегез өчен бик зур рәхмәт сезгә!

Дәүләт Думасында 2016 елда авыл хуҗалыгы техникасы җитештерүче заводларга 10 миллиард сум күләмендә субсидия бирү хакында сүз булды, бу исә инде быел ук 20 берәмлеккәчә авыл хуҗалыгы техникасы алырга мөмкинлек бирәчәк. Техника паркын тиешенчә яңарту өчен без ел саен шушы темпны сакларга тиеш. Дәүләтнең алыштыргысыз ярдәмен нәкъ менә шуның өчен тәгаенләдек тә. Авыл хуҗалыгына ярдәм итү чараларын тормышка ашыру өчен 2015 һәм 2016 елларда федераль бюджеттан 237 шәр миллиард сум акча бүленде. 2016 елда Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы тармагын үстерү өчен 14,5 миллиард сум акча каралган, аның 8,4 миллиарды – федераль бюджет хисабыннан бирелә. Бу акчаларны авыл хуҗалыгы өчен махсус җиһазлар һәм техника сатып алырга, авыл хуҗалыгы корылмалары төзү һәм төзекләндерүгә тотарга була.»

PRESSA.RU



Казан Универсиадасы вакытында меңләгән кеше тамаша кылган «Ак бүре» операсын иҗат итеп, ул борынгы татар әкиятенә җан өрде. Атаклы вокалистлар аның белән хезмәттәшлек итә. Виртуоз баянчы Айдар Гайнуллин исә аның «Pentatango» әсәрен үз репертуарына алган.

Мәскәү композиторы Зөлфия РӘҮПОВА, татар музыкаль традицияләренә тугры калып, Татарстан белән һәрчак элемтәдә яши.

ЗӨЛФИЯ РӘҮПОВА: «ҖЫР ЯЗУ – ҖАН РӘХӘТЕ УЛ»







Зөлфия, үҗәтләнеп, шушы профессиягә килүегез һәм Казан консерваториясенә дүрт (!) тапкыр керергә талпынуыгыз биографиягезнең аерылмас бер өлешенә әйләнде. Ничек булды ул?

– Озын тарих ул. Иң гаҗәбе: минем күз алдында беренче тапкырында ук җиңел генә укырга кергән егетләрнең күбесе бу профессиядән күптән китте инде. Миңа башка юл әзерләнгән булып чыкты. Профессиональ композитор булыр өчен консерваториягә дүрт мәртәбә штурмларга туры килде. Дөресен генә әйткәндә, ышанып та бетмиләр моңа...

Әти, мине юатырга өметләнеп, гел: «Аңла инде, балам, алмагач талантың юктыр. Менә мин, бәлки, космонавт булырга телимдер, ләкин бу мөмкин түгел икәнен аңлыйм. Сиңа да килешергә кирәк», – ди торган иде. Ләкин мин үземә һәм хыялыма тугры калдым. Хәзер, инде еллар узгач, хыялымны чынга ашырырлык үҗәтлек, тырышлык, ихтыяр көче, үземә ышаныч җиткәнгә сөенәм, мин – бәхетле. Әти-әнием минем белән горурлана.

Ә бит өметсезлеккә бирелгән чакларым да булмады түгел. Композиторлар бүлегенә керер өчен элеккеге еллардагы кебек ыгы-зыгы да, конкурс та юк хәзер. Композитор булуның дәрәҗәсе нык төште.

90 нчы еллардагы Казан консерваториясе турында нинди истәлекләр саклана Сездә? Нәҗип Җиһанов рухы сизелә идеме анда?

– Искиткеч атмосфера иде ул вакытларда. Мин профессор Анатолий Луппов классында укыдым. Альберт Леман белән аралашырга туры килде, ул Казанга мастер-класслар үткәрергә махсус килә иде. Мәскәүдән Алмаз Монасыйпов килеп дәресләр бирде. Консерваторияне һәм аспирантураны тәмамлагач, Фуат Мансуров белән аралашу бәхете елмайды. Япон язучысы Юкио Мисима романы буенча язылган «Алтын сарай» премьерама 2008 елда ул дирижерлык итте. Ахырдан әсәр «Татарстан композиторлары музыкасы антологиясе»нә керде һәм 2012 елда Sony Music тарафыннан яздырылды. Татар музыкасының күп аксакаллары исән иде әле ул чакта. Мәсәлән, полифония буенча дәресләрне Мирсәет Яруллин алып бара иде.

Иң беренче зур музыкаль әсәрләрегезнең берсе – Сөембикә ханбикә турындагы симфоник поэмагыз нинди шартларда язылды?

– 2003 елда мине хореограф Айгөл Гыйльметдинова эзләп тапты. Бүгенге көндә ул Санкт-Петербургта эшләүче билгеле балетмейстер. Ул чакта Айгөл Казанның соңгы ханбикәсе Сөембикә язмышы турында махсус симфоник әсәр язуымны сорап мөрәҗәгать иткән иде. Бик күп тарихи әсәрләр укырга, Казан Кремле белән озаклап танышып йөрергә, Болгарга сәяхәт итәргә туры килде. Болар барысы да минем музыкаль күзаллавымны баетты, Казан ханлыгы чоры тарихын, Сөембикәнең иң кайгылы көннәрен чагылдырган образны тасвирларга ярдәм итте.

2004 елда бу әсәр яшь композиторлар һәм башкаручыларның «Россия Яшьләр Академияләре» бөтенроссия фестивалендә иң яхшы әсәрләрнең берсе дип танылды, мин «Россия халыклары ассамблеясе» медале белән бүләкләндем. Әсәрнең уңышы дирижер Александр Сладковский исеме белән дә бәйле, ул профессиональ язмышымда шулай ук зур роль уйнаган кеше. Мәскәү тамашачысы Сөембикә турындагы әсәремнән фрагментны 2015 елда Мәскәүдә узган Татарстан көннәрендә күрә алды. ММДМның Светланов залы сәхнәсеннән Борис Эйфман балеты солистлары башкарды аны.

Хәзерге композиторларда авангард музыкасы белән кызыксыну кимүне, аларның мелодизмга әйләнеп кайтуларын нәрсә белән аңлатасыз?

– Музыка тарихында табигый күренеш бу. Композиторның публика белән аралашу чарасы буларак кабул ителгән авангард музыкага ихтыяҗ югалды. Аның вакыты үтте. Минем музыка – тыңлаучым белән «йөрәктән йөрәккә» аралашу ул. Шуңа күрә күбрәк мелодизмга тартылам, авангард музыканы колористик максатларда, әсәремнең художество уйланылышы соралганда кулланам.

Иң беренче зур музыкаль әсәрем Сөембикә ханбикә турында.

Казанлылар һәм Универсиада кунаклары 2013 елның җәендә «Ак бүре» операсының масштаблы премьерасы белән таныштылар. Опера премьерасы Мәскәүдә узды. Бу әсәр ничек иҗат ителде?

– Татарстан Республикасы Дәүләт симфоник оркестрының сәнгать җитәкчесе һәм баш дирижеры Александр Сладковский заказы буенча язылды ул. Сюжетны һәм либреттоны үзем сайладым. Балаларга әкият укыганда очраклы гына «Ак бүре» әкиятенә юлыккан идем. Шулкадәр ошады – мизгел эчендә сайланды ул. Алдан тоемлавым монда да сынатмады. Либреттоны талантлы яшь шагыйрь Рүзәл Мөхәммәтшин иҗат итте.

Бердәнбер кыенлык: мин ул чакта әле яңа гына икенче баламны тапкан идем. Әни, хатын һәм актив иҗат итүче композитор функцияләрен берләштерү катлаулырак булды. Постановканың мөһимлеген аңлау һәм проектта катнашучы күпсанлы иҗади коллективлар каршында җаваплылык тою гына үземне кулга алып, эшне вакытында тапшырырга мөмкинлек бирде.

Куелышта өч йөздән артык кеше катнашты: Татарстан Республикасы Дәүләт симфоник оркестры, Миләүшә Таминдарова җитәкчелегендәге Татарстан Республикасы Дәүләт камера хоры; Дәүләт җыр һәм бию ансамбле (сәнгать җитәкчесе Айрат Хәмитов), «Пантера» камера балеты (сәнгать җитәкчесе Наил Ибраһимов), Мәскәү, Санкт-Петербург һәм Казанның яшь җырчылары.

Фото З. Рәүпова архивыннан

PRESSA.RU

«Ак бүре» операсын мин әле бай декорацияле, кызыклы сценографияле, режиссер табышлы опера театры сәхнәсендә күрергә дә хыялланам. Кайчан да булса хыялым тормышка ашар дип өметләнәм...

Зөлфия, Сез Нәзифә Кәримова сүзләренә искиткеч җырлар иҗат иттегез. Аларны Эльмира Кәлимуллина һәм Альбина Латыйпова башкаруында яхшы хәтерлим.

– Әйе, җырлар иҗат итәргә яратам, минем өчен ул җан рәхәте. Шулай да симфоник музыкага ныграк тартылам.

Татар һәм аргентина музыкасын берләштергән, Айдар Гайнуллин репертуарының аерылгысыз бизәгенә әверелгән «Pentatango»ны иҗат итү фикере каян килде?

– «Pentatango» (биш ноталы танго) Айдар Гайнуллин заказы буенча туды. Мәскәүдә опера премьерасыннан соң Айдар Гайнуллин, яныма килеп, үзара хезмәттәшлек итү теләген белдерде. Айдарның танголар яратуын белгәнгә күрә, шундый танго иҗат итү идеясе миңа да кызык тоелды. «Pentatango»ның Айдар күңеленә хуш килүенә мин бик шат, аның башкарылу географиясе дә киң: һаман саен күбрәк шәһәрләрдә яңгырый. Айдар соравы буенча, «Pentatango»ның берничә вариантын эшләдем: камера оркестры, симфоник оркестр һәм үзенең «Эйфория» ансамбле өчен.

Мәскәүдәге татар тамашачысы бик зәвыклы!

Сез Мәскәүнең кайнап торган татар мәдәни тормышында актив катнашасыз. Башкала тамашачысы нинди ул?

– Мәскәүдәге татар тамашачысы рәхмәтле була белә. Алар бик зәвыклы. Мәскәүдә үземнең иҗатымны бәяли белгән чын тугры тамашачыларым булуга сөенәм.

Иҗади тормышта кайнап яшәвегезне белгәнгә күрә сорыйм да: пианист Рөстәм Кудояровның хатыны да, ике кечкенә бала әнисе дә булып иҗат белән шөгыльләнергә ничек вакыт табасыз?

– Әлбәттә, җиңел түгел. Вакытны дөрес бүләргә кирәк була. Киңәшләр бирергә яратмыйм, бу мәсьәләгә карата фикер уртаклаша гына алам. Үз гаиләңне һәм эшеңне чын-чынлап яратсаң – вакыты да җитәчәк, эшләрең дә барып чыгачак.

Әсәрләрегез күпләрнең яраткан музыкасына әйләнде. Үзегез кайсы композиторларны яратасыз?

– Күп композиторларның музыкасы миңа якын. Иң яраткан композиторларым исә өчәү генә – Бах, Прокофьев, Фәрит Яруллин.

Марат СӘФӘРОВ.
Мәскәү.



ТАТАРЛАР – МӘСКӘҮДӘ

Нижгар татарлары, Башкортстаннан чыгучылар, Себернекеләр, Казаннар, Пензаныкылар, Мордовия татарлары... Мәскәүдә яшәүче милләттәшләребезнең һәммәсен туган телгә, мәдәнияткә, моңга, рухи мирасыбызга тартылу, уртак тамырлар берләштерә. Татарча барган һәр чараны Мәскәүнең татар җәмәгатьчелеге сусап, яратып кабул итә. Милләткә хезмәт итәргә теләгән һәр кешегә, һәр оешмага эш җитәрлек. Аларның барысын исә Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге Тулы вәкаләтле вәкиллеге үз тирәсендә туплап тора. «Татарстан якташлары» оешмасы да вәкиллек каршында эшли.

Татарстан Республикасы Премьер министры урынбасары – Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге Тулы вәкаләтле вәкиле Равил Әхмәтшин быел Герой шагыйрь Муса Җәлилнең тууына 110 ел тулу уңаеннан медаль булдыру турындагы карарга кул куйды. Ул шагыйрьнең мирасын саклау, исемен мәңгеләштерүдә зур өлеш керткән шәхесләргә ел дәвамында тапшырылачак. Муса Җәлилнең юбилее уңаеннан Мәскәүдә шактый чаралар оештырылды: Мәскәү Татар мәдәни үзәгендә тантаналы кичә, шагыйрьнең һәйкәленә чәчәк салу, иҗатының соңгы елларына багышланган түгәрәк өстәл...

Композитор Сәйяр Хәбибуллинның юбилей концерты, атаклы җырчы Хәйдәр Бигичевны искә алу кичәсе, бөек шагыйребез Габдулла Тукайның 130 еллык юбилее уңаеннан шигырь бәйрәме һәм тантаналы кичә, Г. Тукай исемендәге «Энҗе бөртекләре» татар балалар иҗаты фестивале, мәшһүр хирург һәм галим Ренат Акчуринның 70 яшьлеге уңаеннан төшерелгән документаль фильмны тәкъдим итү кичәсе, «Нәүрүз-2016» шәһәрара бәйрәме, йөз җитмеш меңләп халыкны бер мәйданга туплаган Сабантуй, Фуат Мансуров исемендәге IV яшьләр музыка фестивале, «Рамазан шатеры» мәдәни-хәйрия проекты кысаларында Татарстан Республикасы киче һәм бәйрәм ифтары...

Башкалада яшәүче татар яшьләрендә туган телгә мәхәббәт тәрбияләү – Мәскәүдәге татар оешмаларының иң зур максаты. Шул уңайдан, вәкаләтле вәкиллек Яшьләр советы оештырды. Татар яшьләрен берләштерү, Мәскәү югары уку йортларында белем алучы якташларыбызны бергә туплау, туган телне үстерү белән бәйле проектлар – Яшьләр советы шушы эшләр белән шөгыльләнә.

Әйе, Мәскәүдә татар тормышы гөрләп тора! Россия башкаласында Татарстан көннәрен үткәрү дә матур традициягә әйләнде.

БӘЙРӘМЕГЕЗГӘ «МӘСКӘҮ ЙОЛДЫЗЫ» КИЛСӘМЕ!..

Айдар САДЫЙКОВ,
VIP-тамада



блогер: www.syuyumbike.ru

Кем генә үз туенда популяр артистны күрергә хыялланмый икән? Берәр билгеле шәхесне, танылган кешене бәйрәмгә чакыру җыелган кунаклар өчен шаккатмалы яңалыкка әйләнә! Ә инде программада берәр эстрада йолдызы чыгышы да булса, кичәнең фурор ясыйсын көт тә тор!

Бәйрәм оештыручылар Николай Басковны аеруча ярата. Ул җиңел аралаша, мәҗлес күңелле узсын өчен әллә ниләр уйлап чыгара, җырларын котлау сүзләре белән аралаштырып бара. Ни генә булмасын, Мәскәүдән йолдыз артистны чакырганда, тагын да кыздырып җибәрү өчен, гадәттә, аңа үзебезнекеләрдән берәрсен «беркетеп» куялар.

Алып баручы итеп А-реваны һәм «Комеди клаб»ның башка резидентларын чакыралар. Ләкин болар икесе ике әйбер: тел бистәсе булып сәхнәдән кеше көлдерү – бер нәрсә, бәйрәм чарасын алып бару – бөтенләй башка.

Шәхсән үземә кем белән эшләү рәхәт булды дисезме? Банкетка чакырылган йолдызлар икәнлекләрен һич истән чыгармыйча, билгеләнгән вакытка сыешып, тиз генә ерып чыгарга да ычкынырга дип эшләүче артистлар түгел, чын күңелдән җанын биреп, зал белән аралаша торганнары белән, әлбәттә.

Миңа Алсу Сафина, Ренат Ибраһимов, Сосо Павлиашвили белән дә, «Дюна», «Божья коровка», «Рок Острова» төркемнәре һәм Россиядә беренче МС диджей Сергей Минаев белән дә бер сәхнәдә эшләргә туры килгәне бар.

Лев Лещенко белән аралашудан, бәйрәмнәрне бергә алып барудан матур хатирәләр саклана. Виктор Салтыков («Кони в яблоках» хиты) һәм аның хатыны шулай ук профессионалларча эшлиләр. Бер яшь ханым иренә туган көненә – «Божья коровка», ә улы әтисенә «Мираж» төркеме чыгышын бүләк иткән иде.

«Я долго буду гнать велосипед...» («Букет») җырын башкаручы легендар Александр Барыкин исә һич тә банкетларда чыгыш ясарга яратмый, аны чакырып китертү өчен шактый тырышырга туры килә иде. Аның иң таралган җырлары – «Чудо-остров», «Аэропорт», «За той рекой».

«Ялла» төркеме исә 100 процент хитлар башкара! Алар биюле ике тәнәфес ясый-ясый иркенләп эшлиләр, җыр арасында ресторан буйлап йөреп, зал, кунаклар белән ихластан аралашалар. Өлкән яшьтәгеләр өчен «Веселые ребята» төркеменең һәр җыры җанга бәлзәм кебек – «Люди встречаются», «Розовые розы», «Арлекино»лар...

Сосо Павлиашвили чыгышын аеруча яраталар. 40 минут буена җанга якын җырлар яңгырап торсын әле! Гомумән, артистлар йә 40-50 минутлык зур бер җыр блогы әзерлиләр, яки 25 әр минутлык ике блокның һәркайсында өч-дүрт җыр башкаралар.

«Дюна» төркеме белән кызык хәл килеп чыкты. Алар кичкә 8 дә чыгыш ясарга тиеш иде. Заказ бирүче, халыкның әле күңел ачуга әзер түгеллеген чамалап, аларның чыгышын соңракка, икенче тәнәфескә күчерүләрен сорады. «Дюна» баш тартты. Гомумән, Мәскәүләргә алдан расланган график буенча эшләү хас. Мәсәлән, алар чыгыш ясау урынына килешү буенча 15 минут алдан килергә мөмкиннәр, ләкин һич тә кайчан чакырырлар дип, 2-3 сәгать буена борыннарын салындырып гримеркада көтеп утырмаячаклар инде! Аларның райдерын (шартларын) уку кызыклы. Бөтен бер коллектив өчен, мисалга, гомуми гримерка билгеләнә, ә солистларга – һәркайсына аерым. Артистларны тиешле урынга озатып баручы машинада, йөртүче һәм кабул итүче якның бер кешесеннән кала, чит кешеләр булмаска тиеш. Гримеркалар да сәхнәдән 15 метрдан да ерак булмасын, җырчылар коридордан узганда ятлар басып тормасын! Сәхнәдә махсус эффектлар, мәсәлән, сәхнә төтенен куллану тыела дип аерым язылган. Нинди дә булса предприятие яки сәяси партияләр рекламасы да тыела. Кемдер, Пресняков кебек, аерым маркалы виски сорарга мөмкин, ләкин Эвелина Хромченко капризларын үтәү ягыннан барысын да уздырды.

Кино йолдызы Дмитрий Харатьянны чакырганнар иде берчак. Баштагы 10-15 минуты күңелле иде әле, килеп фотога да төшереп тордылар, аннары кызыксыну югалды.

Җор телле сөйкемле Ургант – туйда бөтенләй башка. Чакырылган артистлар, безнең вәкаләткә керми, дип, кайбер нәрсәләрдән, мәсәлән, туй тортын чыгаруны игълан итүдән баш тарталар.

Яшьләр җыелган җиргә – Тиматины, юбилейларга Михаил Боярскийны, Маршал яки «Машина времени» төркемен чакыралар.

Казанда шулай ук «Оттаван» төркемен яки Адриано Челентаноны очратырга була. Соңыннан аның легендар итальян мачосына тышкы кыяфәте белән генә охшаган кеше булуы ачыклана.

Танылган йолдыз юбиляр яки кунаклар өстәлена утырсын дисәгез, артистка өстәмә 1.000 у.е. түләргә кирәк булмагае! Ул вакытта инде йолдыз сезнең белән чәкәшә дә ала.

Казанда Мәскәү йолдызларын көтеп алсалар, Мәскәүләрдә Казанныкылар бик кадерле була икән. Мәсәлән, бер юбиляр, әтисенең Илһам Шакиров җырларына мөкиббән икәнен белгәнгә, халык җырчысын бәйрәмгә чакырган. Илһам абый баянчысы белән алдан ук килгән, җырлаган, кунаклар белән иркенләп аралашкан. Аның райдеры иң тыйнагы – җырлар алдыннан бер чынаяк кайнар чәй. Салават Фәтхетдиновны да яраталар! Ләкин Салават акчага килми, ул бик яхшы танышына йә якын дустына гына килеп җырлый. Аның белән күп чараларда бергә эшләргә туры килгәне бар. Ә менә Салават кызының туенда мин үзем тамада булдым!

PRESSA.RU



АКТАНЫШ ДИГӘН ИЛ БАР...

АВЫЛ ТУРИЗМЫ БУЕНЧА БИШ МАРШРУТ ӘЗЕР АЛАРДА. ӘЛЛӘ КАЙСЫ ИЛЛӘРДӘН КИЛЕП КАРАП ЙӨРСӘЛӘР ДӘ, ЙӨЗ КЫЗАРЫРЛЫК ТҮГЕЛ.



Эльмира ЗАКИРОВА,
Фәнзилә МОСТАФИНА

Такталачык, Уразай, Иске Кормаш, Теләкәй, Татар Суыксуы, Мари Суыксуы, Зөбәер, Әтәс, Әлем, Байсар... Болары – без барасы авыллар. Фәнзилә – Такталачык, Уразайларны, мин – Байсар, Әлемне сайладык. Су юлы күрсәтү, бал мену, исем кушу йолалары белән танышулар, чигүләр белән бизәлгән татар йортына керүләр, чыбыркы уру, әтәч сугыштырулар, кыз куышлар, «Кичке уен»нарны тамаша кылулар, ак әбиләр белән очрашулар... Барысы да күңелне ымсындыра.








Сәфәр башы

Без Актанышка кайтабыз. Кемнәр өчендер ул – бару. Янәшәмдәге коллегам, журналист Фәнзилә Мостафина өчен, мәсәлән. Ә минем өчен – кайту менә! Без дигәнем – «Ак калфак» Бөтентатар иҗтимагый оешмасы вәкилләре. Татарстан районнарыннан, Россия төбәкләреннән, Таҗикстан, Беларусь, Польша, Казакъстан, Төрекмәнстан... Австралия кебек чит илләрдән килгәннәр. Җәмгысы 150 кеше. «Ак калфак» оешмасының Актаныште узасы халыкара семинары бик тә үзенчәлекле темага – авыл туризмына багышланган иде. Татар халкының йолаларын, гореф-гадәтләрен, шул якның күренекле шәхесләрен, авылларының тарихын һәм яшәешен өйрәнәчәкбез икән. Хәер, «Ак калфак» оешмасы җитәкчесе Кадрия Рәес кызы Идрисова үзе Актаныш кызы лабаса! Район хакимияте башлыгы урынбасары булып эшләгәндә үк шул эшләрнең башында тора иде инде ул. Әнә үзе дә! Балкып, юлчыларны барлап йөри.

Таң атканда ук кузгалдык. Кояш күзне чагылдыра. Иртән Актанышка кайтканда гел шулай. Кояш Актаныштан чыга.

Сөйләшә-сөйләшә, тирә-якны күзәтеп барабыз.

– Актаныште үзеңне чит илдә кебек хис итәсең икән...

– Анда һәр йорт, һәр гаилә ярыша-ярыша чәчәк үстерә, диләр...

– Актанышлар җырчы да, биюче дә, шагыйрь дә, спортчы да!

Беләм инде, юлдашым Фәнзилә хәзер җырчы Әлфия Афзалованы, шахматчы Алисә Галләмованы, шагыйрьләрне санап китәчәк...

Ә миңа аның Актанышны чит илгә тиңләве ошады. Чынлап та!..

Туган авылым Иске Байсардан биш кенә чакрымда бер авыл бар иде. Юкка чыкты инде. Гомергомергә «Морзалар утары» дип йөрттеләр аны. Өч төрбәле зираты гына да күп нәрсә сөйли. Уфадан, Казаннан пароходта ерак сәфәргә чыккан морзалар Әҗәкүл пристанендә төшеп калган. Агыйдел яры буенда аларны тарантаслы атлар көтеп торган. Кучер егет, атларны куалап, кунакларны шул авылга – Мәчтигә алып киткән. Алар кымыз эчәргә дип махсус килгән бирегә... Без, бала-чагалар да, бабакай җиккән ат арбасына утырып, әнә шул авылга – Мәчтигә утырмага барырга ярата идек. Юлда «Әүлия чишмәсе»ннән су эчәбез, күл камышлары җыябыз. Бәләкәй борынгы авыл бизәкле тәрәзә капкачлары, байларча ике яклы итеп салынган өйләре белән каршы ала...

Кыш көне, җәй көне, теләсә кайчан килегез Актанышка!

PRESSA.RU













«Шул авыл урынында ачык һавада яшьләр белән музей оештырачакбыз», – ди Кадрия ханым.

Авылда печән өсте. Авыл кешесенең бер минут вакыты юк! Ә кунакларны нинди югары дәрәҗәдә кабул иттеләр!

«Үдебеднекеләр...»

Мамадыш, Чаллы, Минзәләләр калды. Без һаман кояш чыккан якка таба җилдерәбез. Аккошлар иленә, торналар төшкән якларга. Әрәмәләр, балан-миләш куаклары, тал-тирәкләр арасыннан талгын гына агып ятучы Ык күренә. Кадрия Идрисова, экскурсовод ролен кучеп, бу якларның табигате, авыллары, кешеләре турында иркенләп һәм яратып сөйли:

– Без Минзәлә белән Актаныш районнарын аерып торучы Ык күперен кичтек. Актаныш дүрт зур елга иле дә ул. Көнчыгышта, Башкортстан чигендә – Сөн, төньякта – Агыйдел, аннары районда 12 чакрымлап җирдә Чулман дулкыннары уйный. Ундa – Пучы, элеккеге Калинин районы үзәге. Уфа юлы белән турыга китсәк, Пучыга Әнәк тоташа. Татарстанның Беренче Президенты туган авыл! Бик зур өндәүләр белән әйтә торган кешесе бар Актанышның! Минтимер Шәймиев! «Актаныш кешесе» булу зур җаваплылык сорый бездән. Читтә йөргәндә гел: «Минтимер Шәриповичка сәлам әйтегез!» – диләр миңа. Көн дә күрешеп торалар дип уйлыйлардыр инде... – Кадрия ханым көләкөлә сөйли: – Хөрмәт иткәнегезне, яратканыгызны беләбез. Без сезне аны яраткан өчен яратабыз! Күпләр теләгән искә алып, сәяхәтебезне Минтимер Шәймиевнең туган авылы Әнәктә тәмамларбыз... Әнәкләрнең тагын бер горурлыгы бар әле. Фронтовик-шагыйрь Нур Баян да шушы авылдан чыккан. Хуҗалык аның исемен йөртә... Сулда – Зөбәер. Монысы Лилия Муллагалиева, Эльмира Шәрифуллиналар авылы. Халык бу авылныкыларны, шаяртып, «Зөбәер кукыртлары» дип тә йөртә. Әлләкем булырга яратучыларны бездә шулай атыйлар. Сугыштан соңгы юклык чорында, ялтыравык галошлы аякларын тарантас читеннән салындырып, ирле-хатынлы берәүләр атта җыенга бара икән. Сер бирәселәре килмәгәндер инде: бер пар галошның сыңарын гына кигәннәр дә, оекбашлы аякларын күренмәслек итеп арба эченә яшергәннәр. Кушамат шулай берегеп калган...

Әтәс авылы янынан узганда, «Айкала суларыбыз, чайкала сула-

рыбыз», дип җырлап, композитор Азат Хөсәеновны, Чирү яныннан үткәндә «Керкәле таулары» җыры белән Рәис Нәгыймовны искә алабыз. «Әлфия апа Афзалова әйтмешли, барысы да «үдебеднекеләр»!» – дип шаярта Кадрия ханым, юри актанышчалатып. Автобуслар бердәнбер Чыныкта гына авыл уртасыннан үтә икән. Анысы инде Кадрия Идрисова авылы. Ел саен Казан тикле Казаннан «Карга боткасы»на кайтып йөргәч, гел әлләнидер инде ул бәйрәм!

Уңда – Кормаш. Өч халык рәссамы белән данлы авыл! Васил Маликов, Зилфәт Басыйров, Әсгать Сәфәргалиннар! Ардуан батыр да – шушыннан. Эчтәрәк – Иске Балтач, Яңа Балтач. Шагыйрә Фәйрүзә Мөслимова автобус тәрәзәсеннән каерылып-каерылып карый туган авылы ягына. Мин, үзем дә сизмәстән, «нәмә» дип, яшьрәкләргә «апаем» дип, «әем-мәем» кушымчаларын ялгап сөйләшүгә күчкәнмен икән инде.

Татарстанның көнчыгыш капкасы

Районның «Буләк» лагере туган телебез, милләтебез, гореф-гадәтләребез һәм йолаларыбыз сагында торучы эшлекле ханымнарны кабул итте. «Ак калфак» оешмасының Актаныш бүлекчәсе җитәкчесе Айгөл Галимҗанова үзенең командасы белән кунакларны каршылап, оештырып, озатып йөрде. «Ак калфак»ның күчмә утырышы үзебездә үтүгә мин бик шат, – диде Актаныш муниципаль район башлыгы Фаил Камаев, кунакларны сәламләп. – Без – Татарстанның көнчыгыш капкасы. Районда 31 меңнән артык кеше яши, 98 процентган артыгы – татарлар. Гореф-гадәтләребезне, телебезне саклап яшәргә тырышабыз. Һәр авылда «Ак калфак» оешмасы бар. Алар мәктәпнең, авыл җирлекләренең төп ярдәмчеләре».

«Ак калфак» Бөтентатар иҗтимагый оешмасы җитәкчесе Кадрия Идрисованың пленар утырышта ясаган чыгышы, анда яңгыраган аерым фикерләр уйландырырлык та иде.

«Халкыбызда «Алдын-артын җыештырып куярга кирәк» дигән мәкаль бар. Затлы әзерләнгәннәр, матур әзерләнү генә түгел, фикерле әзерләнү дип атала ул. Авылларның тарихы, һөнәрләре җентекләп күрсәтелде. Ихаталарда, аерым кешеләрдә булдык. Гаҗәп!.. Бөтен җитәкчеләр «Ак калфак»лар белән йөрде! Әллә эшләре юк дип беләсезме? Алар көннәр, төннәр буе безнең белән булдылар!..»

«Актаныштa көчле гимназия бар! 7 нче класстан соң төбәкләрдән, чит илләрдән укытырга җибәрергә була. Җиденчедән булса ни?! 5 яшьтән шахмат уйный белергә тиеш бала! Милли рухны, телне, моңны белеп үсәчәк алар! Актаныштa балаларны 3 яшьтән инде ясле-бакчалардан сайлый башлыйлар. Кайсы шахмат, кайсы бию, кайсы хоккей, кайсы рәсем буенча китә. Татар милли үзаңын үстерергә теләсәң, балаңны Актанышка гына җибәрерлек...» «Авыл туризмын үстерергә бөтен мөмкинлекләр бар Актаныштa. Сез аны күрдегез инде. Ял вакытларында килегез Актанышка».

...Бер көнне Агыйделдә паромда йөздек. Әллә нинди сәяхәтчеләр дә көнләшерлек! Күз алдына китерәсезме: су өстендә акчарлаклар уйный, җыр, музыка яңгырый! Бер ярда – Башкортстан җирләре, икенче якта – Актаныш... Утрауларда – балыкчы өйләре... Вальска әйләнәбез. Кадрия Рәес кызы халыкка «Карабай» күмәк биюен өйрәтә. (Ул үзенә күрә мастер-класс та булды! Кичә Кадрия ханым бер җәем токмачны тиз-тиз генә нечкә итеп кисеп тә мастер-класс күрсәткән иде!..)

Ә кичен атаклы «Агыйдел» дәүләт җыр һәм бию ансамбле концертын тамаша кылабыз. Актаныш баянчыларына кушылып җырлап, Актаныш басмаларыннан аръякка чыгу кадәресе инде төнгә кала. Суда ай, йолдызлар, көймәләр чайкала...

(*Дәвамы киләсе санда.*)



Фатих СИБАГАТУЛЛИН, Россия Федерациясенең җиденче чакырылыш Дәүләт Думасы депутаты, «Бердәм Россия» фракциясе әгъзасы:

«Авыл туризмы шәһәр яки чит ил туризмы белән көндәшлеккә сәләтле, хәтта кайбер яктан аларны узып та китә ала. Кала кешеләренең хәзер авылга мөнәсәбәте үзгәрә башлады: авылда иркен йортлар сатып алалар, кайтып йөриләр, бөтенләй шунда яшәргә күченүчеләр дә күп. Шуңа мөнәсәбәтле рәвештә чит ил кешеләренең дә кызыксынуы арта. «Авылда бер көн»ише дөньякүләм проектлар шуны дәлилли.

Татарстанда авыл туризмын үстерү буенча җитди эшләр башкарыла. Болгар белән Зөяне торгызалар, Биләр җирлеген популярлаштыралар. Бу бик яхшы күренеш. Авыл туризмын тагын да үстерү өчен аларда фән учаклары булдырырга кирәк. Университетлар зур шәһәрләрдә булмаска тиеш. Калада хакимият органнары урнашкан, бөтен җитәкчелек шунда кайнаша – шулай булгач, аларда бар игътибарны фәнгә юнәлтүе кыен. АКШта ничек: хакимият органнары – Вашингтонда, Нью-Йорк бизнес шәһәре санала, ә Бостон – фән каласы, танылган Гарвард университеты да шунда. Без үзебезнең тарихны белмибез. Югыйсә Идел Болгары заманында бездә дә шундый ук бүленеш булган бит: Биләр – хакимият органнары тупланган шәһәр, Болгар – эшмәкәрлек каласы, ә хәзерге Нурлат районындагы Кизләү авылы – мәдрәсәсе белән дан тоткан фән үзәге. Хәзер яңадан шул системаны кире кайтарырга кирәк. Бу юнәлештә эш башланды инде: Болгарда Ислам академиясе булдырылачак. Зур уку йортларын авыл яки район җирлегендә салу ике куянның койрыгын тотарга мөмкинлек бирәчәк. Бердән, юк-барга бүленмичә, фән белән шөгыльләнү мөмкинлеге булса, икенчедән, инфраструктура да яхшырачак: авылларда юллар салыначак, гыйбадәт урыннары булдырылачак, тарихи кыйммәткә ия урыннар рәткә китереләчәк. Авыл туризмы үсеш алсын өчен шул кирәк тә инде.»

Фото: Алмаз Закиров, Илгиз Шәкуров


PRESSA.RU

«ЯРАТЫП ТУЙМЫЙЧА КИТӘБЕЗ...»



ӘНГАМ АТНАБАЙ ҺӘМ ГӨЛЧӘЧӘК ӘДҺӘМОВА. ДӨНЬЯДА ҮКЕНЕЧЛЕ МӘХӘББӘТЛӘР, БӘХЕТЛЕСЕНӘ КАРАГАНДА, НИГӘДЕР КҮБРӘК... КҮҢЕЛЛӘР НИКАДӘР БЕР-БЕРСЕНӘ ТАРТЫЛСА ДА, ТОРМЫШТА УЗЫП БУЛМЫЙ ТОРГАН КИРТӘЛӘР БАР.

Гөлнур САФИУЛЛИНА



Икәү төшкән фоторәсемнәре берәү генә аларның (аны без узган саныбызда биргән идек). Шагыйрьнең, Гөлчәчәген эзләп, Биектау районы Мүлмә авылына килгән чагы. Кыз күңелендә өмет учагы кабызыр да кабат китеп югалыр ул... Көткән кешесенең килмәслеген белеп көтүнең авырлыгы Гөлчәчәккә инде таныш... Шуңа да якыннардан-якыны янәшәсендә чакта да күзләрендә моң, сагыш аның. Тагын үпкә, көтү, сагыну, гаҗиз булу, аңламау...

Еллар үткәч, балалар да үскәч, / Хатларың да синең килмәгәч, / Карточкаңа карап, йөзеңне дә, / Күзеңне дә синең күрмәгәч, / Онытты дип, бөтенесе дә тынды, / Йөрәк кенә ләкин тынмады; / Онытырга күпме тырышсам да, / Юк, барыбер онытып булмады!

«Гөлчәчәккә» дигән бу шигырен Әнгам Атнабай 1960 елны яза.

Ничек кенә оста ямасаң да, / Эзе кала икән яраның. / Бөтенләйгә сине онытыр өчен / Барысын да эшләп карадым, – дип башлана ул. Гомере буе янәшә барган юллары анда – чиксезлектә кавыштымы икән?

Инде хатлардан өзекләргә күчик.

(Ахыры. Башы журналыбызның 7 нче санында.)

«**17 декабрь, 52.** Уфа. Гөлчәчәк! Гади генә дустым булсаң, мин бернинди дулкынланусыз җавап язар идем. Андый хатларны язудан рәхәтлек табасың. Ә сиңа? Синнән хат алу һәм сиңа хат язу – миллион газап, миллион тапкыр өзгәләнү, рәхимсез рәвештә йөрәк итен ашау, күпме авырлык! Чөнки син минем гади генә дустым түгел идең һәм бүген дә алай түгел. Шулай итәргә кирәк, ләкин мин булдыра алмыйм, минем хыялланунаң хәзер перспективасыз икәнлегенә күнегергә кирәк, ләкин мин күнегә алмыйм. Юк, булмый! Үземнең мәхәббәтемнең шулай көтмәгәндә чәлпәрәмә килүенә ышана алмыйм, юк, ышана алмыйм! Синең һәм минем ялгышу сине дә, мине дә, Сәвияне дә бәхетсез итте һәм тагын бер кешене бәхетсез итүе мөмкин (хәер, ул сине яратса, бәхетле булачак). Озакламый мин ата булырга торам, һәм ул бала да бәхетсез булыр. (Кыз булса исеме Гөлчәчәк булачак. Шәпме?)

P. S. Отпуск алсам, бәлки барырмын. Каршы килмисеңме?»

«**30.12.52.** Гөлчәчәк! Әле генә Уфаның К. Маркс урамында йөреп кердем. Тышта күбәләк кар ява. Вакыт соң инде. Бары тик култыклашып соңгы сеанстан кайтучы «парочкалар» гына очраштыра. Күңелсез... Мин редакциягә кердем һәм синең белән сөйләшәсем килде... Ярый әле мин сине очратканмын, ярый әле мин сине яратканмын. Әгәр мин синең мәхәббәтең белән янмасам, һәм ул мине гел рухландырып тормаса, әгәр ул мине көн дә газапламаса, миңа бик-бик авыр булыр, мин буш мичкә кебек булыр идем. Шигырь язарга утырсам, син киләсең дә мине иркәлисең кебек, сүзләр табылмаса, әйтәсең кебек, истән чыккан фикерне хәтергә төшерәсең кебек. Рәхәт булып китә. Һәм карыйсың: син юк... Ләкин миңа синең дөньяда яшәвең рәхәтлек һәм көч бирә. Бәлки шул үзе мәхәббәт дип аталадыр.

С.не аерырмын (чөнки анысы хәл ителгән, бала гына тоткарлык ясады), ләкин миңардан нинди кеше кала? Йөрәгең белән ничаклы изге, саф булма, ләкин мин совет семьясын бозучы булам. ...Ә тышта һаман күбәләк кар ява. Тынлык. Син йоклыйсыңдыр инде. Сәгать иртәнге 4...

Мин үзем турында барысын да сөйләдем. Әни һәм бала-чагалар таза-исәннәр, хатлары килә. Әнкәй минем өчен бик борчылган һәм хәзер дә борчыла. «Гөлчәчәкнең хатларыннан монда бер-икесе калган, Зинирадан шуларны укыттым да, җыладым», дип язган. Ана бит!»

«**26 ноябрь, 53. Уфа**. Безнең арадагы мәхәббәт сүнеп бетмәгән яки дөрләп китмәгән учак кебек, һаман яши, ныклап уйласаң, һаман тирәнгәрәк керә, тамырларын киңрәк җәя бара. ...Мин сине онытырга теләмәдеммени? Теләдем. Ләкин йөрәкне көчләп буламы соң! Йөрәк бит ул! Йодрык кадәрле ит кисәге, ә үзе никадәр көчле, шайтан алгыры!

Антей үзенең анасыннан көч алган. Ул анасыннан аерылса – көчсез. Нигә, кешеләр шулай түгелмени? Аларның куәт чыганагы юкмыни һәм булмаска тиешмени? Бар һәм булырга тиеш. Ул чыганак – мәхәббәт (ә гомумән). Аерым алганда да шулай. Мин иң кыен вакытларда сине күз алдыма китерәм. Син башта томан артыннан беленер-беленмәс кенә карап торасың да, кыюсыз гына адымнар белән миңа якынлашасың. Ниһаять, син минем янымда. Һәм син үзеңә генә хас йөрәк тавышың белән диктовать итәсең:

Күпме күзләр тутырып карамады, / Күпме кашлар уйнап сикерде, / Күп очрады кызлар, / тик берсе дә / Түгел инде синең шикелле. / Башкаларны никтер күңел тартмый, / Башкаларны йөрәк ятсына. / Йөрәк бит ул, / ә гардероб түгел, / Саклап булмый анда барысын да...

Синнән башка гомерем ямьсез минем,
Синнән башка мин ул минмени?

Һәм миңа ничектер җиңел булып китә. Яраткан кешеңне үз яныңда тоюдан да ләззәтле бернәрсә юктыр бу дөньяда! Ләкин һәрнәрсәнең – начармы, әйбәтме, күңелсезме, күңеллеме – финалы була. Монда да шул финал булырга тиештер бит? Ул бары тик миңа гына түгел, сиңа да бәйләнгән. ...Бер генә тапкыр рөхсәт ит: үбеп: Әнгам.»

«**Уфа. 27 дек. 1953 ел.** ...«Үз йөрәгеңне, якын кешенең йөрәген канәгатьләндерү өчен берәүне утка, газапка ташлау эгоистлык булмасмы?» – дип сорыйсың. Ә нишләргә соң миңа? Нишләргә? Болай да бит ул утта, газапта. Ул бит минем белән булса, гомере буе шушы утта янарга тиеш булачак, гомере буе үзенең мәхәббәтенә взаимный мәхәббәт таба алмаячак һәм шуның белән газапланачак. Болай, ичмасам, ут-ялкыны булыр да, гомергә булмас. Ул мәхәббәт белән яшәргә тиеш кеше түгелмени? Кешеләр ялгышмыйлармыни?

«Бөтенесеннән дә җаваплысы, куркынычы, йөрәк әрнеткече – бала» дисең. Дөрес. Мин дә монысын күз алдыма китерә алмыйм. Тик шулай да мин аны үземнән аермаячакмын, ул минем белән бәхетлерәк булачак, ничә әйтсәң дә, минем күңел нечкәрәк... Ярый, сау бул. Ә хәтерлисеңме, без 1949 елны ничек каршы алган идек?»

«**7 фев. 54. Уфа.** Гөлчәчәк! Бүген ял көне. Иртән үк редакциягә килдем дә берүзем язып утырам. «Нәрсә язасың?» дип сорасаң әйтәм: «Сынау» исемле озынрак әйбер. Проза түгел. Синең исемне (Гөлчәчәк) алдым, гафу ит. ...Әчтәлегенә карата фикереңне яз, ярыймы?.. Зинира килеп керде дә (ул монда, редакциядә эшли), шушы хатны укып чыкты. «Миннән бик күп, бик зур сәлам яз», – диде һәм сине кунакка чакырды. Хәзер түгел, ә җәй көне, ул авылга кайткач. «Шул вакытта Күрдемгә килсен, обязательно килсен», – ди. «Мин аны үз апам кебек кадерләп йөртер идем», – ди.

PRESSA.RU

Аның бу теләген мин дә хуплыйм. Безнең авыл бик матур ул, аеруча җәй көннәрен бик матур: яшеллек!... Ун көн эчендә күп кенә үзгәрешләр булды. Иң әһәмиятлесе: поэманы бетердем. Язучылар союзында укыдым: яраттылар һәм «Әдәби Башкортстан» журналына тәкъдим иттеләр, ләкин анда бирәсе килми. ...Сау бул. Эшеңдә уңышлар, үзеңә сәламәтлек теләп, үбеп (чөнки сагындым): Әнгам.»

«**1 март, 54.** Гөлчәчәгем! Башта ук искәртәм: ашыгып язам, иртәгә командировкага китәм. Кайтасы, хәзерләнәсе бар, ә мин бары тик сиңа хат язар өчен генә редакциягә килдем. ...Бер хат турында хәтергә төшерәсең. Мин анда чын кешеләрчә уйлап карарга

Бу дөньяның көзләре дә матур,
Син булганга шулай матур ул.

кушкан идем. Дөрес кушкан идем һәм бик вакытлы, чөнки ул миндә өлгереп җиткән иде. Ләкин син соңладың уйлавың белән дә, карарың белән дә соңладың. Син анда «мин уйлаган идем, тик син эзсез, суга төшкәндәй югалдың» дисең. Шулаймыни? Эзсез, суга төшкәндәй? Белмәгән идем, монысы минем өчен яңалык. Бәлки... Тизрәк күрешкәнчегә кадәр: Әнгам.»

«**27 август, 54.** Уфа. Саумы, Гөлчәчәк! ...Миндә дә бит теләк бөркет кебек очарга, очарга, очарга иде! Булмады! Казан! – булмады! Бөре! – булмады. Уфа! – тагын булмады. Нишлисең? Димәк, бу очу минем кулдан килми дигән сүз. Кабындым, ләкин ялкынланып, дөрләп яна алмадым. Яна алмагач, сүнәргә кирәктер. Һәм шушы «булмады»лар өстенә мәхәббәт трагедиясе! Яраттым һәм яратылдым, ләкин үз бәхетемне үзем кистем. ...Син – саф, керсез, гөнаһсыз, ә миндә хәзер күпме пычраклык, күпме гөнаһ, күпме каргыш! Юк, мин инде сиңа тиң түгел. ...Хатың өчен зур рәхмәт. Аңлыйм, ләкин нишлим, Гөлчәчәк? Оныт, дияр идем, алай дию белән генә онытып булмыйдыр ул... Күзләреңә карап: Әнгам».

«**30 август, 54.** Миндә яңалык бар. Без – яшь башкорт язучысы, «Огонек» журналында бер хикәясе чыккан талантлы гына Денис Исламов дигән егет белән Яңа елга каршы Казанга барырга хәзерләнәбез. Монысы инде буш фантазия генә булмаска тиеш. Шул турыда сүз булгач та бер хатыңда ясап җибәргән картаны алып карадым һәм очрашуны күз алдына китереп утырдым. Кызык очрашу булачак, ә? Ничәмә еллардан, нинди вакыйгалардан соң!

Хатның ахырын бик пессимистларча бетергәнсең. Шуны уйлап караганың бармы, Гөлчәчәк, безнең хатлар кызык кына килеп чыга: без һәрвакыт берберебезне юатышабыз. Синдәге хатлар белән миндәгеләрнең бер-берсенә җавапларын чагыштырып чыгасы иде. Кызык тарих килеп чыгар иде.»

«**19 июль, 56.** Мин синең хатыңны алдым, ләкин озак кына җавап язмый йөрдем. Дөресен генә әйткәндә, җавап язмыйча кала алырмын шикелле иде. Күрәсең, язам. Димәк, сиңа җавап язмыйча калдыра алмыйм икән. Ул гына да түгел... Ярый, мин бу хатны башлаганда ук «бик эшлекле, официаль хат кына язармын» дип үз-үземне ышандырып куйган идем. Сүземдә тормыйм әле. Мин һаман да редакциядә эшлим. Быелга гына түгел, үткән елга да отпуск алмаганмын. Менә бер атнадан, һич югында 1 августтан отпуск алам. Алгач та, алган сәгате белән үк телеграмма бирермен. Көтсәң, барырмын. Обязательно, валлаһи-билләһи барырмын!!! Монысы инде чын булыр!

Гөлчәчәк! Мин әле күптән түгел генә шундый шигырь язган идем:

Очраттым да/ мин югалттым аны. / Якындадыр, бәлки еракта. / Бәхетеңне табуы да кыен, / Югалтуы авыр бигрәк тә. / Мин югалттым аны – сөйгәнемне. / Аңа тиң булганнар юк бүтән. / Очратсагыз «сине көтә» диеп, / Әйтегезче, дуслар? / Мин көтәм.

Нәрсә язсам да, мин барысын да сине күз алда тотып, сине уйлап иҗат иттем, һәм ул киләчәктә дә шулай булачак.»

«**3 сентябрь, 56.** Күрдем. Үткән атна-ун көн эчендә булган вакыйгалар минем өчен дә, сиңа да шулкадәр яңа һәм еллар буена көтеп алынган булса да, һич тә көтелмәгән, алдан уйланмаган шикелле. Ләкин уйлыйм-уйлыйм да, иң мөһименә шатланам – без берберебезне элеккегедән дә ныграк аңлый башладык һәм бер-беребездән разочароваться итмәдек булса кирәк, киресенчә, бер-беребезне тагын да көчлерәк, аңлы рәвештә яратуыбыз тирәнәйде шикелле. ...Без начар эш эшләргә җыенмыйбыз. Үз бәхетебез өчен көрәш, башка кайберәүләргә бәхетсезлек китергән хәлләрдә дә, изге үк көрәш булмаса да, бөтенләй мәгънәсез көрәш түгел.

Хәзер авылда гына ятам. Теге очеркны редакциягә җибәрдем. Кичә тагын бер материал яздым. ...Авыл кичләре бик матур һәм ямансулата, бик сагынам, хәтта кирәгеннән артык. Менә шул. Тизрәк – Уфага, расчет, аннары кире авылга һәм... Гомумән, барысы да бер дигән булырга тиеш. Тик исәнлек кенә теләлә. Сау бул. Нык кысып һәм кайнар үбеп: Әнгам.»

«**Күрдем. 10 сентябрь, 56.** Менә берничә көн рәттән яңгыр ява, беркая чыгып булмый, читлеккә ябылган арыслан шикелле тик ятам. ...Син җитмисең миңа! Йокларга дип ятам да, күз алдына сине китереп, сөйләнергә тотынам. ...Сәгать бер була, ике... өч... Ә мин һаман йоклый алмыйм. Кайчакта сине үз янымда, кырымда итеп тоям, тәнең тәнгә тигән шикелле була, һәм тагын сискәнеп уянып китәм... Торып утырам, тартам... Бер-бер артлы өч-дүрт папирос... Ятам... тагын синең белән бергә...»

«**23 сентябрь, 56.** Уфа. Синең хат, нигездә, бер нәрсәгә – мине практик эш итмәүдә гаепләүгә кайтып кала. Гөлчәчәк, син минем иптәшем, хатыным булгач та, мине шул хакта күп, бик күп тапкырлар гаепләрсең әле: әрләрсең, битәрләрсең, ачуланырсың.

Минем иң зур кимчелегем – үзем турында кайгырта белмәү.

Ярый, практик эш булгач, практик эш булсын. Беренчедән, мин бит сиңа сентябрь аенда бөтенесен хәл итәргә һәм синең янга барырга вәгъдә бирмәдем. ...Ким дигәндә бер ай эшлим (башкача ярамый, редакция алдында намуссызлык булыр иде); аерылышу мәсьәләсен хәл итәргә кирәк (шул вакыт эчендә, әлбәттә); авылга кайтам (әнкәйгә шулай дидем); үзебезнең районда яки Яңавыл районында эш турында сөйләшеп карыйм. Их, син түземсез, җиде елын көтте, ике-өч ай көтәргә түземе җитми, кара син аны.

Икенчедән, әниең турында. Мин аңа зарар китерергә һәм синнән аерырга теләмим. Юк, теләмим! Син һәм ул ничек тели, мин шуңа да риза. Мүлмәгә барырмын, син анда эшләрсең, мин Казанда «попытаться» итеп карармын, әзрәк дус-ишләр бар бит әле. Булмаса, аена 700-800 сумны мин болай да эшли алам. Син әйткәнчә, укырмын. Син риза икән, мин монысына да риза.

Өченчедән, миңа ышанмыйсың. Монысы инде вәгъдәләр, сүзләр белән генә эшләп була торган нәрсә түгел. Бары шуны гына әйтә алам: хәзер мин «Гөлчәчәк кияүгә чыккан» дигән сүзгә дә, «Әнгам, хуш. Мин инде икенче кешенеке» дигән хатыңа да ышанмаячакмын. Бары тик барып, үз күзләрем белән күрсәм генә ышаначакмын; юк, анда да болай, тыштан гына.

...Үземдә рух күтәренкелеге, җиңеллек хис итәм. Җырлыйсы килә. Кешенең барыр юлы билгеле, максаты ачык булганда шундый настроение дә була бит! Ничектер, синең янга барып кайту күп кенә пычраклыкларымны, үзең язганча, кабахәтлекләремне югандай булды. Синең ышанычлы (мин һаман ышанычлы дип язам әле!), мәхәббәт белән тулы күзләрең миңа терек суы бөреккәндәй булды. Ярый, сау бул. Гайбәтләргә төкер, гамьсезрәк бул, минем турында миңа караганда күп уйлама. Сагынып һәм үбеп: Әнгам.»

«**Күмертау. 9 октябрь, 56.** Мин хәзер синнән бик ерак: Башкортстанның иң көньяк районнарының берсе Куергазы районында командировкада булдым. Бүген кайтырга җыенып, көн буе машинада килдем һәм чак-чак Күмертау шәһәренә – яңа үсеп һәм калкып килә торган күмерчеләр үзәгенә килеп җиттем. ...Арытты, йончып беттем, күзләр үзләреннән-үзләре йомыла. Хәзер өч тәүлек йоклаган юк дияргә була.

Хат яз. Минем фикерләр ягыннан үзгәрешләр булганы юк. Үзеңдә хәлләр ничек? Менә бу вокзалда утыру безнең Арчадагы вакытны искә төшерде, шуңа хат язасы килде. Их, ул юллар! Нигә шулкадәр яратам – белмим! Каберем дә юлда булыр, ахры?

Сау бул, Гөлкәй! Хат яз. Сагынам мин сине. Бөтен нәрсәм дә бар кебек, һәм бернәрсәм дә юк шикелле. Үбеп: Әнгам. Әнә поезд пошкыра. Тагын юлга.»



Язманың тулы вариантын сайтның «Мәдәният. Шәхес.» сәхифәсендә укыгыз.

САБАНТУЙ АДЫМНАРЫ




Җәйнең кыл уртасында – 15-16 июльдә Нижгар шәһәрендә XVI Федераль Сабан туе уздырылды. Хәер, борынгы татар-болгар җирендә мондый киң колачлы, илкүләм Сабантуйның соңгы ун елда икенче мәртәбә үткәрелүе инде бу. VI Федераль Сабантуй да 2006 елда Нижгарда оештырылган иде. X-XI гасырда биредә – Ока елгасы Иделгә койган төштә – Болгар ханлыгының чиген саклаучылар яшәүче Җүн кала дигән шәһәр-кирмән торган. Шуңа күрә ун гасырдан соң Сабантуйның бабаларыбыз дәүләт тоткан җиргә әйләнеп кайтуы белән дә истәлекле, кадерле бу вакыйга.

Унбер гасыр элек Ибраһим хан (Җүн каланы икенче төрле Ибраһим шәһәре дип тә йөрткәннәр) биләмәләрен барлап йөрсә, бу көннәрдә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов, Түбән Новгород өлкәсе губернаторы Валерий Шанцев белән, бу туфракта борынгы заманнардан бирле гомер сөрүче милләттәшләребез белән очрашып, мәшһүр җырчылар Рәшит Ваһапов белән Хәйдәр Бигичевка һәйкәл ачуда катнашты; Нижгар шәһәренең үзәгендәге «Локомотив» стадионында өлкәдә дус, тату гомер сөрүче татар һәм русларны, башка халыкларны Сабантуй бәйрәме белән котлады. Мәгълүм булганча, әлеге урында XIII гасыр башында руслар Түбән Новгород кирмән-каласына нигез салган.



PRESSA.RU



Рәмилә Риф кызы ХИСАМОВАның кинематографиядә башта тавышы гына ишетелә. 2004 елда ул Голливуд киноларын «сөйләтә» башлый: «Дьявол и Дениел Уэбстер» фильмында Иблис тавышын, мәсәлән. Шуннан башлап, ул 48 фильмны русча «сөйләтә». Соңгыларыннан – «Киллеры» һәм «Лузеры». 2005 елда «Оперативный псевдоним-2: Код возвращения» фильмында Герда ролен башкара. Шуннан соң «Эксперты», «Хиромант-2», «Предлагаемые обстоятельства» сериалларында һәм соңгы елларда тагын дистәгә якын фильмда төшә. 2015 елда «Людмила Гурченко» (Зинаида Кириенко), «Провидица» (Александра Львовна) киноларында уйный.
Театр актрисасы буларак, Мәскәүдә беренче тапкыр үзен Чехов героинясы итеп күрсәтә: «Вишневый сад»та – Дуняша. Аннан соң «А зори здесь тихие...» (Женя Комелькова), «Алые паруса» (Ассоль), «Берег утопии» (Катя) спектакльләре театр сөючеләр арасында Рәмиләгә танылу китерә.



РӘМИЛӘ ИСКӘНДӘР



ТОРМЫШ ЮЛЫ

Рәмилә 1977 елда Чиләбе янындагы Кунашак авылында туган. 6 яшенә кадәр татарча гына сөйләшкән – русчаны белмәгән. Әтисе – инженер, әнисе – укытучы, Рәмилә үзе кечкенә вакытта ветеринар, аннан соң укытучы, икътисадчы булырга ниятли, мәктәпне тәмамлаганда, кинәт кенә Чиләбе сәнгать институына укырга керергә була. Студент чакта яшь тамашачылар театрында эшли башлый, соңгы курстан Чиләбе драма театрына күчә. 2002 елда Мәскәүгә кунакка барган җиреннән шунда кала: Станиславский театрында эшли башлый. Хәзерге вакытта төп эш урыны – Россия академия яшьләр театры. 2013 елда улы Тимур туа.



ПАТША БЕЛӘН ПАТШАБИКӘ

Рәмиләнең зур кинодагы дебюты – аны Павел Лунгинның «Царь» фильмында Явыз Иванның (Петр Мамонов) хатыннарының берсен – борынгы кавказ ыруы кызы, чибәр Кученейны уйнарга чакыралар. Чукындырылгач, Мария Тәмрук кызы булып китә.
«Царь» фильмы 2010 елда Россиядә һәм Белоруссиядә экраннарга чыга. Канн фестивалендә катнаша, Мәскәүдәге халыкара кинофестивальне ачып җибәрә.



КИНО ТӨШЕРҮ ТАРИХЫННАН

Кино Суздальдә төшерелә. Явыз Иванның үз-үзен тотышындагы патологик кырыслык Россиядә, Европада ахыр заманны көтү белән бәйле, дип аңлата режиссер Павел Лунгин. Шуның өчен, Бабил манарасына охшатып, тәрәзәсез сарай төзетә. Тәрәзә юк – дөнья бетте. Сарайның ишегалдында мәйдан бар. Явыз Иван анда кешеләр өстенә аюлар җибәрә торган була. Ерткычлар кешене тураклап, кошлар чукып бетергәч, кешенең җәсәде дә, димәк, терелер җисеме дә юк дип саный.




КАСТИНГ ТУРЫНДА

Рәмилә Искәндәр бу кинога очраклы гына килеп эләктем ди. «Кастингларга йөрергә яратмыйм. «Мосфильм» коридорыннан үтеп бара идем, актерлар сайлау белән шөгыльләнә торган Татьяна Максакова фотопробага чакырды. Аның мине «Берег утопии» спектаклендә күргәне булган. Грим салдылар, башыма ниндидер башлык кидерделәр. Үзеңдәге иң түбән хисләрне уят, агрессия кирәк, диделәр. 39 температура белән килгән идем, ахырга таба төшем белән өнем буталган кебек тоела башлады. Шунда Павел Семенович: «Булды, котлыйм!» – ди. Мин елыйм, тилереп көләм. Кино турында хыялымда да юк иде бит!»



РОЛЬ ТУРЫНДА

Кученей тормышта бик кырыс холыклы була. Атасы тәрбиясендә үскән кыз атта чаба, Явыз Иван белән дә ауда таныша. Ул рус патшасының корбанын кулыннан диярлек тартып ала. Патша башта аны ир кеше дип кабул итә, кафтанын аерып төшергәч, чибәр кыз икәнен күреп ала.
«Грим сала башлауга үз эчемә бикләнә идем. Һәрбер явызлыкның беренчел чыганагы була – шул чыганакка үтеп керергә кирәк. Миндәге усаллык Явыз Иванга да күчә. Дөресрәге, без бер-беребезне тулыландырып тора торган шәхесләр. Бу җәһәттән Петр Мамоновны (Явыз Иван) аңлау катлаулырак булды. Әмма без беренче көннән үк аңлаштык, җиңел эшләдек.



ЗУР КИНОДАН СОҢ

Кинодагы шаукымлы рольдән соң тынлык урнаша. «Мин ул тынлыктан курыкмыйм. Театрым кала, анда яхшы рольләрем бар. Театр актрисага көч бирә, ә кино, киресенчә, суыра. Вак-вак атлап чапканчы, эре адымнар ясавың хәерлерәк. Мондый фильмнар күп булмый – мин моны бик яхшы аңлыйм», – дип шәрехли ул «йолдыз»ларга таба юлын.

Фотолар төрле матбугат чараларыннан алынды

PRESSA.RU

АККОШ КАНАТ КАГЫНА

Ландыш
ӘБҮДӘРОВА

ӘЛБӘТТӘ, КАНАТ ҖИЛПҮЕДӘЙ ҖИҢЕЛ ХӘРӘКӘТЛӘР АРТЫНДА ОЗАК ЕЛЛАРГА СУЗЫЛГАН ХЕЗМӘТ, ҮЗ-ҮЗЕҢ БЕЛӘН КӨРӘШ, ҺӘМ ЕШ КЫНА ЕРАКТАГЫ ЯНАР УЧАК БУЛЫП БАЛКЫГАН МАКСАТ ХАКЫНА ҮЗ-ҮЗЕҢНЕ ҖИҢҮЛӘР ТОРА.



Жәйге челлә көн төнгә авышып бара иде. Көн буе әлсерәп йөргәннән соң, йокы да тиз генә алмый, ялкау гына телевизор пультына басып, каналлар алыштырам. «Культура» каналында – балет. Экранда япь-яшь балерина каурый кебек оча гына. Балеринаның дәрте, пластикасы, сыгылучан сыны, осталыгы һәм, ниһаять, сихри музыка үзе – бер мизгелдән мин дөньямны онытам. Күз алдында рус классик балетының тере үрнәге, шул ук вакытта балеринаның яшьлеге, хәтта ки, әйтер идем, балалыгы, хәрәкәтләрендәге табигыйлык катыш төгәллек магнит кебек үзенә тарта. Партнеры – азиат кыяфәтле балерун исә бөркет кебек. Аның ташып торган көче, алмаздай кырланган чиста хәрәкәтләре сокландыра, үзенә тулысы белән ышанган балеринаны бәллүр гөлсар кебек сак тотып йөртүен тын алырга да онытып күзәтәм. Па-де-де тәмам. Алып баручы биючеләрне жюри хөкеменә тапшыра. Шунда мин «Культура» каналының «Зур балет» проектына юлыкканымны аңлап алам.

2016 елгы сезонда җиңүче парның беренче чыгышы булган ул. Алып баручылар биючеләрне игълан итә:

– Рената Шакирова – Кимин Ким. Мария театры (Санкт-Петербург)!

Бу чыгыштан соң әле бернәрсә дә билгеле түгел. Рената белән Киминнең җиңәчәге дә, шушы араларда яшь балеринаның Мария театрында кордебалеттан солистлыкка күчәчәге дә. Бер генә нәрсә аермачык булып ярылып ята: Ренатаның күзләрендә чагылган ихтыяр көче.

Әнә шулай «таныштым» мин Рената белән. Башкала театрларының балет солистлары арасында татар фамилияләрен сирәк ишетергә туры килә. Рудольф Нуриев, Ирек Мөхәммәдов... Диана Вишнева бер әңгәмәсендә әнисенең тамырларында татар каны агуын әйткән иде. Шакирова фамилиясен ишетүгә тизрәк интернетка чумам (энже эзләүче мин!). Яшәсен Гугл – икенче мизгелдә мин Ренатаның социаль челтәрдәге сәхифәсендә. Үзе – онлайнда. Кыенсынып кына сүз катам...

– Әйе, татар кызы мин, – дигән җавап килә. Ә берничә көннән Рената репетицияләр белән шыплап тулган тыгыз графигыннан әңгәмә өчен вакыт таба.

А. Я. Ваганова исемендәге рус балет сәнгате академик училищесының көзгеле заллары (ул заллардагы иерархия баскычларында гына да күпме чыныгу үтелгән, күпме ихтыяр көче тупланган!), туздырып ташланган дистәләгән пуантлар... Ваганова училищесы турында риваятьләр йөри: рус балет сәнгате мәктәбе кыршау кебек. Анда бары тик классика. Беренчедән, 10-11 яшьтә син инде – студент. Икенчедән, биредә төп принцип: «кыйный – димәк, ярата», ягъни педагоглар сиңа карата битараф булса гына, «бәйләнми». Ә прима булырга хыялланган үсмернең кайсысы гына үзенә карата битарафлыкка түзәр? Ваганова училищесын тәмамлаганнар «Большой» белән «Мариинка»да үзенә эш таба ала, анда булмаса, аларны чит илдә дә колач җәеп каршы алалар: ни дисәң дә, сыйфат! Өченчедән, ел саен биредә 18-20 урынга 200 ләп кеше дәгъва итә. Рената исә Санкт-Петербургка Башкортстанның Стәрлетамак шәһәреннән килә. Кабул итәләр икән – яхшы, алмасалар да үкенечле түгел. Аны Уфаның Р. Нуриев исемендәге хореография училищесында көтәләр инде. Менә шулай кесәдә «запас» булганда, үзеңне, бәлки, ышанычлырак та тотасыңдыр?

Ренатаның бәхет йолдызы дигәннән. Берничә буын мөгаллимнәр гаиләсендә туган кыз баланың сәнгатькә тартылуы гаҗәп түгел. Ренатаның әбисе 1939 елда, бик күп милләттәшләре кебек үк, Урта Азиягә – Ташкентка чыгып китә. Анда балалар укыта, кияүгә чыга, нигез кора. Оныгы Рената да Ташкентта туа. Аңа 4 яшь тулгач, алар гаиләләре белән яңадан туган якларына әйләнеп кайталар. Шулай бервакыт әнисе Рәйсә ханым кечкенә Ренатаны үзе укыта торган мәктәпкә чыгарылыш кичәсенә алып бара. Рената анда бер туктамыйча дүрт сәгать бии. Бу – ару белмәс, дәрте ташып торган кызчык кем булыр, дип тел шартлата ул вакытта әнисенең хезмәттәшләре. Рәйсә ханым исә кызын бию түгәрәгенә яздыра. Стәрлетамакның «Солнышко» бию ансамбле белән Рената шул вакытлардан бирле сәхнәләрдә чыгышлар ясап йөри башлый.

Ә бәлки зур киләчәк яки язмышның синең өчен генә кабынган бәхет йолдызы юлны шулай яктыртадыр?

Бәлки, бу мавыгу шуның белән узар да иде... әмма ул көннәрдән бер көнне телевизордан «Культура» каналында балет спектаклен ә тап була. Спектакльдәге хис-кичерешләрне, артистларның бию телендә олы мәхәббәт тарихын сөйләп бирә алуларын кыз могҗиза итеп кабул итә. Балет! Менә нәрсә кирәк булган аңа. Рената өчен «Син булдырасың, кызым!» дигән сүз генә кирәк. Алай гына да түгел, Рәйсә ханым кызның үзен генә җибәрми Санкт-Петербургка, гаиләләре белән күчеп китәләр. Берничә ел Стәрлетамак белән ике араны таптагач, әбиләрен дә үз яннарына алалар.

Шулай итеп, Шакировлар гаиләсендә балетлы Питер чоры башлана. Боларның берсе дә заяга түгел икәненә бүген инанабыз. Балет сөючеләр форумнарында Шакированы – Дудинская, Зубковская, хәзергеләрдән Лопаткина, Вишнева белән чагыштыралар. Чагыштыру тамашачы эше, ә Рената исә бүгенге көндә үз стилен булдыру өстендә эшли. «Һәркайсын яратам, хөрмәт итәм, һәркайсының үз стиле, пластикасы бар, ләкин кабатларга теләмим. Кабатлаудан яхшы нәрсә килеп чыкканы юк әле», – ди ул. Ә менә

PRESSA.RU



Тик шунысы бар: балет икән, димәк, башкала. Язмышны билгели торган хәлиткеч карарларны кабул иткәндә адәм баласына әни фатихасы канат куя.

Диана Вишневаның хезмәт сөючәнлеге, максатчанлыгы сокландыра аны. «Ул бит бүгенге уңышларына үзенең тырышлыгы аркасында ирешкән шәхес». – Ренатаның бу сүзләре Вишневаның бер әңгәмәсендә әйткәннәрен искә төшерә: «Мин театрда яши идем диярлек». Безнең бу сөйләшү дә репетицияләр арасында бара түгелме соң?

2015 елда академияне тәмамлаганчы ук аны рус классик балетының бишеге – Мария театрына эшкә алалар. Балерина театрны икенче өем дип атый. Репетиция булмаганда, шунда калып спектакльләр карый. 2016 елның башында ул «Зур балет» проектында катнашып, партнеры Кимин Ким (ә ул күптән инде театрда прима) белән җиңү яулый. Озакламый кордебалеттан солистлыкка күчә (хезмәт кенәгәсендәге «кордебалет артисты» белән «балет солисты» дигән язу арасындагы аерманың нинди тырышлыкларга бәрабәр булуын артист үзе генә белә). Репертуарында: «Аккош күле», «Йокыга талган гүзәл», «Жизель», «Дон Кихот», «Щелкунчик», Ромео һәм Джульетта». Кем өчендер болар матур төш кебек.

– Арытадыр бит? – Минем күз алдында Аронофскиның «Кара аккош» (2010) фильмы тора. Стресслар, физик яктан да, күңел халәтләре белән дә арыган-талчыккан балериналар... Төп героиняның галлюцинацияләре... Рената көлеп җибәрә.

– Алай ук түгел. Без дә ял итәбез. Мин, мәсәлән, китапханәдә китап укырга яратам, гәрчә аны хәзерге заманда ял итүгә санамыйлар бугай. Җәяү йөрим. Дуслар белән дә очрашабыз, күңел дә ачабыз. Озакламый сыйныфташлар белән очрашуга барырга җыенам. Ә менә «Зур балет»та арыта иде. Без бит сәхнәгә күнеккән. Телевидениедә сәхнәнең чикләре дә, тамашачысы да юк. Жюри бар, күпсанлы камералар. Телевидение үз кагыйдәләрен куя. Театрда без чыгышыбызның кайчан буласын минутына кадәр төгәллек белән беләбез, шуңа тәнне, мускулларны









алдан әзерлибез, җылытабыз. Ә монда бернәрсә дә билгеле түгел.

Әлбәттә, кичә генә спектакльләрдән өзекләр биеп йөргән студент өчен зур сынау була бу проект. Атна саен бер па-де-де әзерләргә кирәк. Тәҗрибәләр куеп карарга. Хореограф Владимир Варнава белән модерн стилендә чыгыш әзерләргә кирәк булгач, башта нәрсәдән башларга белмичә бер-берсенә карашып торалар, чөнки заманча хореография ул – бөтенләй башка. Анда сюжет юк. Анда, классик балеттан аермалы буларак, тәннең бөтенләй башка мускуллар төркеме эшли. Балет артисты өчен бу үтә дә мөһим. Ләкин сиңа театр җитәкчелеге шундый ышаныч белдерә икән – иркәләнеп торып буламы соң? «Мин педагогым Маргарита Кулликка, партнерым Киминга рәхмәтлемен, – ди Рената. – Без педагогым белән хәзер образлар тудыру, стилистика булдыру өстендә эшлибез. Хәрәкәт кенә түгел, балет сәнгатендә карашлар да, мимика да бик мөһим. Ә Кимин белән без «Дон Кихот»та биегән идек инде. Партнер таныш булганда, аңа тулысынча ышанасың, техникасын алдан тоясың, алай образга керү җиңелрәк». Рената сөйләгәндә, Майя Плисецкаяның сүзләре искә төшә. Легендар балерина үзенең хатирәләрендә, укытучыларымнан уңмадым, дип яза. «Ләкин Вагановадан берничә дәрес алдым, шул гомерем буена җитте», – ди. Ренатага исә бу җәһәттән дә бәхет елмая: әле Стәрлетамакта ук ансамбль җитәкчесе Галина Еникеева аңа балетта зур киләчәк юрый. Академиядә Удаленкова Татьяна Александровна кулына эләгә.

– Рольләреңнең кайсысы якынрак?

– Катлаулылары. Андый вакытта мин үз эчемә бикләнәм. Миңа персонажны тоярга кирәк, аның хис-кичерешләрен үзем аша үткәрергә. Гаиләмдә күнектеләр инде – андый вакытта миңа «тимиләр». Джульеттаны эшләгәндә, һәрбер хәрәкәтне, һәрбер карашны уйлаштык...

Мин янә балериналар чынбарлыгы белән «Кара аккош» фильмы арасында охшашлыклар эзлим. Әлбәттә, тормышта кинодагыча түгел: көндәшеңнең пуантларына пыяла кыйпылчыклары салып кына прима-балерина булып булмый. Рената Шакированың исә кешеләрдә хөрмәт итә торган сыйфатлары – күңел киңлеге, намуслылык һәм хезмәт сөючәнлек. Ягъни бу сыйфатлар аның үзенә карата таләпләре дә. Мондый Ренатаны, кинодагы героиня никадәр генә «язмышлы» булмасын, Каракош белән чагыштыру урынсыз. Бу балерина сәнгать күгенә биек очыш алган Аккош булып кереп бара.

P. S. Мәкаләгә нокта куйганда да, «Культура» каналында «Зур балет» бара иде. Рената белән Киминның «Таш кыя»сы (хореограф В. Варнава). Пуантлар юк, артистлар яланаяк. Ахырда Ренатаның аягында тупас ботинкалар пәйда була. Макияж юк диярлек. Сәхнәдә хисләр ташкын булып бәргәләнә. Бу классик балет түгел. Бу яңа заман хореографиясе. «Баланчинның сюжетсыз балеты да классика санала. Ләкин хәзер бию сәнгатендә юнәлешләр бик күп, һәркайсын белеп бетерү мөмкин дә түгел. Әмма классика – нигезләрнең нигезе булып кала», – дигән иде Рената. Гомумән, теләсә кайсы сәнгать нигезендә мәхәббәт ята, дигән фикердә ул.



Балет юкка гына затлы сәнгать төре саналмый, анда хисләр өермәсе – балеринага шуны күрсәтергә кирәк.








PRESSA.RU

60 нчы елларда шигъриятькә яңа дулкын килде. Рәдиф Гаташ, Ренат Харис, Равил Фәйзуллин, Рөстәм Мингалим, Рәшит Әхмәтҗан... Һәм, әлбәттә, Гәрәй Рәхим! Татарстанның халык язучысы, Г. Тукай премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе... Шөгер якларында, Федотовка авылында туган Григорий Родионовка Гәрәй Рәхим тәхәллүсен данлыклы шагыйрь Хәсән Туфан тәкъдим итә. «Сөйләсә – бастырып сөйләр, җырласа – өздереп җырлар, көлсә – рәхәт чигеп көләр», – диләр Гәрәй Рәхим турында. Якты, җылы, кояшлы кеше ул. Иҗаты да шундый. Аны моңнар шагыйре, фәлсәфи шагыйрь дип тә йөртәләр. «Моң – шагыйрьнең кыйбласы, иманы, туган җире, теле, күңел күзәнәкләрендә туган уй-фикерләре, мәхәббәте, нәфрәте, кыскасы, моң – шагыйрьнең үзе!..» – дип язган Аяз Гыйләҗев аның турында. Шул моң эчендә – дөнья турында уйланулары, халык язмышы, аның тарихы, борынгы ата-бабаларыбызга, аларның гореф-гадәтләренә, туган җиргә мәдхия җырлау...
Шагыйрь, язучы, драматург Гәрәй Рәхим бу көннәрдә үзенең күркәм юбилеен билгеләп үтә. Котлыйбыз! Иҗат уңышлары телибез!


Гәрәй РӘХИМ

ҺАВАЛАРДА ОЧКАН БӨРКЕТ КЕБЕК...

Каян килә?

– Каян килә, туган халкым, синең
Иректә бер халык булуың?
– Барыбызны уртак иткән зур юл,
Барыбызга ирек биргән ул юл
Тарихлардан килгән юл, улым!

– Каян килә, туган республикам,
Илдә йолдыз булып балкуың?
– Мине йолдыз итеп балкытучы,
Республика итеп яктыртучы
Тырышлыгы туган халкыңның.

– Мәскәүдәге Колонналы залда
Гөрләп узды Тукай кичәсе.
– Бәйрәм монда килеп җиту өчен
Кирәк иде әле, улым, баштан
Тукай җанын, рухын кичәсе.

Әнкәем

Йөрәккә дәрт бирә,
Тәнемә көч өрә
Өзелеп, балам, дип әйткәнең.
Син – минем яклаучым,
Бәладән саклаучым,
Бердәнбер киңәшчем
Әнкәем!..

Тормышлар авыр, дип,
Талчыктым, ардым, дип
Зарланып бер сүз дә әйтмәдең.
Күп газап кичердең,
Кызганмый көчеңне
Һаман да эшләдең,
Әнкәем!..

Гомерең узды, дип,
Картайдың, туздың, дип
Беркайчан, беркайчан әйтмәмен.
Син – мәңге яшь кеше,
Күңелләр яшьлеге –
Гел кызлар кебек син,
Әнкәем!.. Әнкәем!.. Әнкәем!..

Ни җитми?

Миңа ни җитми соң бүген?..
Миңа җитми яшь чагым,
Әнием пешергән коймак,
Кырда яккан учагым.

Миңа ни җитми соң бүген?..
Әтинең кырыс йөзе,
Печән бир диеп ялварган
Сыерның моңлы күзе.

Миңа ни җитми соң бүген?..
Башаклар җыйган камыл,
Тамакка – ач, ә рухка бай
Мин туып-үскән авыл.

Миңа ни җитми соң бүген?..
Син – тәүге мәхәббәтем.
Синнән башка мин бер дәрвиш,
Синнән башка мин ятим.

Миңа ни җитми соң бүген?..
Салютташ, сәламдәшләр,
Минем һәр шигырь юлыма
Шатланган каләмдәшләр.

Миңа ни җитми соң бүген?..
Казанның иске чагы.
Аның бөтен чатларында
Гөрләгән татарчасы.

Сиздем... Сиздем мин тормыштан
Тик бер үкенеч калган –
Картаюны сизми генә,
Аңа сиздермичә генә
Үтеп китәсе калган.

Асия Сафина (Тимериева) Түбән Кама районы Үчкә авылында туа. Каенлы сигезьеллык мәктәбен тәмамлагач, Түбән Камада урта мәктәптә укый. Лаборант һөнәрен үзләштереп, химия комбинатына урнаша. Аннары Казанда укып кайтып, ательеда мастер була. Чаллыда укып кайтканнан соң, Яшьләр белән эшләү идарәсендә психолог булып эшли башлый. Якташлары Асияне үзенчәлекле шигырьләре, хикәяләре аша да белә.



Асия САФИНА

АВГУСТ КӨЕ

Яшәү җыры

Мин кырларны, басу-игеннәрне
Гомер агышына охшатам:
Гомернең дә булмый ниндиләре,
Матур да соң, матур – ышанам!

Кыш китүгә юрганнарын ачып,
Басу-кырлар язда уяна;
Китү белән кар сулары ташып,
Шытым күреп күңел куана.

Күз алдында шәрә басуларга
Яшел хәтфә келәм каплана;
Бу манзара өмет өсти җанга –
Киләчәкне барлап шатлана.

Күксел диңгез сыман талгын гына
Мул басуда дулкын чайкала.
Могҗизалы иген дәрьясына
Хозурланып йөрәк таң кала.

Җәйге чиллә. Басу көчен туплый;
Баллы сөт исләре тарала...
Офыкларда аҗаганнар уйный,
Киң кырларда Икмәк ярала.

Алмаштырмас идем алтын тавын
Шаулап үскән иген кырына;
Алтын көшел – тук башаклар
шавын
Тиңләр идем яшәү җырына!

Август көе

Алмагачта алма аллана –
Алмаларга өмет баглана...
Өлгереп тә кирәксезгә калган
Алмалар да бар ул дөньяда...

Алмагачта алма аллана,
Август керсә – күңел моңлана;
Татарлыгым кирәксезгә кала –
Телем белән дәртем югала.

Татар булу – һаман тышауда;
Кемнәр чыгар хаклык яуларга?
Ни сәбәпле батыр, тырыш халкым
Күндәмлекне тора сайларга?!

Затлыбыз ник үсми татарча,
Зыялысы читкә гел кача...
Үз бакчаңда үскән багалманың
Куанычын күрик ичмаса!

Ана теле – телнең Олысы!
Милләт тамырларың ныгысын;
Татарыңа хезмәт итсәң генә
Югалуга каршы торырсың!

Җәйге бер көн

Зилзиләле җил җилләде,
Агач башларын иеп.
Күңелләргә хәвеф керде
Афәт башланыр диеп.

Күк күкрәде, яшен атты
Офык чикләрен кисеп...
...Хәвефләрне алып китте,
Яңгыр җилләре исеп.

Кояш чыкты, бар чәчәкләр
Елмаеп ачылдылар.
Хәвеф китте, шатлык килде –
И җәйге асыллыклар!..

Мин – ирекле

Һаваларда очкан бөркет кебек
мин ирекле!..
Тик илемә, Ватаныма бирәм
ул ирекне.

Һаваларда очкан лачын кебек
мин ирекле!..
Тик Каумемә – татарыма бирәм
ул ирекне.

Һаваларда очкан кошлар кебек
мин ирекле!..
Тәүге мәхәббәтем, сиңа бирәм
ул ирекне.

Һаваларда очкан кошлар кебек
мин ирекле!..
Тик улларым, кызларыма бирәм
ул ирекне.

Һаваларда очкан сәмруг коштай
мин ирекле!..
Тик дөньяга, бар җиһанга бирәм
ул ирекне.

Минем иркем әнә шундый...
Сорасагыз әйтәм һаман:
«Мин ирекле...
Мин ирекле...»

PRESSA.RU

Энҗе САДЫЙКОВА-ИБРАҺИМОВА – Казан кызы. КФУның көнчыгыш телләре институтын тәмамлады. Татар, инглиз, төрек телләрендә аралаша. Ул – Казанның туйлар төшерүче иң затлы фоторәссамы, «Кәрәз Клуб» беренче татар фотоклубы җитәкчесе. Аның дөньясы – спорт, театр, фото, дизайн, сәяхәтләр, бал кортлары, журналистика. Фотолары журнал тышлыкларын бизи, үзенчәлекле тел белән язылган язмаларыннан яңалык, заманчалык, ихласлык бөркелә. Мәктәп елларыннан ук хикәяләр яза. «Сөембикә» укучылары аның «Төркия килене» язмасын, журнал уздырган конкурстагы фотосын яратып кабул иткән иде. «Әчкелтем шоколад» – Энҗенең «Сөембикә» журналындагы беренче әдәби дебюты.



Энҗе САДЫЙКОВА

ӘЧКЕЛТЕМ ШОКОЛАД

(Хикәя)

1.

17 апрель, 2009 ел

Көндәлектән:

«Бүген яхшы көн иде. Автобуска керү белән канәгать елмайдым. Яраткан урыным буш икәнен күреп, киң тәрәзәнең сул ягына сыендым да, пыяла аша дөньяны күзәтергә керештем. Кайчак автобусны тәрәзәсе-ние белән юкка чыгарып, хыялланып ала идем. Гәрчә тузанланып, көн буена бу көпчәкле өйгә кереп чыккан һәр язмышның бармак эзләреннән мескен пыяла томанланып беткән булса да. Автобус Казан урамнары буйлап йөзеп кенә барды. Һәм шул мизгелдә мин үземне Венециянең тар урамнарыннан, иске, ләкин бик сөйкемле көймәдә йөзеп баргандай хис иттем. Асфальтның керделе-чыктылы җирләре судагы нәни дулкыннарга әверелеп, ара-тирә тән белән күңелне тибрәндереп тә алдылар.


...Автобус йөртүчене уйламаган кебек, көймәнең ишкәкчесен дә санга сукмадым. Муенымны катырып, бик төз халәттә көймәнең нәкъ уртасында басып бара бирдем. Бер кулым, рәвешен китереп кенә, кесәгә чумган; икенче кулымда – лимонад шешәсе. Тик шешәдә лимонад түгел, уйларым, имеш. Алтын күбек булып, берәм-берәм төптән атылып менәләр дә бер-бер артлы сүнеп юкка чыга баралар. Хыял уйнаклавын уйламаганда, акылда, уйда иркенлек, хөрлек. Кабан күленең чаты күренүгә, күңелем сискәнеп куйды. Бу җиргә аяк басу минем өчен сәхнәгә чыгу белән бер иде. Янәдән дулкынлана башладым. Җиңел генә каушаудан нерв күзәнәкләрем (мин аларны яратып, «нәркүз» дип йөртәм) кыбырсый башлады. Кулым үзеннән-үзе рюкзакка үрелде. Акчарлак туганнарны

сыйларга дигән күмәч телемнәрен ваклый-ваклый күлгә таба йөгердем. Тупыл-тупыл йөгереп килгән сабыен кулларын җәеп көтеп торган ана кебек, Кабан-Ана да бүген нарасый балаларына кочагын җәйгән иде. Кочаклаштык. Хисләнүдән елыйсы килде хәтта. Тик мин түздем – аналарны борчырга ярамый. Акчарлаклар шәһәр шавын шундук оныттырды. Күл һәрвакыттагыча сабыр иде. Мине алкышлап каршылаган акчарлакларга рәхмәт әйтеп, учымдагы ипи валчыкларын суга ыргыттым.

Җил салкын икән. Уйларым да җылылардан түгел анысы. Эчемә суык төшкәнен тойдым. Җилдән түгел бугай, уйларымнан... Кыскасы, мин ышыкка менәргә булдым... Нәкъ ун минуттан театрда спектакль башланырга тиеш. Яратам мин шулай кырыйдан, күл белән театр арасында калып, театрга агылган халыкны күзәтергә. Кемдер алдан килеп көтеп тора, кемдер: «Әй Аллам, соңга калдым инде», – дип, озын баскычларны абына-сөртенә сикереп үтә. Һавада көязлек, затлылык кебек бәйрәмчә, әмма ясалма исләр аңкый иде. Якынгарак елыштым. Җылысын тоймасам да, тәрәзә аша эчтәге утлар балкышын күрәсем килде. Ләкин утлар урынына күзем Аңа төште. Йөрәкнең бертуктамый «Җаным» дип үрелгәненә. Куллары... Белсәгез иде сез ул кулларның тылсымын. Тик... Аны күрү мизгеле бәхеткә әйләнергә өлгерми калды. Мин өзелеп гашыйк булган кулларына берәү асылынган икән инде. Дилбәр!

Кыйбатлы, зиннәтле кибет киштәсе каршында бер тиенсез басып торган баладай хис иттем үземне. Театрда – пыяла тәрәзә артында тормыш кайный, утлар уйный, йөзләрдән елмаю төшеп өлгерми, яңалары куна. Ә минем «нәркүзләрем» кан тамырлары буйлап мәтәлчек атты... Кулларым! Кулларым шоколадка үреләсе итте. Туктаттым. Юк, мин көнләшмәдем. Ихластан бәхет теләдем. Теләргә тырыштым. Шулчак фәрештә-канатларымның кыштырдавын тойгандай булдым. Мине күрмәүләреннән файдаланып (ярый әле күрмәделәр!), очтым театр алдыннан. Хәер, мине кем күрсен соң? Себеркегә атланып, кечке Кабан өстеннән очсам да, беркем шаккатмас иде.

Тукталышка җитәрәк, үземә кирәкле автобус торганын күрдем, тик артыннан йөгермәдем. Мин бит Казан–Венеция урамында, көймәнең уртасында кәпрәеп басып барам. Нинди йөгерү, ди, ул! Ә рюкзактагы шоколадка барыбер чыгарга туры килде. Җитмәсә, анысы да әче булып чыкты. Шушы салкын, азмы-күпме ялгыз, тирән әчкелтем халәттә... рәхәт иде миңа. Бәхетле идем мин. Шуны аңлау сөенеченнән, ләззәтне учлап-учлап тутырдым кесәләргә. Акчарлаклар, уйлар, салкын җилләр, тансык булып янган утларның үз ләззәтен алдым. Җил исә, кешеләр, автобуслар килә һәм китә, кояш батып яңадан калка, ә мин тукталыштан һәр күзәнәгем белән бу рәхәтлекне тоеп, авызымда эрегән шоколадның әчкелтем тәмен әкрен генә бәгырьгә сеңдерәм...»



Рәсем: Наталья Васильева

PRESSA.RU

2.

17 апрель, 2010 ел

Чынбарлык.

Кояшның кыздырганына бүген машинада чыдарлык түгел. Ул, ачык тәрәзәдән кулын сузып, бармаклары белән шаян уйнаклап, тырнакларының кызыл төсенә, бармагындагы йөзегенә, ахыр чиктә, үз-үзенә сокланып бара. Шәһәр шавыннанмы, ашыгуданмы, янындагы руль тоткан көчле кулларданмы – акчарлакларны бүген ишетми иде. Бәхетеннән иләсләнгән кыз мизгел авышты исә, чәчләрен рәтләп, куллар хуҗасының күзгедәге чагылышына елмаеп бара.

Менә-менә спектакль башлана дигәндә генә машинадан төшеп, театр бинасына пырхылдап очып керделәр. Өченче кыңгырау белән алар да урыннарына чыңлап диярлек килеп утырдылар. Колактагы зур-зур алкалары, кесәләрдәге машина, өй ачкычлары үзе бер симфония булып уйнап алды. Спектакль һәрвакыттагыча көчле иде. Ләкин ян утыргычта Ул утырганга күрә спектакльнең яртысы гына аңлашыла иде. Каушау, дулкынлану хисләре, баш миен рәхәт бер дулкынга күмеп, кызның акылын томанландыра. Ошаган репликалар истә калмый. Эчтәлек янәшә сызгырып уза. Үз дөньяңдагы башка бер тамаша тәнне алкышларга күмгәндә, сәхнәгә дә җитешүе кыен.

Беренче пәрдә тәмамлану белән, бөтен кеше ашыгып иреккә ыргылды. Шул исәптән, алар да. Чыгып барышлый, ни сәбәпледер, күзе бергә чыгып килүче зәвыклылар көтүен сөзеп алды. Һәм кинәт абынып калды: Дилбәр! Көндәш кыз үзенә текәлгән күзләрне күрмәде. Ә Кыз, яклау эзләгәндәй, кадерле кулларын барлады. Күкрәкне бәреп чыгарырдай типкән йөрәк башка китереп сукты. Кыз елмаеп, бөтерелеп бер алдына, бер артына төшеп, Аны тизрәк алып чыгып китте. Беренче уе качу иде. Күренәсе, күрәсе, күрсәтәсе... килми-килми-килми! Уенда бары качу – югалу! Тик ике адым атларга өлгермәде, аны бөтенләй башка бер хис бөтереп алды. Һич көтмәгәндә нииндидер хатынлык уянды. Тискәре хатынлык. Күренәсе килә иде. Күрсәтәсе! Һәм нәкъ аңа – Дилбәргә. Тәненә ыспай яткан күлмәген, нәфис кыяфәтен, шатлыгын, бәхетен, янындагы байлыгын. Бу теләкнең, йомшак итеп әйткәндә, дөрес булмавын уйларга вакыт юк иде.

– Бәлки йөреп килербез? – диде ул.

Театр фойесын алар өч тапкыр әйләнделәр. Икесе дә аптыраашта иде. Куллар хуҗасы бу йөрүнең мәгънәсен аңлап бетермәгәнгә, ә ул ни тырышып та «Д» хәрефле максатын очратмаганга.

Икенче пәрдә башланды. Сәхнәдә барган күренешләр төсле тасма булып кына сузыла башлады. Сизми, күрми, аңламый. Бары ишетә. Тонык сүзләр, көйләр... Кинәт сәхнәдән берсе ап-ачык итеп: «Оят турында авыз ачма инде син, яме!» – диде. Шунда ук күңелле генә җыр сузыла башлады. Ә аның башында бертуктамый барабаннар кага. Ачулы, ярсулы барабаннар. Нәрсә булды әле генә? Пәрдә ябылганчы шулай уйларына буылып утырса, мөгаен, ул шашар иде.

Итәгендә өметсез, җансыз яткан кулларына әкрен генә Аның куллары кагылды. Караңгы булса да, белеп тора: күзләре белән ул аңа карамый, сәхнәне күзәтә. Имеш. Кыяфәте дә бик җитди. Тик куллары гына, бар уйларын, хисләрен, тәнен сатып, аңа омтыла. Аһ, ул куллар... Кайчак ул Аны бөтен барлыгы белән сагынып өлгергәнче, куллар кулларны юксынып өлгергән була. Театрда иң яхшы спектакль, беләсезме, кайсысы? Караңгылык аша, яшерен генә, әкрен генә, сер итеп кенә Аның кулларын тоя алганы. Шул үтә дә якын сәхнәнең сихри тузанын сулап, сукыр бер ләззәт белән, куркып кына, Аның кулларын өйрәнгәне. Менә бүген дә шулай булды. Күзен йомды да, бармаклары буйлап сузылган нечкә сөякләрнең көчен сизеп, тамырлары аша аккан кан җылысын тойды, һәр күзәнәген... Әйләнә-тирә югала барды, эри барды, һәм ул янә көч-хәл акылдан язмады. Шулчак кинәт кенә айныды да, Дилбәрнең күзләрен исенә төшерде.

Салкын киемен элгән акыл бу юлы дошман хисләрне ишектән уздырмады. Аны иң кырыс рәвештә хөкем итте. Үзе белән көрәштерде. Аңа әйтеп бетергесез оят иде. Бәхетле халәттә, яратып яратылган хәлдә була торып, көнләшүдән дөрләп янганын сизде. Бер тәнәфес эчендә никадәр түбәнгә төшкәнен таныды.

Тамашачы, яраткан актерларның уенына хәйран калып, дүрт тапкыр чакырып чыгарып алкышлады үзләрен. Тик Ул калганнардан күбрәк кул чапты. Нәкъ вакытында әйтелгән, акылын башына кайтарган шул бер реплика өчен.

* * *

Кайтканда тәрәзәсен ачмаса да, акчарлаклар моңын ишетте. Аны аңларга тырышып, ерактан газиз Кабан-Ана елмая иде. Салкын җил күлмәге белән машина тәрәзәсен сыпырып узды...

Кайту белән ул купшы киемнәрен салып ыргытты да, ашыгып, яна-көя, өстәл тартмасыннан узган елгы көндәлеген эзләргә керешә. Тапты. «Тузанланып беткәнсең бит, бәгырькәем». Тиз генә 17 апрельне эзләп тапты һәм бүлмә уртасында чәчелеп яткан дәфтәр, киемнәрнең уртасына утырып, йотлыга-йотлыга Үзен укыды. Үткәндә калган чынбарлыгын. Чын Үзен. Яшь таммады түгел, тамды. Җанын яндырып узган Намусның яраларын, үз-үзенә булган хыянәт эзләрен, үз ризалыгы белән күңеленә кундырган тузанны юды булса кирәк.

Ул төне буе Казанны, күпердән агылган машиналар ташкынын күзәтеп чыкты. Кулында лимонад шешәсе, ак ипи, ә бәгырендә әчкелтем шоколад тәме иде.

КЫЗ АНЫҢ АВЫРУ ӘНИСЕН ТӘРБИЯЛӘГӘН АРАДА, БУЛАЧАК КИЯҮ ИКЕНЧЕ КЫЗГА ӨЙЛӘНЕП КУЯ.

ЧИЛӘГЕНӘ КҮРӘ КАПКАЧЫ...

Мәдинә АВЗАЛОВА

Алар йөрделәр. Бик яратыштылар. Күмпе матур сүзләр әйтелгән иде. Һәм бер мизгелдә барысы да күккә очты.

Әйе, күккә очты. Ике күгәрчен һавага күтәрелгәндә, ул да күгәрчен очырды. Аның үзен кунакларның берсе дә күрмәде, зәңгәрсукөрән күгәрченне күргәч кенә дәррәү кычкырып җибәрделәр: «Әнә, тагын берәү! Зәңгәр күлмәкне иңләп, һавада өч күгәрчен оча! Кәләшеннән күзен дә, кулын да алмаган кияү егет бер мизгелдә бу тамашадан өнсез калды. Ләкин үзен шундук кулга алды. Борчулы карашын төркемдәгеләргә текәде. Кемнедер эзли иде сыман ул. Тапмады. Таныш йөзне күрмәде. Бераз тынычланып китте, аннан кәләшен кулына алды: «Сине өйгә кадәр күтәреп кайтам дигән идемме?»

Загс ишеге төбеннән ун адым да китмәде, кәләшен чүт кенә кулыннан төшереп җибәрмәде. Көтмәгәндә каяндыр пәйда булган кызга ул ни әйтергә дә белми югалып калды. «Син...» – диде ул пышылдауга күчеп. «Мин, – диде кыз җан өшеткеч салкынлык, битарафлык белән, – мин сиңа балдагыңны кайтарырга килдем». Кыз шулай диде дә, бәләкәй кызыл бәрхет тартмачыкны кияү егетнең кулына тоттырып, шундук күздән дә югалды.

Бәйрәмчә бизәлгән машиналарга утырыша башлаган кунаклар бу хәлне әллә күрде, әллә күрмәде. Берәүнең дә, вакыйганы куертып, яшь парның кәефен җибәрәсе



килмәде. Хәтта кәләш тә моңа артык игътибар итмәде, фаҗига ясамады. «Исең китмәсен, – диде ул, кызу-кызу адымнар белән күздән югалган кызга ачулы караш ташлап. – Йөри инде шунда әрсезләнеп. Гарьләнми дә, ичмасам...»

Кызның үз хәле хәл иде. Гарьләнмәгән кая ул?! Биш ел яратышып йөргән егет белән кыз, өйләнешергә дип гариза биргән җирдән, икесе ике якка каерылсын әле?! «Диңгездәге кораблар шикеле без синең белән хәзер, – диде Әнәс көннәрдән бер көнне кызга, – юлларыбыз аерыла». Егетне шул көннән алыштырып куйдылармыни. Әйтерсең, ул Рәмзиясен беркайчан да кочып үпмәгән, колагына матур сүзләр пышылдамаган, бергәгомергә дигән тылсымлы сүзләрне әйтмәгән. Барысы да булды ич, булды! Нәрсә бу? Тылсыммы, сихерләделәрме әллә аның сөйгәнен?!

Рәмзия җәйге ялының унбиш көнен Әнәснең авыру әнисе янында уздырды. Булачак кайнанасы кырыс холыклы булса да, гадел һәм туры сүзле иде. Көннәр буе җыештырынып, аш-су әзерләп йөргән, янынннан бер дә китмәгән кызга егет анасы жәлләп тә, яратып та карады. Ананың: «Казаныңа кит, мине саклап егетсез кала күрмә», – дип шаяртканы чынга ашты.

Соңгы күрешүләрендә егет Рәмзиягә тапкырлау җәдвәле кебек ятлаган бер үк сүзләрне кабатлады: «Тормыш алып бару өчен акча кирәк, Рәмзия, акча... Мәхәббәтне ипигә ягып ашап булмый».

Авыр, бик авыр булды аңа. Суларга төшимме әллә, дигән көннәре дә булды. Шундый көннәрнең берсендә кыз төшендә мәрхүмә әбисен күрде. Каршысына очып диярлек килгән Рәмзияне күргәч, әбисе кырт борылды да, кара күгәрченгә әйләнеп, ак болытлар эченә кереп югалды.

Кыз төшен әнисенә сөйләде. «Ярамаган эш эшләргә җыенмыйсыңдыр бит? Әбиең синең өчен борчыла, – диде әнисе. Аннары әйтә куйды: – Китәсе кеше китә торсын, барыбер синеке булмас иде. Ул бит кәләшнең үзенә түгел, байлыгына өйләнә. Ә байлык ул, үзең беләсең, бүген бар, иртәгә юк...»

Озак та үтми, Рәмзиягә егетнең әнисеннән хәбәр килеп иреште: Хатын малайны акча эшләмисең дип талый. Акча да, акча аңа... Имеш, пар килмәгәннәр.

«Ничек кенә пар килгәннәр әле. Чиләгенә күрә капкачы», – диде Рәмзия моны ишеткәч.

PRESSA.RU



«ӘТИ, БЕЗ БИТ БАРЫБЕР ТУГАН!»

– БАЛАЛАРНЫҢ ӘНИЛӘРЕ ТУРЫНДА НАЧАР ИТЕП ЯЗМАСАГЫЗ ГЫНА...



Гөлнур ХӘСӘНШИНА

Люция баштан ук шундый шарт куйды. Минем максатым гаеплене эзләү түгел икәнен аңлагач кына, очрашырга ризалашты. Әйдәгез, сезнең белән дә алдан ук килешеп куйыйк: журналист барыбер нидер әйтеп бетермәгән бугай дип, язган юлларым арасыннан берни дә табарга тырышмагыз. Минем кебек: «Бичара, ялгышкан», – дип кенә уйлагыз. Әйе, ялгышкан... Аннан, чыннан да, балаларның әниләре хакында бер начар сүз ишетмәдем Сарманда. Язманы укыгач, сез моңа инанырсыз. Аңа карата мондый кискен карар кабул итәргә судның, әлбәттә, сәбәпләре булгандыр. Әңгәмәдәшемнең алар хакында миңа сөйләмәве – анысы бит башка мәсьәлә.

Өч ел элек хатыны белән аерылышты ул. Ленаның китүен авыр кичерде Инсаф. Балаларын бик сагына шул: улын, ике кызын... Эчүгә сабышты менә... Ир-атның күбесе кайгыны шулай баса бугай. Моңарчы шешә белән дус булганын белмим.

Бергә эшләгән хезмәттәшенең авылдашы булып чыга Инсаф. Үзенә сүз дәшкән ир-ат артыннан ишек ябылуга, Люция аның турында, шулай итеп, барысын белергә дә өлгерә. «Иртүк баш төзәтергә керсә дә, эчкече түгел, димәк, хәсрәтен генә баса икән – анысы узар», – дип уйлагандыр ул. (Дөрес уйлаган! Алар кавышканга инде унбиш ел – шуның соңгы унөч елында ирнең хәмерне авызына да алганы юк!) Ә ялгыз калуның ни икәнен белә Люция – яшь тә ике айлык кызы белән төп нигезгә кайтып сыенганына инде берничә ел. Инсафны мактый хезмәттәше: «Әти-әнисе авылда хөрмәтле кешеләр. Бик тырыш нәсел. Инсаф та хатыны белән бура йорт салып чыккан иде. Әллә нәрсә булып куйды шул...»

Тәвәккәлли Люция. Яңа елдан бу икәү яңа тормыш башлыйлар.

Нәкъ ярты елдан Инсафның балаларын күрергә барырга җыеналар алар. Бу юлы – икәүләп. Лена бу вакытта балалар белән Азнакайда яши, ул инде кабат кияүгә чыккан, тагын өч балага әни булырга өлгергән.

– Җәйге каникуллар башланганын көттек. Теләсә, балаларның уртанчысын – Эльвираны үзебезгә кунакка алып кайтып торырбыз, дип барган идек. «Кире монда китермәсәгез генә кайтам сезнең белән», – диде ул. Шулай итеп, бездә калды...

Люция белән ул көннәрне искә төшереп утырабыз.

Эльвира артыннан ук Мортыш-Башка Эльвир да кайтып төшә. Башта әтиләренең күршесендә генә яшәүче әбиләренә әле. Яшерми Люция: 14 яшьлек яшүсмер күңеленә ачкыч табу аңа иң авыры була. «Тыя алмам дип курыктым», – ди ул. Малай инде үзе ничек тели, шулай яшәргә өйрәнгән – аның берәүгә дә баш бирәсе килми. Ә Люциянең кырысрак булмый чарасы юк: иңнәренә нинди җаваплылык алганын ул үзе генә белә.

Эльвир әтисе һәм яңа әнисе янына бер елдан соң гына күченә. «Яңа әни» дигәннән. Апасы һәм сеңлесе кебек, Люциягә «әни» дияргә ашыкмый ул. Үсеп буй җитә, армиядән әйләнеп кайта, укый, башлы-күзле булырга карар итә. Никах мәҗлесе вакытында кунаклар алдында торып баса да: «Люция апа, мин моннан соң сиңа «әни» дип кенә дәшәрмен инде, яме», – ди. Шул көннән башлап, ике сүзнең берендә «әни» дип кабатлап торган олы улы Люциянең иң беренче киңәшчесе. Мин вакыйгаларны ашыктырып, алгарак киттем.

Кайту чираты Зөһрәгә җитә. Леналар Лениногорскига күченгән булалар – төпчек кызны шуннан барып алалар. Кызчыкны юлга авыл советы, районның опека бүлеге җыеп озата.

– Башта бик авыр булды, – ди Люция. – Юк, балалар белән түгел, алар безгә берниндн проблема да тудырмады. Инсафның Сарманнан авылга кайтып эшкә кергән генә чагы иде. Хезмәт хакы түләмиләр: бәйрәмнәрдә генә йә 100, йә 200 тәңкә биреп куялар. Мин ашханәдә эшлим, хезмәт хакым шулай ук зур түгел. Кызым Алсу әниләрдә үсте, 6 нчы класска гына монда килде. Әни 16 ел урын өстендә ятты безнең, әти карады. Шуңа күрә Алсу да анда күбрәк кирәк иде. Хәзер дә ире, балалары белән әти янында, Каташ Каранда тора ул. Мондагы балалар белән бик дус булды, бигрәк тә Эльвира белән. Киләм, дип, ялларны, каникулларны көтеп кенә торды. Мин гел эштә булдым. Алар ашарга да үзләре пешерде, мал да карады, сыер да сауды...

Тормышлар бер килеш җайлана шулай. Ә беркөнне эштән кайткан әниләрен балалар яңа хәбәр белән каршы алалар: «Безгә бүген Рәхимә апа килде...» Районның опека бүлеге хезмәткәренең Эльвирны эзләп йөрүе булган икән. Лена әниләренең икенче ирдән туган өч баласын «Балалар йорты»на урнаштырганнар. Эльвирга инде 18 яшь, ул – абый кеше, туганнарының киләчәк язмышын ул да хәл итә ала. Теләге бар икән – опекага ала, юк икән...

Бездә чит бала юк! Барысы да үзебезнеке!

Эльвирның армиядә хезмәт иткән чагы. Аның бер-бер хәбәрен көтеп торсаң... Кичен, әтиләре дә кайткач, бөтенесе утырып сөйләшәләр, киңәшләшәләр: «Нишлибез?» Кызларның өчесе дә – Эльвира да, Зөһрә дә, Алсу да: «Кечкенәләрне алып кайтырга кирәк! Без бит инде зур, карарга үзебез булышырбыз», – диләр. Бер карарга килгәч, икенче көнне дә көтмичә, Рәхимә апаның өенә төнлә төшеп китәләр: «Без балаларны үзебезгә алабыз! Кая барырга, нишләргә кирәк?»

– Барып кердек «Балалар йорты»на... Алдагы бүлмәдә бер бала елый, кечкенә генә кыз. Диванга утыртып куйдылар моны. Йөрәгем нидер сизенеп: «Гөлназмы әллә?» – дим. Диваннан төшеп, яныма йөгереп тә килде: «Әйе!» – ди. Әйтерсең, яклаучы кеше тапкан... Аннары яныбызга Рузилә чыкты. Рузилә белән Раилнең берсенә – 7, икенчесенә 5 яшь, алар апаларын белә, хәтерлиләр. Гөлназ өч кенә яшьлек иде. Ул инде хәзер әнисен дә онытты... Абый-апаларыннан ишетеп, без сөйләшкәннән генә белә тагын бер әнисе бар икәнен. Бер тапкыр Чаллыда очраштылар алар. Раилләр санаторийда иде. Без кереп барабыз, Лена санаторийдан чыгып килә: ул да хәл белергә килгән. Гөлназны кочаклап елады шунда Лена. Сагынадыр, билгеле... Ул бит аны тугыз ай күтәргән, өч яшькә кадәр үстергән...

Кечкенәләрнең кайтуын өйдә ул көнне апалары түземсезләнеп көтә. Кем кайсы баланы карый – кызлар алдан ук бүлешеп куя: Алсуга – Рузилә, Зөһрәгә – Гөлназ. Раил: «Мин абыйны көтәм!» – ди. (Эльвирга өйдәге бу яңалыкны ике-өч айдан соң гына язалар әле.)

– Август башы булса да, бик салкын көн иде ул, – ди Люция. – Балалар футболкадан гына – без аларны үзебезнең курткаларга төреп алып кайттык. Җылы киемнәре юк иде шул... Рузиләнең джинсы итәге бар



PRESSA.RU

иде: ул аны әле кайткач бик озак салырга теләмәде. Рәсем ясарга ярата Рузилә – «Балалар йорты»ннан аның бер пакет рәсемнәрен генә биреп җибәрделәр. Беренче көннәрдә гел ашарга сорап тордылар: көнгә икешәр тапкыр аш пешердек. Кызларны мунчага апалары кертте, дәресләрен дә алар караштты – үзләре алдан әйткәнчә бик булыштылар. Бигрәк тә Гөлназны яраттык. Барыбыз да! Кечкенә булгангамы икән... Курчак кебек матур иде ул, без аны кулдан да төшермәдек...

Лена, балаларын кире кайтаруны сорап, судка мөрәҗәгать итә. Суд аның бу үтенечен канәгатьләндерми.

«Тәрбияли белмәде, туры юл күрсәтергә хәленнән килмәде», дисәләр?! Алла сакласын!

Тагын бер елдан аны аналык хокукыннан мәхрүм итәләр... «Башка берәүләргә бирсәләр, бу кадәр ачуым килмәс иде! Алыгыз, кирәк булса, тагын табармын!» – Лenaның судта әйткән бу сүзләрен Люция аңларга тырыша. «Андый чакта әйтелә инде... – ди ул һәм шунда ук сүзне башкага бора. – Алсуны тапканнан соң бик катлаулы операция кичердем. Инсафка: «Әйдә, бер кечкенә бала алыйк әле», – дия идем. «Берне сорадың, Ходай өчне бирде миңа!» – дип көлә ул хәзер».

Кечкенәләр өйгә кайтуга «әти», «әни» дип әйтә башлый. Олы улына бик тә охшаган Раилгә Инсаф кына озак ияләшә. Үзенә һәрвакыт «Эльвир» дип дәшүләренә тәмам аптырап, Раил берсендә: «Минем исемем хәзер Эльвир буламыни инде?» – дип сорый.

Әтиләрен Раил кадәр яратучы юк бугай аларда! «Әти, абый белән апалар синең балалар булгач, без дә сиңа туган бит инде!» – диюче дә шушы малай бит инде. «Әти, 18 яшем тулуга мин дә синең фамилиягә күчәм – Сөнгатуллин булам, яме!» – диюче дә ул. Укытучылары да: «Ике сүзнең берендә телендә «әти» аның», – диләр икән.

– Инсаф өйдә чакта кечкенәләр гел аның янында сырпалана. Үзе дә балаларны бик ярата. Алсу да күптән «әти» дип дәшә инде аңа. Ә мин кырысрак шул...

Әниләре үзе шулай ди. Белмим... Ярату күптөрле була бит ул, төрлечә чагыла. Аннан яратуны балалар кадәр берәү дә тоемлый алмый.



– Балалар тәртипле булды, шөкер. Былтыр зурлап ике туй үткәрдек менә: башта Эльвирны өйләндердек, аннан Зөһрәбезне кияүгә бирдек. Эльвир Бөгелмәдә укып кайтты, аннан, читтән торып, Алабугада белем алды. Хәзер үзе укыта. Әти булырга да өлгерде инде. Өй салып яталар. Сеңелләрен, энесен бик ярата, үзләренә гел кунакка алып китә. Зөһрәләр Әлмәттә яши, фатир сатып алдылар, яңа гына уллары туды. Эльвираның ире Раилне бик якын итә: нинди эшкә тотынса да, булышырга аны чакыра. Эльвирабызның да бәби үстереп ятуын Лена ишеттеме икән, белмим. «Әниегезгә шалтыраткалагыз», – дим дә бит... Эльвира: «Кайбер вакыт телефоннан булса да сөйләшәсем килә дә, әни үпкәләр дип куркам», – ди икән. Солдаттан кайткач, Эльвирга да: «Әниең янына бар», – дидем. Бармады...

Абый-апалары артыннан инде кечкенәләр дә үсеп килә. Сүз үзеннән-үзе аларга күчә:

– Әле Раилгә иптәш булыр, дип, тәрбиягә бер малай алырга йөрибез. Моның өчен башта Әлмәттә укырга, әзерләнергә кирәк, диделәр. Психологлар да дәрес бирә. Күпләр балаларыннан зарлана анда. Ә мин берсе турында да начар сүз әйтә алмыйм. Олылары турында да, кечеләре хакында да. Рузилә 7 нче класстан соң Минзәлә педагогика колледжына укырга керде. «Инглиз теле өйрәнәм», – дип, үзе теләп китте. Беренче елны ул да, без дә сагындык, инде ияләшеп киләбез. Раил дә бик тырыш, «дүртле»гә генә укый.

Балалар әниләрен хурлап ялгыш бер сүз сөйләгәннәре юк. Чын әниләре мин түгел икәнен, аларны тәрбиягә генә алуыбыз турында, гомумән, берәүгә дә белгертәселәре килми. Үз әтиләре моңарчы гел килгәләп йөрде. Лenaның исә безнең бусаганы атлап узасы килмидер инде, кире бормас идек югыйсә... Алиментын түләп тора – ул акчаны балаларның үз исемнәренә салып, җыеп барабыз. Кибеттә эшли, диләр, акча тирәсенә теләсә кемне куймаслар. Өсте-башы гел чиста, пөхтә аның. Апа-абыйлары да, кечкенәләр дә әниләренә охшаган – матурлар. «Безгә шундый чибәр балалар табып биргән өчен Ленага рәхмәт инде», – ди Инсаф. Чынлап та, рәхмәт...

Көтмәгәндә-уйламаганда шулай күп балалы әнигә әйләнеп киткән Люция үзенең яңа халәтенә күптән ияләшкән бугай. Җиде бала янына инде килен-кияүләр, оныклар өстәлгән... «Яшелчәне күп утыртам. Йөзәр төп помидор, баклажан, кәбестә. Түтәл-түтәл суган, кишер... Йөзәр банка компот ябам, кыяр-помидордан салат ясыйм», – ди ул. Узган ел 62 баш каз үстергәннәр. Ике үгез симертеп суйганнар. Егерме ояга якын умарта тоталар. «Балаларның өстенә кешедән калган кием кигертмибез. Хөкүмәт шуның өчен түли: бер айда берсенә алабыз, икенче айда – икенчесенә, – ди Люция. Нигә яшерергә: балаларны акча өчен генә алдылар, дип әйтүчеләр, әлбәттә, булган. Акча өчен генә бала карап булса икән?! Үз әниләре: «Аларны мин тәрбияләргә тиеш», – дип, судка биргәч, Люция иренә: «Абыйапалары да кечкенәләрне кире кайтарырга риза түгел. Гөлназны алып булса да, качам мин!» – дияр идеме икән?! Күңелендә хәсетле уйлар йөртсәң, болай уйлап та, әйтеп тә булмыйдыр. «Көндәшеңнең балалары», – дигәненңе ишетми дә ул. «Барыбер бала алырга теләгән идек. Үзебезнекеләр килеп чыккач, сөендек кенә. Алты бертуган бит алар. Бер-берсенә охшаганнар...» – ди. «Безгә нигә шаккатырга – үзебезнекеләрне үстерәбез. Чит-ятларны якын итә алганнар гаҗәп!» – дип өсти.

Хәер, анысы да гаҗәп, монысы да.

P. S. Инсаф белән Люция гаиләсендә яңалык: аларның хәзер балалары сигезәү! Раилгә 12 яшьлек Никита исемле энекәш алып кайтканнар!



ГАТАУЛЛИН Раил

Казан дәүләт педагогика университеты (1999)

Кызы һәм улы бар.

Карьера: «Татнет»ны үстерү фонды һәм Белем.ру оешмасы; программист; SEO-белгеч, дәреслек һәм методик әсбаплар авторы, тәрҗемәче.

Тормыш шигаре: «Начар дигән кешедә дә яхшылык табарга була».

https://www.facebook.com/suyumbike.zhurnaly

Белем.ру порталына – 10 яшь!

Мәктәптә укыганда 1 сентябрьне – Белем бәйрәмен зур түземсезлек белән көтеп ала идем. Аннары – укытучы булып мәктәптә укытканда... Татар мәгарифен үстерү юнәлешендә шактый хезмәт куючы кеше буларак, бу көн миңа әле дә гадәти көннәрдән шактый аерыла. Бәйрәм дигәннән: Белем.ру порталына быел тәгәл 10 яшь! Белем көнендә Белем.ру порталы туган көнен дә билгеләп үтәчәкбез. Юбилей уңаеннан ул яңа проектлар белән тулыланачак.


Интернетта татарча мәгълүмат арта


«Татнет»ны үстерү фонды исеменнән ике елга якын татар интернеты үсешен даими карап, анализлап барабыз. Аеруча соңгы елларда интернет челтәрендә татар телендә мәгълүматның артуы күзәтелә. Татар газета-журналлары сайтлары активлашты, татарча – файдалы яңа проектлар дөнья күрде. Социаль челтәрләрдә, аеруча «ВКонтакте»да татарча төркемнәр саны нык артты. Татарча аралашучылар, фикер алышучылар да арта бара. Димәк, хәзер интернетта шактый күп мәгълүматны үз телебездә эзләп табып була!


Әкият түгел, чынбарлык!

Айга, башка планеталарга очасы килмәгән бала юктыр ул. Кечкенә чакта миндә дә бар иде андый хыял. Галәм белән бәйле берәр яңалык ишеткәндә йөрәк хәзер дә кысылып куя... «Джуно» космик аппараты, Җир гравитациясен файдаланып, зур тизлек (~250000 км/сәг) җыйды һәм 5 ел эчендә 700 миллион чакрым юл үтеп, Юпитер орбитасына кадәр барып җитә алды. Юпитер, димәк, безгә якынайды!

сөендерде









көендерде

сөендерде









көендерде

сөендерде







көендерде

Дөрес язарга да була бит...

Интернет челтәрендә татар телендә аралашучылар саны арта барса да, татар хәрефләрен (ә, ө, ү, җ, ң, һ) кулланып язмаучылар да әле шактый. Бу – туган телебезне кимсетү бит! Ничек инде «Сәлам!» урынына «Салам!» дип язарга мөмкин? Компьютер өчен дә, смартфоннар өчен дә татар телен урнаштырырга күп дигәндә бер минут вакыт җитә. Бозмыйк туган телебезне! Бу уңайдан кулланучылар өчен «Компьютерда татар теле» (шулай дип эзли аласыз) исемле мәкаләм файдалы булыр дип исәплим.

Югыйсә үзләре дә татарча укыган...

Кайбер ата-аналар хәзер: «Балам БДИны бирә алмас», – дип рус телендә укытуны даулап йөри. Кайсылары татар телен укыту методикасы начар дигән сәбәп таба, татарча белем бирү өчен әсбаплар җитми ди. Мин – информатиканы үзем язган дәреслек буенча татарча укыткан кеше. Укучыларым барысы да диярлек югары белемле – уңышларына куанам. Белем дәрәҗәсе аны нинди телдә алганга бәйле түгеллеген үзләре татарча укыган әти-әниләр белергә тиеш тә бит...

Спортта гаделлек җитми

Кайбер җиңел атлетларның допинг куллануы сәбәпле, Халыкара Олимпия комитеты Россия җыелма командасын Олимпия уеннарына кертмәскә карар кылган иде. Әмма бит әлеге командада «чиста» спортчылар да шактый! Башкаларның гаебе аркасында Олимпия уеннарында катнаша алмаслар, дип, әлеге җиңел атлетлар турында уйлап, бу җәйдә нык борчылып алырга туры килде... Спорт – тәне һәм рухы нык кешеләр урыны булырга тиеш!

PRESSA.RU



Мин яратам сине, Татарстан!

Мин яратам сине, Татарстан,
Ал таңнарың өчен яратам,
Күк күкерәп, яшен яшьнәп яуган
Яңгырларың өчен яратам.

Мин яратам сине, Татарстан,
Горур халкың өчен яратам,
Җан эреткән әнкәм телең өчен —
Татар телең өчен яратам.

Мин яратам сине, Татарстан,
Тугайларың өчен яратам,
Тукайларың, Сәйдәшләрең өчен,
Җәлилләрең өчен яратам.

БУ ИНДЕ ХАЛЫК ГИМНЫ!

Бу җырның сүзләре шулкадәр гади. Аны бик тиз отып каласың. Машина тәрәзәсеннән карап барганда да күпләр үз алдына гел кабатлый торганнардыр: «Мин яратам сине, Татарстан!» Ерак сәфәрдән кайтып килгән чагында да, очкыч трабыннан төшүгә: «Эх, мин яратам сине, Татарстан!» – дип куябыз. Инде чирек гасыр элек «Мин яратам сине, Татарстан!» дигән җыры да килеп чыккач, күңелдә мөлдерәмә тулышкан хисләрне көйгә салып түгәргә мөмкинлек чыкты.

Бу җырның сүзләре, әйткәнемчә, бигрәк тә ихлас, самими шул. Көе дә бик тиз истә кала торган. Күкрәкне туган якны ярату хисләре, шул туган ягың белән, анда яшәүче кешеләр белән горурлану хисләре алгысытканда, тойгыларыңа ирек бир дә, кинәнеп бер җырлап җибәр! Үзең генә җырла. Хәер, сиңа шунда ук янәшәдәгеләр дә кушылыр. Чөнки

бу җырның көе сагышланыр өчен түгел, күңел тантанасы өчен. Җырлый башлауга көндәлек мәшәкатьләр вак булып калыр. Күз алдыңнан Татарстанның көньяк-көнчыгышына ук килеп җитә язган Урал тау итәге дулкыннары, Чатыр тауның татар күңеленә ярашып тора торган тыйнак текәлеге, ышыктан аккан Ык суының талтирәкләре, Агыйделнең язын ак шомыртка төренә торган ярлары, Кама-Чулманның сабыр салмак сулары, Иделнең күз карашы җитмәс киңлекләре, Ослан таулары, моңлы Мишә һәм Зәй сулары, Алабуга урманнары һәм Татарстанның алтын иген басулары йөгереп узар да син тагын да дәртләнебрәк сөрән салырсың: «Мин яратам сине, Татарстан!»

2008 елда «Мин яратам сине, Татарстан!» җырының авторлары – шагыйрь Роберт Рәкыйпов (үлгәннән соң), композитор Роберт Андреев һәм җырны гимн дәрәҗәсенә җиткереп җырлый алган Салават Фәтхетдинов Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев фәрманы белән Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе белән бүләкләнде.

Бая гимн дигән сүз әйттек. Чынлыкта, Татарстан Республикасының сүзсез гимны бар иде инде. Рөстәм Яхин музыкасы яңгыраган гимнны олы ихтирам белән тыңлап кына тора торган идек. Дөрес, берничә ел элек Рамазан Байтимеров шигыре ул гимнга сүзләр итеп сайланды. Милләт гимны да бар иде безнең. Ул – «Туган тел» җыры. Халык, рухи бердәмлек тойгысы кичергән мизгелләрдә, дәррәү аягүрә басып, «Туган тел»не җырлады. Инде менә «Мин яратам сине, Татарстан!» җыры гимн рәвешендә яңгырый башлады. Аның популяр булып китүендә, әлбәттә, Татарстанның халык җырчысы, Тукай премиясе лауреаты Салават Фәтхетдиновның роле гаять зур. Чөнки ул дистә елга якын инде һәр концертының репертуарына шушы җырны кертә. «Татарстанның хәзер ике гимны бар. Берсе Республика гимны, икенчесе – халык гимны», – дигән мәшһүр гыйбарәне беренче Президентыбыз Минтимер Шәймиев шул концертларның берсеннән соң әйткән иде дә инде.

Бу урында икенче «гимнның» музыкасын иҗат иткән композиторның үзенә сүз бирсәк тә урынлы булыр. Чөнки Роберт Андреев турында кешеләрнең дә мәгълүматы артык күп түгел. Югыйсә бу композиторның иҗаты игътибарны җәлеп итә торган. Әйдә, сөйләтик әле.

– Табигать шулай яраткан, күрәсең. Мин моңлы бала булып үстем. Матур хыяллар дөньясында үстем мин дә. Хәтерлим әле, салам түбәле өй кыегына менеп утырам. Өй кыегы – сәхнәм, тактам – гармун. Җырларым – «Кондырак болыннары», «Утыр әле яннарыма», «Сөмбел». Шуларга үзебезнең авылда җырлана торган керәшен җырларын өсти идем. Әтием тимерче иде минем. Аның янына барып та, сандал чыңын моң итеп тыңлыйм.

Алачык белән янәшә генә ындыр табагы иде безнең. Мине шунда ял минутларында җырлаталар иде. Гармун ал, – дип әтине аптыратып бетерә торган идем. Берзаман уеннан кайтып керсәм, әтием сәке читенә утырган да, тальян гармун тартып, керәшен җырын җырлап утыра! Шатлыгым чиксез иде. Менә шул көннән алып, мин музыкага чумдым. Авыл мәктәпләрендә музыка укытмыйлар иде шул. Шунлыктан, үзлегемнән баян тартырга өйрәнсәм дә, мин төзүчеләр техникумына укырга кердем. Аннан өч ел диңгез флотында хезмәт иттем. Соңрак озак еллар нефтьчеләрнең «Ромашкино» санаториесендә мәдәни ялны оештыручы булып эшләдем. 35 ел дәвамында музыка дөньясында кайнау үзенекен итте, акрынлап көйләр язу белән мавыга башладым. Композитор Рәис Нәгыймов белән дуслык та стимул биргәндер инде. Беренче җырым язылганга 30 ел булган икән инде. Роберт Рәкыйпов сүзләренә язылган «Зөһрә» дигән җырым Әлмәттә узган үзешчән авторлар бәйгесендә җиңүче дип табылган иде.

1990 нчы елларда республикабыз 16 нчы союздаш республика булачак дип, күтәренке рух белән йөргән вакытлар иде бит. Мин янәдән шушы авторның шигырьләр китабын тотып утырам. Күзем «Мин яратам сине, Татарстан!» шигыренә тукталды. 30 август иде бу көн. Ул көнне Татарстан Дәүләт Советы «Мөстәкыйльлек турында декларация» кабул итте. Ә мин соңыннан мәшһүр булып китәчәк җырымны язганмын.

1991 елда Рига шәһәренә Сабантуйга барган идек. Бәйрәм буласы көнне безне видеотасмага төшерделәр. Мин Даугава елгасы ярына басып, «Мин яратам сине, Татарстан!» дигән җырымны җырладым. Гаҗәп дулкынландым мин ул чагында. Җырымның үз биографиясе шул көннән башланды бугай. Иң беренчеләрдән булып аны Чаллы үзешчәннәре җырлады. Аннары хәзер Швециядә яшәп ятучы Гөлүзә Зыятдинова, соңрак Габидулла Хөрмәтуллин җырладылар. Салават җырны үз репертуарына алганнан соң, ул аеруча нык популярлашты. Бер елны ул хәтта концерт сезонын да шул җыр исеме белән атады. Салават җыр театры автобусының сыртына да шушы җыр исеме язылган. Нинди генә зур дәүләт җитәкчеләре катнашында узган чара булмасын, бу мәшһүр җырчы, республикабыз белән горурлануын дәлилләп, чыгышын «Мин яратам сине, Татарстан!» белән башлый.

Әлбәттә, мин үзем дә горурланам. Минем үземә дә күп мәртәбәләр чит өлкәләргә барган мәдәни десантлар составында катнашырга туры килде. Мәскәү, С.-Петербург, Ташкент, Пермь, Сургут, Уфа шәһәрләрендә булдым. Бу җырымны җырлаганда тамашачы, аягүрә басып, кушылып җырлый. Гади бер кешенең тыйнак хезмәтен республикабыз да, халкыбыз да югары бәяләде, дип горурланып яшим.



Мәдинә
АВЗАЛОВА

яшәеш

АСЫЛБИКӘ

УРЫН ӨСТЕНӘ КАЛАСЫҢ КИЛМӘСӘ, БЕРТУКТАУСЫЗ ХӘРӘКӘТЛӘН, ДИЛӘР АҢА.

Яшь ярымнан кеше кулына калган кызчык ятимлекне генә түгел, бөтен тәнен әледән-әле «утка» тотып җәфалаган чирне дә үзенә буйсындырыр көч таба ала.

Аны беренче күрүем дип әйтә алмыйм. Ул да минем кебек Кукмарадагы 1 нче татар мәктәбендә укыды. Мәктәбебезнең дан тоткан җырчысы иде. Ул җырлаганда залда утыручы яше-карты елый башлый, җырлап бетергәч, гөрләтеп кул чабалар, тагын, тагын чакыралар иде. Ул вакытларда тамашачыларның күз яшьләренә буыла-буыла елавына аптырый идем. Нигә елыйлар... Бик күп еллар узып, гомерләр баю ягына таба борыла башлагач кына, күңел түреннән ургылып агылган моңы бүгенгәчә колак төбендә яңгырап торган чандыр гәүдәле кыз баланың сәхнәдән ни әйтергә, залдагыларга ни ишеттерергә теләгәнен аңладым бугай. Үтелгән кыска гына гомер юлында күргәннәрен, бөтен ачы хәсрәтен, каһәрле язмышын шул җырлары аша әйтеп биргән ләбаса!

– Их-х, – дим, – син бер атаклы җырчы буласы кеше идең бит!

Сизеп торам: аның бу темага сөйләшәсе килми. Артыңнан ияреп килгән хыял да бит кайчан да бер кайтарып булмаслык еллар артында кала. Миңа калса, тормыш сукмагының менә шулай бормалы, авыркатлаулы булуына, шуңа да карамастан, үзендә яшәү көче таба алуына ул шат, бәхетле дә бугай әле.

«Очып төшкән кош бит ул...»

Балачагы, үткәне турында искә төшерүе авыр аңа. Күңеле чиста кеше беркайчан да үзенә кылган явызлыклар турында кешегә сөйләми. Ә аңа исә сөйләве генә түгел, хәтеренә алу да мең газап. Шулай дип сүз куешабыз да, сүз үзеннән-үзе ябык темага барып тоташа.

Кукмара районының Купка авылында 1948 елны дөньяга килә Асылбикә. Сугыштан соңгы авыр чорлар... Ул чор балалары кузгалакның да, кычытканның да, өшегән бәрәңгенең дә тәмен яхшы белә. Бу хакта сүз куерта башлагач, мине шып туктата. «Безнең әби белән бабай мул тормышлы кешеләр иде. Булачак кияүне, ягъни минем әтине дә алар йортка керткән», – дип төзәтмә кертәсе итә. Бай тормышлы Гафифә әби белән бабайның бердәнбер кызлары Маһирәбикә Асылбикәнең әнисе була инде.

– Без өч бала идек. Бер туганыбыз күз тиеп үлгән, – дип сөйли Асылбикә. – Ул бик чибәр булган. Күз тию дигәннәре дөрестер, мөгаен. Аралашып йөри торган бердәнбер якын туганым – Мөхәрләм абый. Хәзер уйлыйм: кеше кулларына калуыбызга әти дә, әни дә – икесе дә гаепле булган. Әти Өшен авылына эшкә киткән җирдән кайтмаган, шунда торып калган. Ә Маһирәбикә миңа яшь ярым чагында өйдән чыгып киткән. Өч яшемә чаклы мине авыл апалары үстерешкән. Әле хәзер дә: «Мине әни дип йөртә идең», – диючеләр бар.

Ул вакытларда бүгенге шикелле химая һәм иганәчелек бүлекләре дә, адым саен ятимнәр йортлары да булмаган шул. Авыл кешеләре ятим калган баланы каядыр илтеп тапшырырга башына да китереп карамаган. Үзләре караган, үзләре тәрбияләгән. «Биш бала янына алтынчысы гына сыймыйча калмас...» дигәннәрдер инде. Малай әтисе янында үсә. Кулдан-кулга йөри торгач, нәни кызчыкка да бәхет елмая. Үлем белән йөзгә-йөз очрашып, сугыш утында йөргән артиллерист Бадыйк Билалов белән аның җәмәгате Гөлҗамалның, сөннәткә утыртканда вафат булган бәләкәч улларын җирләп, Швецбергеннан Әсән-Елгага (элеккеге Көек авылы) кайтып кына төшкән чаклары. Бабасы кулында кошчык сыман талпынган кызчыкны күрәләр дә: «Үзебез үстерербез, безгә бирегез», – дип ялваралар. Әйбәт кеше икәнлекләре күренеп тора, нигә бирмәскә?! Шулай итеп, бала Билаловлар гаиләсенә килеп эләгә. Асылбикә гаилә җылысының ни икәнен, әти белән әни арасындагы мөнәсәбәтләрнең менә шундый чиста-якын була алуын беренче мәртәбә шул гаиләгә килеп эләккәч күрә. Ул аларга яратып, кадерләп, ихлас күңелдән: «Әти, әни», – ди. Ә аның башка әти-әнисе юк та бит. Кыз үскәндә бик чая була. «Бервакыт әби белән бабай янына Купкага кунакка кайттым. Шунда бер хатын килеп керде. Әби әйтә: «Кызым, бу синең әниең», – ди. Ә мин торып бастым да: «Ике әни була алмый», – дип, чыгып йөгердем.

Сөйләшү барышында ялгыш та «әни» дип ычкындырмады. Гел исеме белән генә әйтте. Гәрчә аны күптән гафу иткән булса да...

Соңыннан да язмыш аларны, әллә сынап, әллә үртәп, гел очраштырып тора. Хәер, тормыш сукмаклары гел бер авылга килеп тоташкач, кая барасың?! Асылбикәне туган авылы тарта. Анда Маһирәбикәне еш күрә. Тик очрашканда гына алар бер-берсен күрмәмешкә салышып үтәләр. Бала – әнисен, әни баласын аңлар вакытлар соңрак, гомер узып барганда гына булыр.

БЕЛГЕЧ ФИКЕРЕ



Равия МУХИНА, Казан шәһәре 7 нче хастаханәсенең ревматология бүлеге мөдире.

Бу – бик сәер чир. Аңа тиз генә диагноз кую да мөмкин түгел. Чөнки пациент: «Бөтен җирем сызлый», – дип зарлана. Ныклап сораштыра, медицина тикшеренүләре үткәрә башлагач кына аңлашыла: авыруның буыннары сызлый икән ләбаса. Аның бөтен тәне сызлый: кулы, аягы, тез башлары, муенның умыртка ара буыннары... Кеше шешенеп китә, хәрәкәтләнү авырая, температура күтәрелә. Авыруларның күбесендә тиз ару, хәлсезлек, аппетит бетү, ябыгу галәмәтләре күренә.

Полиартритның сәбәпләре күптөрле. Шуңа да аның билгеләрен дөрес ачыкларга кирәк. Бүген моның өчен бөтен мөмкинлекләр бар. Дөрес һәм төгәл диагноз куелды исә, чирне дәвалау зур проблемалар тудырмый. Бигрәк тә, табибка вакытында мөрәҗәгать иткәндә. Мисалга, чирнең әле башлангыч кына чорында без авыруларны гормональ булмаган препаратлар белән дәвалыйбыз. Мәгълүм ки, һәр дару бер җирне дәвалый, икенчесен агулый. Организмда лейкоцитлар үзгәрергә, ашказаны авырта башларга мөмкин. Хәзерге яңа препаратлар шушы кимчелекләрне истә тотып эшләнгән дә инде.

Әгәр дә кеше ябыга башласа, гормоннар бирәбез. Мондый очракта преднизолон бик булыша. Моның ише дарулар ялкынсынуга каршы кулланыла. Чирнең төрле стадиясендә артритка каршы төп препаратлар тәкъдим ителә. Аларның күбесе ялкынсынуны баса. Авыру үзен яхшы хис итә башлый. Соңгы вакытта кулланыла башлаган биологик препаратлар чирне туктатуга юнәлтелгән иң үтемле чараларның берсе санала. Әмма чир тулысынча дәвалауга бирешми.

PRESSA.RU

Билаловлар бөтен игътибарны нәни кызчыкка юнәлтәләр. Бадыйкның әтисе Билал бабай: «Кызымны кыерсытасы булмагыз! Ул безгә һавадан төшкән кош шикелле...» – дип гел искәртеп тора.

Аның җырга осталыгын 1 нче сыйныфта укыганда ук күреп алалар. Кыз радиодан яңа җырлар өйрәнә дә укытучысына җырлый. Ә укытучы шул җырны башка балаларга да өйрәтә. Ул яшәгән Әсән-Елга авылында башлангыч мәктәп кенә. Асылбикә укуын 8 нче сыйныфка кадәр Пычак авылында

Унынчыны тәмамлагач, иптәш кызлары шәһәргә укырга китеп бара. Ә ул – хастаханәгә...

дәвам итә. Шул вакытларда башлана да инде аның михнәтләре. Сызлана, куллары шешә, озаклап урын өстендә яткан чаклары ешая бара. «Авыртмаган бер җирем юк. Ходаем, ни өчен миңа бу газаплар...» Кыз шулай инәлә. Табиблар аңа «ревматоидлы полиартрит» дигән хәтәр диагноз куялар. «Әгәр кызыгыз хәрәкәтләнмәсә, бармакларына эш тапмаса, хәле яман булачак», – дип, хөкем карары да чыгарып куялар.

– Әнигә рәхмәт, – ди Асылбикә ул вакытларны искә төшереп. – Авыртына башлыйм да бер почмакка барып утырам. Имеш, тимәсеннәр, күрмәсеннәр генә... Әни шундук йолкып диярлек урынымнан торгыза: «Нишләп утырасың, утырган җиреңдә кәкрәеп каласың бит», – дип мине тирги. Бармакларыма эш бик тиз табылды. Әни тегүче иде. Үзе дә тегә, мине дә тегәргә өйрәтә. Нәрсәләр генә, кемгә генә текми идек без?! Авылның иң оста тегүчеләре булганбыздыр, мөгаен. Аннары бәйләргә өйрәндем. Хәзер дә бәйләмәгән әйберем юк. Балаларыма да, якыннарыма да бәйлим, бәйлим, бәйлим... Чирем мәҗбүр итә, әни шулай өйрәтте.

«Ур-ра, бәрәңге сабагын чабарга кеше табылды

Асылбикәнең 5 нче сыйныфта укыган чагы идеме икән, өенә кайтып барышлый каршысына күрше кызы йөгереп чыкты да әйтә салды: «Ә сезгә ниндидер егет килгән...»

– Йөгереп кайттык та чаршау артына кереп шылдык иптәш кызым белән, – дип дәвам итә сүзен әңгәмәдәшем. – Эскәмиядә чибәр генә бер малай утыра. Күзәтә торгач, батыраеп киттем, сорыйм моннан: «Син кайсы авыл малае? Синең исемең Мөхәрләмме?» – дим. «Әйе», – ди бу. «Алайса, син минем абый буласың бит инде, – дим. – Ур-ра, бәрәңге сабагын чабарга кеше табылды», – дидем дә, шундук урамга атылдым. Абый да минем артымнан... Әти-әни эштән кайтканчы, ялт иттереп эшләп куйган иде шул чагында. Ә бит аңа нибары 14 яшьләр чамасы гына булган. Әтидән качып чыгып киткән дә, аны ятимнәр йортына озатырга дип, эзләп йөрүләре икән. Озатырга язу килеп төшкәч, әни әйтте: «Китәсең килмәсә, кал. Тик Асылбикә белән укырга барачаксың!» 5 нче һәм 6 нчы сыйныфны абый белән бергә бетердек. Аннары әни абыйны ФЗӨга урнаштырды. Алар безнең язмышка беркайчан да битараф калмады, үз балаларыдай карады.

«Көйгә-моңга тартылу – әтидән»

– Бик сызланган чагымда да: «Җырла әле...» – дисәләр, җырлый идем. Минем абый да оста гармунчы. Котдус әти гармунчы иде безнең. «Үлгәч, гармунымны каберем өстенә куярсыз», – ди ул. Без бу яктан аңа охшаганбыз. Калган яктан да охшаганбыз, дип әйтмим. Мин – Билаловлар кызы, мин аларга охшаган. Ә алар укымышлы, акыллы, тәрбияле нәсел!

«Асылбикә әллә нишләде»

– 7 нчене тәмамлагач, авырый башладым дигән идем. Авырсам да, укуны дәвам иттерәсем, зур сәхнәгә менәсем килде. – Асылбикә авыр сулап куя. – 9 нчы сыйныфка Кукмараның 1 нче мәктәбенә киттем. Күреп торам: бу сыйныфка кыз-малайларның иң асыллары җыелган. Сыйныф җитәкчесе (әйткәнем дога булып барып ирешсен) Нәсимә апа Авзалова үзе генә ни тора. Ул тиз арада безнең икенче әнигә әйләнде. Ләкин шулай да ул минем авырганымны белмәде. Югыйсә бик сизгер һәм гаҗәеп игътибарлы кеше иде. Соңыннан әйттем: «Нәсимә апа, мин бит каты авырыйм», – дидем. Хәйран калды. «Ялгыш та сиздермәдең бит», – ди. Безне авылларга концерт куярга чакыра торганнар иде. Хаста икәнемне белгәч, кыш көннәрендә Нәсимә апа мине юрганга төреп, чанага утырта. Ә егетләр алмаштилмәш тартып бара.

Интернатта яшәп укуын, акча кирәк булгач, әнисенең авыл мәктәбенә җыештыручы булып урнашуын, эшләп алган 13 сум 50 тиен акчаның 6 сумын аңа җибәреп торуын горурланып та, әрнеп тә сөйли Асылбикә.

«Холкым авыр» дисә дә...

Уку тәмамлангач, сыйныфташлары ялга кайсы кая таралыша, ә ул ике айга – җәйнең иң ямьле чагында – Казанга барып, инде һәр почмагы таныш булган, инде күрәсе дә килмәгән хастаханәсенә кереп ята. 11 нчене тәмамлагач та шул ук язмыш көтә. Кызның төшенкелеккә бирелгән чаклары да аз булмый. Мин кемгә кирәк? Мондый килеш нинди сәхнә? Ул инде хәзер әллә нинди өметләр белән яшәми. Бердәнбер теләге: кияүгә чыгып, кыз белән малай тапса иде дип кенә хыяллана!

Күз алдына ерак туганы – җәй көннәрендә Магнитогорскидан авылга кунакка кайтып йөргән егет килеп баса. Ул бит кызга бәләкәйдән гашыйк. Әле 6 нчы сыйныфта укыганда ук: «Әйдә, йөрибез», – дип тәкъдим ясаган иде. Кыз ул вакытта: «Туган булып калабыз», – дип кырт киссә дә, үсә төшкәч – кызлар дәрте кабынгач, гел егетне уйлый башлады.

– 1970 елны Бәкергә санаторийга бардым, – ди ул. – Хәлем әйбәтләнеп китте. Өйгә кайткач, алмалар турап утырам. Ә үзем Гарәфетдин (шул егет инде) кайтмасмы икән дим? Уйлап кына бетердем – ишек шакыйлар. Гарәфетдин! Чак артыма авып китмәдем! «Мин сине сулышым белән тартып китердем», – дидем. Озак та үтмәде, тәкъдим ясады. «Холкым авыр», – дип тә кисәтте. «Ничек тә түзәрмен», – дидем. Пычак авыл советына төштек тә язылышып мендек. Шуннан бирле мин – Гафарова Асылбикә Бадыйк кызы... Ул миңа Ходайның бүләге. Күпме гомер итеп бер мәртәбә кычкырышканны, сүзгә килешкәнне хәтерләмим. Ходай, теләгәнемчә, миңа бер кыз, бер малай бирде. Маратым белән Миләүшәмнең бүген үз тормышлары. Шөкер, матур яшиләр. Алар өчен борчылмыйм. Гарәфетдинем генә моннан өч ел элек гүр иясе булды. Аның әтисе 66 яшендә инсульттан үлеп китте. Гарәфетдин дә нәкъ шул яшьтә шушы чирдән китеп барды.

Егерме елдан соң...

«Улым тугач, шатлануларым», – дигәндә, аның күзләренә яшь килә. Көтеп алынган шатлык, көтеп алынган яшәү мәгънәсе ич ул аның. Аннары... кызы. Төннәр буе сызланып чыкканда, иренең дә керфек какмыйча, янында бәргәләнүе, Асылбикәсенең хәлен җиңеләйтә алмавына гаҗиз булып, арлы-бирле йөренә башлавы һаман да аның күз алдында. Хатыны җилкәсенә төшкән авырлыкны ир, чын мәгънәсендә, ирләрчә күтәрде. Ә болай иткәч, җиңелрәк икән ул! Асылбикәсе моны ирен югалткач тагын да ныграк аңлады.

Үземнекен таптым дип, бербәрсен ярты сүздән аңлап яши торган парлар турында әйтәләрдер. Алар шундый иде. Алар арасында аңлашылмаган, яшеренеп күңел түрендә калган сүзләр булмады. Кара-каршы утырып, күзгә-күз карашып бер сөйләшү җитә торган иде. Әнисенә карап кызы дигәндәй, иренең бу җәһәттән шик белдергән чагы да булмады түгел. Тик Асылбикәнең зирәклеге бу очракта һәрвакыт өстенлек ала иде.

Үз гомерендә ул Кукмараның данлыклы 6 нчы тегү фабрикасында да эшләгән. Унынчыны тәмамлауга нәкъ егерме ел вакыт узып киткәннән соң, Казан кооперация техникумында укып, чирек гасыр сәүдә базасында баш бухгалтер урынбасары булып та эшләгән. Өйдә исә азга гына да бәйләү-тегүчигү эшләрен ташламаган.

«Мин аны кичердем»

– Мин аны төшемдә күрдем. «Миннән гафу үтен...» – дидем, ә ул: «Нәрсә өчен?» – диде. Мин аңа гомер буе үземнең төшеп калганнардан түгеллегемне күрсәттем. Бер чирләшкә дип уйламасын, дидем. «Уңышларым турында ишетәме икән?» – дип уйлый торган идем. Үкендерәсем, ник болай эшләдем, дигән сүзләрне ишетәсем килә иде. Көтеп ала алмадым.

Шулай да Асылбикә 86 яшендә дөнья куйган Маһирәбикә карчыкка 55 яшенә, аны кичерү билгесе итеп, кабарып торган мамык шәл бәйләп җибәрә. Аннан төнге күлмәк белән халат тегеп бүләк итә. Әни кеше: «Мине күргәне дә юк, үлчәгәне дә юк, ничек шулай оста теккән», – дип хәйран кала.

– 60 яшенә дә ак мамык шәл бәйләдем, – ди Асылбикә. – Миннән калмасын, дидем. Мин аны инде күптән гафу иттем.

...Очрашу ахырына якынлаша. «Җырла әле...» – дим Асылбикәгә. Ялындырмый, җырлый башлый да, кинәт туктап кала. «Булмый инде, булмый, – ди әчке бер тетрәнү белән, – җырлар алар менә монда – йөрәгемдә!» – дип, кулын күкрәгенә куя.

Йөрәгенә азга гына да тынгылык бирмичә, әле ташкын булып ярсыган, әле ялкын булып көйдерептелеп алган күңел җырлары – җырланмый калган җырлары йөртәдер аны, катлы-катлы сынауларны кичәргә нәкъ менә шул моңнар ярдәм итәдер сыман. Һәрхәлдә, минем үземә шулай тоела.



Ольга ПАВЛОВА,
ТР Дәүләт Советы депутаты, ТР Дәүләт Советының социаль сәясәт комитеты әгъзасы,
«Бердәм Россия» фракциясе әгъзасы:

«Инвалид хатын-кызлар турында ишетеп кенә белмим. Татарстан Дәүләт Советының социаль сәясәт комитеты әгъзасы буларак, бу мәсьәлә белән шөгыльләнүче министрлыклар һәм ведомстволар белән берлектә, миңа көн саен мөмкинлекләре чикле булган кешеләрнең проблемаларын хәл итүдә катнашырга туры килә.

2011 елдан бирле, инвалидларга уңай мохит тудыру федераль һәм республика программалары кысаларында, эре шәһәрләрдә мөмкинлекләре чикле кешеләр өчен 15 спорт объекты сафка бастырылды. Быел тагын 18 шундый объект файдалануга тапшырылачак. Татарстанда барысы 323544 инвалид бар, шуның 14100 е – балалар.

Ел саен Татарстанда инвалидлар өчен спортның төрләре буенча дистәләгән спорт уеннары – чемпионатлар үткәрелә. Былтыр үткәрелгән шундый чараларда республиканың төрле район һәм шәһәрләреннән 1200 гә якын спортчы катнашты.

Хөкүмәтебез, паралимпия һәм сурдалимпия спортын үстерү максатында, былтыр Казанда «Республика балалар һәм яшүсмерләр өчен спорт-адаптация мәктәбе» ачып җибәрде. Быел аның бүлекчәсен Чаллы шәһәрендә дә эшләтеп җибәрү көтелә. Сочидагы Паралимпиадада катнашкан спортчыларыбыз Россия җыелма командасына ике алтын, бер көмеш һәм бер бронза медаль китерде.

2014 елдан бирле үткәрелеп килгән «Татарстанның энҗе бөртекләре» республика бәйгесе дә инвалид хатын-кызларны җәмгыятькә кирәкле шәхес итеп таныту өчен эшләнә. Без – «Мәрхәмәт» хатын-кыз депутатлар берләшмәсе – әлеге бәйгене оештыручылар.

Бүген республикада һәркемгә тигез мөмкинлекләр тудыру өчен зур эшләр башкарыла. Һәм без дә мөмкинлекләре чикле кешеләргә ярдәм кулы сузарга һәрвакыт әзер.»

PRESSA.RU



АНДА ТАҢНАР ЯКТЫРАК...

Эльза НӘБИУЛЛИНА

ӘЗӘРБАЙҖАН, ГРУЗИЯ, ДАГСТАН, ТӨРКИЯ, ТАИЛАНД, ИНДОНЕЗИЯ, АВСТРАЛИЯ... БУ ИЛЛӘРНЕ АРКЫЛЫГА-БУЙГА ГИЗДЕЛӘР ИНДЕ: АЛАР – ИРЕКЛЕ СӘЯХӘТЧЕЛӘР.

Кайсы илгә аяк бассалар да, аның нинди урыннарын күрергә, кайда, күпме тукталырга икәнен үзләре хәл итә. Искәндәр белән Эльза тагын юлда. Сәфәрләренең төп максаты – Скандинавия илләре табигате белән танышу. Урта һәм Көнчыгыш Европа илләрен карау турында да хыялланалар. Бүген без сезгә Эльза юлъязмасыннан тагын бер өзек тәкъдим итәбез.





Беренче көн

Аллага тапшырдык! Барысы да без уйлаганча булсын дип телик... Әлегә ирем белән икәү машинабызда Финляндия һәм Швеция аша Норвегиягә юл тотабыз. Иртәнге өченче яртыда Казаннан чыктык. Шәһәр әле изрәп йоклап калды...

Эссе һавалы Казаннан соң яңгырлы шәһәрләр каршы ала: Чабаксар, Түбән Новгород, Мәскәү... Озын юлларда барганда, ирексездән: «Ә элек ничек йөргәннәр икән?» дип уйлый башлыйсың. «Әнә, Пьер Безухов Мәскәүдән Петербургка барган бит», – ди Искәндәр. «Поезд беләнме?» – дим мин. «Поезд булганмы соң ул вакытта?» – ди Искәндәр. Анна Каренина Питердан Мәскәүгә поезд белән килгән инде – анысын төгәл беләм... Юл буе Пьер Безуховның Петербургтан Мәскәүгә ничек барганын искә төшерергә тырыштык.

Икенче көн

Безнең белән Санкт-Петербургтан Финляндиянең Суоненйоки шәһәренә кадәр тагын ике кыз бара. Алар blabla car аша тапты безне. Кызлар барасы урын – җиләк фермаларына бай булган өлкә. «Өченче ел инде җәйгә шунда эшкә урнашабыз. Бер атнадан зур җиләк фестивале булачак», – дип сөйләде кызлар.

Финляндия тарафына чыккач, манзара кискен үзгәрә: иң элек юлларга игътибар итәсең, билгеле. Машина юлына параллель велосипед юллары бара. Икенчедән, табигать үзгә: күлләр, бераз калкулыклы урыннар, җиләккә һәм мүккә бай урманнар... Ә мүк һава бик чиста булган урында гына болай мул булып үсә ди Искәндәр.

Юллар яхшы булса да, чикләүләр кертелгән: сәгатенә 60-80 чакрымнан артык тизлек белән барырга ярамый. Һәм, билгеле, бу кагыйдәне бозучы юк. Һәм, билгеле, бу кагыйдәне берәү дә бозмый.

Кызларны тиешле урынга илткәнче, төнге сәгать уникеләр булды. Әмма бередә караңгы төшми, төньякка барган саен, төннәр яктырак. Уңайлы урын табып, палаткабызны җәйдек. Һава салкынча, бераз яңгыр сибәли.

Өченче көн

Көнебезне 67 нче киңлектә – котып сызыгы артында төгәлләдек. Әмма көн үзе бередә төгәлләнми: кояш ни чыкмый, ни батмый. Кызык: сәгать төнге 11, ә син кояштан саклanучы күзлек киясең.

Иртәнге җидедә үк тордык та, яңгыр яуганчы, дип,

Кояш җәйге чорда бер чыга да, кышка гына байый. Моны котып көне дип атыйлар.

палатканы җыеп, Швециягә таба юл алдык. Юлда туктальшлар ясап, кечкенә шәһәрләрне карадык, кибетләргә сугылдык, капкалап алдык, урманга да туктадык. Урманнар җиләккә бай монда! Юлдан ерак та түгел күпләп караҗиләк (черника) үсә, бераз шуны җыйдым. Искәндәр үсемлекләрне фотога төшерде, укучыларыма күрсәтәм, дип, үзе белән ике төр мүк тә алды. Овертурнеа шәһәрендә Швеция ягына чыктык. Чикне узу минем өчен көтелмәгәнчәрәк булды. Ниндидер контроль постлар булыр дип көткән идем. Баксаң, Шенген зонасы илләрендә берсеннән икенчесенә күрше авылга барган кебек кенә йөриләр икән. Гади генә күперне кичтек тә чыктык! Аптыраштa калуымны күреп, Искәндәр, кире борылып, күпернең теге ягыннан – Финляндиядән урап килде. Шулай итеп, Швециягә ике тапкыр кердек!

Дүртенче көн

Без Норвегиядә! Үзеңне әкият дөньясына эләккәндәй хис итәсең: бөтен җир матур! Без Нарвик шәһәре ягын-

PRESSA.RU





нан килдек. Төньяк бу. Әмма һава җылырак. Хәтта бүген кояшны күрү насыйп булды. Ә һаваның җылылыгы диңгездәге җылы агым – Гольфстрим белән бәйле.

Халык рәхәт итеп, тормышның тәмен белеп яши кебек биредә.

Беренче тукталышыбыз – Лонгея утравына урнашкан балыкчылар шәһәрчеге Мюре. Зур шәһәрләрдә дә, кечерәкләрендә дә халыкның тормышы бертигез дәрәҗәдә җитеш, яхшы. Безне пенсионер Торбьерн абый гаиләсе кунак итә. Үзе – норвегияле, хатыны – филиппинлы. Күп еллар дәвамында безнең кебек сәяхәтчеләрне үзләрендә кабул итәләр. Аларны couchsurfiring аша таптык. Озаклап сөйләшеп утырдык. «Яңа кешеләр белән аралашу офыкларны киңәйтә, бу – безнең байлыгыбыз. Шәхси милкеңне урлап та китәргә мөмкиннәр, ә бу байлыкка беркем кул суза алмый», – дип сөйләде ул безгә.

Йокларга ятар алдыннан безгә: «Good night» – дип теләделәр. Урамда яп-якты! «Хәерле төн!» дию ничектер сәеррәк яңгырый... «Ә кышкы чорда ике ай дөм караңгы була. Күптән күнектек: йолдызларга карыйсың, Төньяк балкышны күрәсең... Уйландыра торган мизгелләр... Үзеңнең зур галәмдә никадәр кечкенә икәнеңне аңлыйсың», – ди Торбьерн абый.

Бишенче көн

Томан, яңгыр сибәли. Тауга менеп биектән кыяларга карарбыз, шәһәрне күзәтербез дигән идек... Торбьерн абый белән Тина ханым, иртәнге аш белән сыйлаганнан соң, Мюредан ерак та булмаган балыкчылар авылына алып киттеләр. Биредә нибары 15-20 кеше яшидер, әмма туристлар даими килеп торгач, ресторан, кафе, музей, кибетләр эшләп тора. Кафега кереп каһвә эчтек, туган илләребез хакында гәпләшеп утырдык. Төшке аш вакытында Тина ханым безне парда пешерелгән яшелчәләр һәм балык фрикаделькалары белән сыйлады. Бар да гади, әмма искиткеч тәмле!

Бераздан кабат юлга кузгалдык. Исәп – Лафатен утрауларына барып чыгу. Халык үзе телэгән җиргә йортлар салган: кайсы кыя өстендә, кайсы күл буенда, кайсы диңгезгә үк кертеп төзегән. Бер урында туктап, Искәндәр кармак салып карарга булды. Биш тапкыр кармагын атуга дүрт балык эләкте! Балыкчы өчен иң бәхетле мизгелләр! «Димәк, кичке ашыбыз бар», – диде ул.

Җиденче көн

Лафатенның Рейне шәһәрен югарыдан карар өчен тауга мендек. Болытлар бүген түбән йөзә. Тауның яртысына менеп җитүгә болытларга күмелдек. Тау үзе биек түгел, якынча 600 метр, әмма бик текә. Бераз шыңшып та алдым, ләкин менгәч, «ах-вах»лар онытылды...

Сигезенче көн

Көннең иң истә калган мизгеле – Свартисон бозлыкларын карарга бару. 1860 метр биеклектә урнашкан бу бозлыклар тирәсендә кар ята, шуннан бик күп шарлавыклар агып төшә. Бер мизгелдә җәйдән салкын һавага күчәсең. Шунда ук җылы киемнәрне киеп, июль карына басып, фотога төшәргә ашыктык. Кызыл (!) кар күрдек! Искәндәр аңлатуынча, ул кайбер суүсемнәре тәэсирендә шундый ал төскә керә.

Унынчы көн

Кристиансунга, Атлантик океан ярына юнәлдек. Кристиансун – зур булмаган шәһәр, бар кеше диярлек үз йорты белән яши. Аңа фьорд астыннан узган 6 чакрымлык тоннель илтә. Искәндәр шаярта: «Тоннель ка-



■ **Алтынчы көн** Көнебезне Лафатен утрауларына багышладык. Югарыдан – кыядан – диңгезгә, шәһәргә, фьордларга искитмәле күренеш ачыла. Утраулар үзара күперләр белән тоташкан. Алар бик үзенчәлекле: урта өлешләре калку ясалган. Шуңа күрә күпер болытларга илткән юл сыман тоела.

зу – норвегиялеләрнең хоббие, ахрысы», – ди. Шәһәрдә озак тормадык, Атлантик роуд дигән юлга таба киттек. Берничә вак утрау аша узучы 10 чакрымга сузылган машина юлы ул. Туристлар күп анда. Алар еш кына интернетка: «Бу – дөньядагы иң матур юл!» – дип язалар.

Бу регионда балык күп. Юл читендә, балык күп тотыла торган урыннарда, балык сурәте төшкән махсус тамгалар куелган. Балыкның күплеген акчарлаклар да сиздерә: алар монда симезрәк, шуңа күрә түбәнрәк очалар кебек тоелды безгә. Балыктан безгә дә өлеш чыкты – Искәндәр тагын бер скумбрия эләктерде.

Унберенче көн

Норвегиядә тагын бер әкияти көн уздырдык. Беренче тукталышыбыз – Тролльләр юлы дип аталган искитмәле урын. Тролльләр турында Норвегиядә төрле ышанулар яши. Имеш, алар – шушы тау куышларында яшәүче ямьсез гәүдәле зур җан ияләре. Безнең Шүрәлегә охшаган образ булып чыга инде. Аннан Гейрангер-фьордына юнәлдек. Норвегиянең йөрәге, үзәге диләр аны. Үзәндә йортлар, кунакханәләр урнашкан. Матур! Туристлар күп, һәр җирдәгечә күбесе – кытайлар. Искәндәр миңа аңлата: «Кытайлар дөньядагы барлык кешеләрнең биштән берен тәшкил итә. Шуңа күрә һәр очраткан бишенче кешенең кытай булуына син әзер булырга тиеш», – ди.

Уникенче көн

Бүген тагын бер бозлыкны күрдек. Негартзбринг бозлыгын хәтта тотып та карый алдык. Ул шундый зур һәм зәңгәрсу. Без күргән урыны бозлыкның бер «теле» генә дип атала. Аның астыннан елга булып шундый ук зәңгәр су агып чыга. Ташларга бәрелә-бәрелә, бик күп бормалар ясап, җитез ага. Кешеләр бозлыкның өстенә менәргә дип махсус җайланмалар да әзерләп килгәннәр. Кызганыч, безнең «Адидас» кроссовкалары әлегә мондый функцияне үти алырлык түгел...

«Чик-чик»: куллар өскә, боз һәм мин, мин һәм боз, куллар бозга тия һәм башка төрле композицияләр ясап, әллә ничә кат фотога төшкәннән соң, ниһаять, кире юлга чыктык. Машина юлыннан бу бозлыкка кадәр ике чакрым чамасы кыялар буенча атларга кирәк. Авыр түгел анысы. Әмма еш кына мондый урыннарда минем фантазиям активлаша. Янәсе, менә мин бозга тотынгач кына, аның бер өлеше кинәт аерылып килеп төшә. Әмма мин югалып калмам: шул бозлыкка тотынып, тау елгасында агым уңаена агармын...

Унөченче көн

Йокыдан уянганда яңгыр ява иде. Озак уйлап тормадык, башкалага – Ослога киттек. Чөнки безне Норвегиягә килгән көннән бирле дустыбыз Багир зарыгып көтә. Багир чыгышы белән Рәсәйдән, Дагстан егете. Чит илдә ярты гомереннән артык яшәвенә карамастан, таулар җылысы, киң күңеллелек аның канында. Әнә, һаман: «Для нас, горцев...» – дип сөйләвен дәвам итә.

Монда җәйге чорда да чаңгы ярышлары үткәрелә. Король гаиләсе дә ярышларда актив катнаша.

Ундүртенче көн

Осло белән танышабыз. Музейлар, истәлекле урыннарга бай шәһәр ул. Иң элек каланың иң югары ноктасы булган Хольменколлен калкулыгына тукталдык. Биредә чаңгы трамплины, дөньядагы иң иске чаңгы музее, биатлон трассасы урнашкан. Ел саен биатлон буенча Дөнья кубогы чемпионаты да монда уза. Чаңгы шуу – норвегиялеләр өчен чын-чынлап милли спорт төре, яшәү рәвеше. Шәһәр урамнарында җәен дә күпсанлы чаңгычыларның махсус тәгәрмәч көйләнгән чаңгыларда йөрүләрен күрергә була. Чаңгы музее белән танышып чыкканнан соң, бу төр спорт белән шөгыльләнү теләге бермә-бер арта. Музейда төрле тарихи экспонатлар белән беррәттән, 40 яшендә сигезенче тапкыр Олимпия уеннары чемпионы булган Бьордаленның спорт җиһазлары да саклана.

Минем өчен Ослодагы тагын бер мөһим урын – ул Тынычлык өчен Нобель премиясе үзәге. Нобель премиясе ел да Швеция башкаласы Стокгольмда тапшырыла. Әмма берсе генә – Ослода. Аңа, кыска гына итеп әйтсәк, дөньяда тынычлык, тигезлек урнаштыруга хезмәт иткән кешеләр лаек була. Тынычлык премиясенә ия булу – ул минем дә матур бер хыялым. Әлеге үзәккә эләккәч, шушы хыялыма якынайган кебек булдым.

Бу – Норвегиядәге соңгы кичебез. Төнлә, паромга утырып, Даниягә, аннан Германиягә юл алабыз.



Язманы тулы килеш сайтыбызда Эльзаның блогыннан укый аласыз.

PRESSA.RU

16+

ИР-АТ ЧЫНЛАП ЯРАТСАМЫ?!



Равил САБЫР – драматург;
өйләнгән;
гаилә стажы – 21 ел;
олы улы Рәзимгә – 20;
кече улы Ришатка 14 яшь.

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик.

1 Иң элек хатын-кызда нәрсәгә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Күзләренә инде, әлбәттә!

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Яратсаң – барысын да. Минем «Сигезле бию» дигән пьесамда шундый өзек бар. Мәрьям Ләйләгә сорау бирә: «Ул сиңа тәкъдим дә ясадымы?»

Ләйлә: «Ниндидер бер бик мөһим сүз әйтәсе бар аның миңа. Бүген төшкә кадәр шалтыратырга тиеш иде, тик, нигәдер, хәбәре юк. Аптырагач, үзем җыеп караган идем, телефонын сүндергән. Ни уйларга да белмим».

Мәрьям: «Чынлап торып яратса, әллә кайчан шалтыраткан булыр иде инде! Мөһим сүзне телефоннан әйтмиләр аны, күзгә күз карап әйтәләр. Чынлап торып яратсамы ир-ат?! Чынлап торып яратса, ул хатын-кызны башка кеше кочагыннан тартып алып та өйләнә!»

3 Ә нәрсә өчен Сез бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Ялган өчен. Кечкенә ялган була, төгәлрәге, дөресен әйтмәү. Гаиләдәге тынычлыкны, үзара мөнәсәбәтләрне вак-төяк белән бозмас өчен барлыкка килә торган ялган. Ә тагын зур ялган бар – хыянәт... Ул берничек тә гафу ителә торган әйбер түгел.

4 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм аңа өйдә комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә аның кайсысы якынрак?

– Алиһәләр еракта ич алар...

5 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

– Чехов ни ди әле? Хатын-кыз ир-атның дустына әверелгәнче башта аның әшнәсе, соңрак сөяркәсе булырга тиеш, аннары гына инде дус, ди. Хәер, Чехов бик күп бәхәсләр тудыра торган драматург.

6 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганны хәтерлисезме?

– Хәтерлим, әлбәттә! Тик ни рәвешле икәнен сөйләмим... Бер генә нәрсә әйтә алам, хатыным: «Кайчан әйтер икән, дип, гел көтеп йөрдем, тик барыбер көтелмәгәнчә килеп чыкты», – диде.

Көтелмәгән, кызыклы очраклар күп була инде ул яшь чакта. Без Римма белән авылда җәй көне таныштык, каникул вакытында. Икенче көнне ул шәһәргә китте. Тагын бер-ике көн узгач, мин дә шул шәһәргә барып чыктым. Без бер егет белән үзебезчә бик зур планнар корган идек, тик ул эш барып чыкмады. Мин Риммага шалтыраттым: «Мин сезнең якларга килеп чыктым әле, әйдә, – мин әйтәм, – очрашабыз». «Юк, – ди бу, – беркая да бара алмыйм, безнең өйдә кунаклар бар, аларны ташлап чыгып китә алмыйм», – ди. «Мин хәзер киләм, җыена тор», – дидем дә трубканы куйдым.

Шикләнә-шикләнә генә бардым мин боларга. Килеп керсәм, ни күзем белән күрим, Римма өйдә берүзе генә, төгәлрәге, алар гаиләсеннән башка берәү дә юк. Кухняда дүрт егет утыра, Римма аларны чәй белән сыйлый. Мине дә чакырды бу чәй эчәргә. «Рәхмәт, – мин әйтәм, – вакыт юк, соңга калабыз, әйдә киттек тизрәк!» «Ярар алайса, хәзер киемнәремне генә алыштырам», – диде дә бу, икенче бүлмәгә чыгып китте. Мин ишек төбендә басып торам, теге егетләр бер сүз дәшми чәй эчәләр.

Күп тә үтмәде, матур күлмәкләрен киеп, Римма да килеп чыкты. «Ярар, егетләр, ачуланмагыз инде. Тагын чәй эчәсегез килсә, үзегез ясап эчәрсез. Киткәндә ишекне бикләргә онытмагыз, ачкычны коврик астына яшереп куярсыз», – диде дә, без аның белән чыгып киттек. Урамда сорадым Риммадан: «Кемнәр соң

болар?» – дим. «Просто дуслар», – ди. «Дүртесе дәме?» – дим. «Дүртесе дә», – диде ул елмаеп...

7 **Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый диләр, шулаймы?**

– Минемчә, кызлар күбрәк әтиләренә охшаган егетләрне сайлый.

8 **Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?**

– Белмим шул... Алъяпкыч кияргәдер инде, яулык бәйләргә, токмач басарга...

9 **Гашыйк булуын хатын-кыз үзе белдерүгә ничек карыйсыз?**

– Белдерүгәме, әйтүгәме? Караш белән дә белдереп була бит, елмаю белән дә... Хәер, ир-ат арасында шундыйлары да бар, аларга маңгайларына бәреп әйтү кирәк.

10 **Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип саныйсыз?**

– Күзләре инде, әлбәттә!

11 **Хатын-кызларның үзегезнең кайсы якларыгызга игътибар итүен көтәсез?**

– Көтмим. Көтеп яшәсәң бу дөньяда...

12 **Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта, диләр. Бу чынлап та шулаймы?**

– Мәктәптә укыганда мине бер укытучым: «Ыслишком умный!» – дип сүгә торган иде. Акылның артыгы да буламы икән, дип аптырый идем, хәзер дә бу сорауга җавап таба алганым юк. «Артык чибәр» ничек була соң ул? Кай җире артык булырга мөмкин чибәрлекнең, матурлыкның? Берәр мисал китерә аласызмы? Ә кайбер хатын-кызлар кайбер ир-атларны чыннан да куркыта, анысы хак.

13 **Ир-ат һәм хатын-кыз логикасы дигән төшенчә бар. Алар сезнеңчә бер-берсеннән нәрсә белән аерыла?**

– Йорт төзер өчен ир-ат нәрсә эшли? Башта акча җыя, әкренләп төзелеш материаллары сатып ала, нигез сала, бер кирпеч өстенә икенчесен урнаштыра-урнаштыра стенасын күтәрә, түбәсен яба һәм башкасы, һәм башкасы... Ә хатын-кыз нәрсә эшли? Башта: «Яңа йорт кирәк!» – дип, берничә ел иренең колак итен ашый, аннары «ник ак кирпеч алдың, кызылы кирәк иде», ди, түбәне калай белән япканга да риза булмаска мөмкин, әйтик, шифер очсызрак дияе бар. Ахыр чиктә, йорт төзелеп беткәч, анда көченер вакыт җиткәч, – ә менә хәзер иң кызыгы! – «И-и-и, нигә кирәк иде инде безгә бу яңа йорт?! Күпме акча, көч түгеп ничә ел сарыф иттек шуңа! Бу иске йортыбыз да бик әйбәт бит әле, мин моннан беркая да күчмим!» – ди... Менә сезгә аерма. Җыеп әйткәндә, ир-ат логикасы – ул бик коры, күңелсез әйбер, үзенә күрә проза, ә хатын-кызныкы – поэзия!

14 **Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен үзегез аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.**

– Аңлыйм кебек үзе мин хатын-кызның ни өчен теге яки бу гамәл эшләгәнен... Хәер, менә минем хәләл җефетем көн саен иртән эшкә барырга җыенганда көзге каршында чәчләрен бөдрәләтә. Аның махсус электр җайланмасы да бар, «плойка» дип атала бугай. Менә шуның белән чәчләрен кызды-ра-кыздыра бөдрәләтә дә... аннары тарак белән тарап турайтып бетерә һәм ул бөдрәләрдән берни дә калмый!

15 **Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный.**

– Юк, юл куймыйм: үземне хаклы дип санасам. Аңлатам, мисаллар китерәм, исбатлыйм, тик барыбер үземчә эшлим. Ә хатын үзенчә...

16 **Шундый очракны күзаллыйк әле: сез ачыгып, арыпталып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән...**

– Юк инде, бергәләп пешерәбез. Мин дә арып кайтам ла инде ул эштән.

17 **Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан...**

– Көрәшмим, сузылам да ятам диванга. Хатын, эшләре бетеп: «Мин әзер, киттек!» – дип, ишек төбенә килеп басмыйча, тормыйм. Үз-үзеңне юкка бимазалаудан ни мәгънә? Кешенең нерв күзәнәкләре чикле һәм үлгәннәре урынына яңалары тумый, диләр бит...

18 **Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә. Сез алган бүләкләрнең иң ошаганы һәм ошамаганы?**

– Бүләк ел саен шул бер стандарт инде: носки, майка, футболка, одеколон, кырынгыч. Хәер, бер елны әби (хәләл җефетемнең әнисе) алтын чылбыр бүләк иткән иде туган көнемә. Бәясе дә хәйран гына булгандыр әле. Тик менә мин генә алтынны бик өнәп бетермим. Никах балдагы бармакны сызлатты минем нигәдер, шуңа күрә кими башладым. Бу бүләк ителгән чылбыр исә муенны кычыттырды. Ятмый миңа алтын, кыскасы! Минем хатын ярата инде ул алтынны, һай, ярата! Балдакны да, чылбырны да аңа бирдем, ул алтыннарны эретеп, үзенә ниндидер бизәнү әйбере ясатты. Ә берничә ел элек, булмады инде бу, үзем-үзем бүләк ясарга туры килә, дип, туган көнемдә яңа машина алып кайттым.

PRESSA.RU





Наталья АЛЕКСАНДРОВА, ОНКОпрофи медицина клиникасының гинеколог-онкологы

ДИСПЛАЗИЯ

Дисплазия – гинекологка баргач, шушы диагнозны ишетсә, хатын-кыз куркып, югалып кала. Әйе, куркыр өчен сәбәп бар – бу инде онкологиягә бер генә адым калган дигәнне дә аңлата ала. Мөмкин чакта чарасын күрмәсәң, ул яман чиргә әйләнеп китәргә мөмкин. Әмма вакытында күреп алып, чарасын күрсәң, аны дәвалау авыр түгел.
Нәрсә соң ул? Гинекологиядә бу диагноз аналык муентыгының лайлалы тышчасында күзәнәкләр төзелеше үзгәргәндә куела. Алар тыгызлана, үсә башлый, эпителийны боза... Күбрәк моның белән 25-30 яшьләр тирәсендәге хатын-кызлар җәфалана. Бүген бу мәкерле чирнең сәбәпләре һәм аны аздырмау юллары турында сөйләшик.

Нидән гыйбарәт?

Аналык муентыгы күпкатлы эпителий белән капланган. Әмма кайчак аның лайлалы тышчасында, инде әйткәнебезчә, күзәнәкләр төзелеше үзгәрә башлый. Дисплазия дигәнебез шул була инде. Эпителий катламында күзәнәкләр тыгызлануы һәм үсеше сизелә, күзәнәкләрнең яңару, өлгерү һәм башка процесслары да бозыла. Әкренләп, бу яман үзгәреш алырга мөмкин. Аналык муентыгындагы эрозиядән аермалы буларак, дисплазия өске катламнарны гына зарарлап калмый, тирәнгәрәк үтеп керә.

Чир бик астыртын – чөнки аның билгеләре күзгә ташланып тормый. Һәм бары профилактик күзәтүләр барышында гына билгеле була. Шуңа күрә һәр хатын-кыз елына бер тапкыр аналык муентыгын каратырга тиеш! Шунысы мөһим: дисплазия диагнозы куелганда, аны ачыклауның өч ысулын да – кольпоскопия (микроскоп аша карау), PAP-тест (эпителийның цитоморфологиясен тикшерү), биопсия (шикле урыннан алынган кисәкчекнең гистологиясен тикшерү) кулланырга кирәк. Боларның бөтенесен онколог-гинекологка күренгәндә узып була.

Сәбәбе

Дисплазиянең төп сәбәпләреннән берсе – хатын-кыз организмында папиллома вируслары булу санала (һәркайсы түгел – ә онкологик яктан куркыныч саналган ВПЧ-16 һәм ВПЧ-18 формалары). 1-1,5 ел дәва-

мында дәваланмыйча калдырылган бу вируслар эпителийда үзгәрешләр ясап, дисплазия барлыкка килә. Статистика күрсәткәнчә, мондый диагнозлы пациентларның 95-98 процентында шушы вирус табылган. Әмма чирнең баш калкытуында башка факторларның тәэсире зур. Алар арасында:

- гормональ үзгәрешләр (менопауза, йөклелек, авырга узмау чаралары куллану, гормонлы матдәләрдән файдалану);
- җенси тормыш белән иртә (16 яшькә кадәр) яши башлау;
- аналык муентыгын җәрәхәтләү;
- җенси юл белән күчкән инфекцияләр;
- тәмәке тарту һәм алкоголь белән мавыгулар;
- стресслар, күп дару эчүләр, хроник чирләр;
- чисталык җитенкерәмәү;
- күп тапкыр бала табу;
- бала төшертүләр;
- организмга А, С витаминнары, микроэлементлар җитмәү;
- аналык муентыгында эрозия, лейкоплакия һәм начар фон булдыручы башка чирләр.

Билгеләре

Лайлалы тышчаның (эпителийның) ни дәрәҗәдә зарарлануына карап, дисплазия өч төрле була:

- беренче (җиңелчә) дәрәҗә – эпителийның 1/3 зарарлануы;
- икенче (уртача) дәрәҗә – 2/3 артыграк өлеше үзгәрешкә дучар булуы;
- өченче (авыр) дәрәҗә – бөтен катламның үзгәрүе.

Гадәттә, дисплазиянең җиңелчә һәм уртача дәрәҗәсе үзен берничек тә белдерми. Хатын-кызның һәр унынчысында бу чир яшертен генә уза. Ул авыр форма алганда, җенес органнары кычыта, әчеттереп тора. Якынлык кылганда авырту сизелә, җенес юлыннан күп итеп бүлендек яисә канлы бүлендек килә башлый.

Нәрсәсе куркыныч?

Әйтелгәнчә, чарасын күрмәсәң, дисплазия яман чиргә әйләнергә мөмкин. Кучеш чоры организмның, иммун системасының ныклыгына бәйле. Ләкин шуны истән чыгармыйк: дисплазияне дәвалап була. Шуңа да гинекологка, гинеколог-онкологка күренергә онытмагыз!

Ничек дәваланырга?

Анысы инде чирнең организмда ни дәрәҗәдә азуына, хатын-кызның яшенә, хатын-кызның бала табу теләгенә карый. 1-2 дәрәҗәдәге дисплазияне участок гинекологы да дәвалый ала. Ә менә авыр формадагысын гинеколог-онколог карый. Чирне бары аның ярдәме белән генә җиңеп чыгарга мөмкин. Мондый очракта хирургларга да мөрәҗәгать итәргә туры килә. Операциядән соң эч авыртулар һәм җенес юлыннан күпләп лайлалы бүлендек килүләр булырга да мөмкин. Шуңа күрә хатын-кыз 4-6 атна җенси мөнәсәбәтләрдән тыелып торырга, авыр күтәрмәскә, мунча-сауна һәм ванна кермәскә, тампоннар кулланмаска тиеш.

Авырга калып буламы?

Әлеге диагноз белән авырга калу – җитди сигнал. Әлбәттә, күп нәрсә дисплазиянең аналык муентыгын ни дәрәҗәдә бозуына һәм аның төренә – яссы яки цилиндрик эпителийның зарарлануына бәйле. Биредә хатын-кызның яше дә мөһим роль уйный. Мондый диагнозлы хатын-кыз баштан ук белеп торырга тиеш: йөккә калу җиңел булмас. Дәвалану еллар буена сузылырга мөмкин. Җиңел дәрәҗәдәге дисплазия белән балага узарга була әле. Ә ул инде авыр төс алса, аны йөккә узганчы ук дәваларга кирәк.

Әгәр дә бу чир көмәнле булгач баш калкытса, нишләргә? Дулкынланмагыз! Мондый хәлдә ул үзен сиздерми, чир азмый, авырга узган хатын-кызның хәле дә аңа карап начарайный. Дөрес, кайчак бала вакытыннан алда дөньяга килергә мөмкин. Йөкле хатын-кызларның 75 процентында «күзәнәкләр патологиясе», ягъни азмы-күпме үзгәрешләр болай да булыр анысы. Ә менә йөкле хатын-кызларның нибары 3 процентында гына дисплазия күзәтелә. Йөккә узганда аналык муентыгын дәваламыйлар. Бары кольпоскопия һәм цитология гына үткәрелә. Биопсияне ахыр чиктә генә, аналык муентыгында яман чир билгеләре күзгә ташланып торганда гына алалар.

Ә инде яман чир авырга узгач кына билгеле булса, биредә, һичшиксез, онкогинекологның ярдәме кирәк булачак.



ПРОФИЛАКТИКА ОНКОЛОГИЧЕСКИХ ЗАБОЛЕВАНИЙ

РЕКЛАМА

- Высококвалифицированная консультация онкодерматолога.
- Удаление родинок, папиллом, бородавок.
- **Ведущие профильные специалисты:**
- Маммолог ● Уролог-онколог, уролог ● Гинеколог, гинеколог-онколог ● Проктолог ● Эндокринолог-онколог ● Хирург-онколог ● ЛОР-онколог, ЛОР ● Невролог ● Терапевт ● Пластический хирург.
- **Кабинет УЗИ экспертного класса.**
- **Лаборатория.**
- **Лечение эрозии шейки матки радиоволновым методом и методом криодеструкции.**

Казань, Сибирский тракт, 23; тел.: 8(843) 273-95-03.

Часы приема: пн.-пт. с 8.00 до 20.00; суббота: с 9.00 до 18.00; воскресенье – выходной.

Лицензия № ЛО-16-01-003675 от 16.09.201

ВНИМАНИЕ! АКЦИЯ!
СКИДКИ НА УСЛУГИ ГИНЕКОЛОГИИ ДО 27%

Консультация гинеколога+кольпоскопия+мазок на степень чистоты и онкоцитологию – 1150 руб. (скидка 350 руб.);
Консультация гинеколога+УЗИ органов малого таза+кольпоскопия+мазок на степень чистоты и онкоцитологию – 1540 руб. (скидка 560 руб.)

* Акция действует до 20.09.2016. Подробности на сайте: **www.oncoprofi.ru**

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТОВ

PRESSA.RU

Иллә дә рәхәт чор инде бу җәй айлары. Җиләк-җимеше дә, яшелчәсе дә мулдан. Шушы муллыктан тиешенчә файдаланып калыйк әле: түтәлдән генә өзеп алган помидорлардан искиткеч тәмле аш пешерик. Күпме сыйлансаң да туйдырмый торган бу тәмле ашны пешерергә безне Ләйлә ГАФФАРОВА өйрәтәчәк. Төркиядән өйрәнеп кайткан рецепты ул аның. Файдалы һәм ләззәтле булуы өстенә – буйсынга зыян китерми бу аш.





ТАНСЫККА – ТОМАТ АШЫ







Кирәк:

(4-6 кешелек гаилә өчен)

- 1,5-2 кг чамасы кызыл помидор;
- 3-4 баш уртача зурлыктагы суган;
- 1 уртача сарымсак төше;
- 2 л шулпа (тавыкныкы да, сыер итеннән пешкәне дә ярый);
- петрушка яфраклары;
- каты сыр (100-150 г тирәсе);
- тәменчә тоз-борыч, рәйхан (базилик);
- томат пастасы;
- 1 аш кашыгы чамасы он;
- кипкән ипи шакмаклары (сохари).

Эш барышы:

■ суганны турап, үсемлек маенда кыздырабыз.

■ Помидорларны юып, 3-4 минутка кайнар суга салып торабыз. Судан алып, суытабыз. Аннары кабыгын салдырып, эре генә итеп турыйбыз да, суган янына табага салабыз.

■ Табаны капкач белән каплап, ярты сәгать сүрән утта пешергәннән соң, 1 стакан шулпа, томат пастасы, борыч, рәйхан һәм изелгән сарымсак өстибез. Барысын бергә яхшылап болгатабыз.

■ Ашны бераз куертып җибәрү өчен, помидор өстенә 1 аш кашыгы он сибәбез. Төерләнмәсен өчен, тиз генә болгатабыз. Табаны уттан алып, бераз суынганын көтәбез.

■ Помидорлар суынгач, барысын





да зуррак кәстрүлгә салып, куе боламык кебек булганчы блендер белән тураклатабыз. Әгәр дә блендерыгызның әйләндерергә көче җитсә, калган шулпаны да шунда салсаң була.

■ Безнең блендер зур түгел, шуңа күрә шулпаны соңыннан гына салып, кәстрүлне ут өстенә куябыз. Ашка түменчә тоз салабыз. Помидорлар әчерәк булса, бераз гына шикәр комы да кушарга була. Кайнап чыгып, 2-3 минут узуга, кәстрүлне уттан алабыз.

■ Табынга биргәндә ашны тәлинкәләргә бүлеп, өстенә уылган сыр һәм ваклап туралган петрушка сибәбез.

■ Икмәк шакмакларын исә аш янына аерым савыт белән куябыз. Теләгән кеше аны ашка аз-азлап кына салып ашый. (Ипи киптерү серен журналыбызның 2013 елгы октябрь санында бер язган идек. Сез аны сайтыбыздан да таба аласыз.)

■ Ашларыгыз тәмле булсын!

БӨТНЕКТӘН ӘЗЕРЛИБЕЗ





КАЙНАТМА

Бик тәмле, күңелләрне күтәреп, кәефләрне ачып җибәрә торган кайнатма рецепты өйрәтик әле үзегезгә. Ясап карагыз, һич тә үкенмәссез.

Кирәк:

- 250 г бөтнек (мята перечная) сабаклары һәм яфраклары;
- 1 лимон;
- 300 г шикәр комы;
- 0,5 л су.

Эш барышы:

бөтнекне юып, вак итеп турыйбыз. Лимонны да вакларга кирәк булыр. Барысын бергә кәстрүлгә салып, өстеннән 0,5 л су коябыз. Кайнатып чыгарып, уттан алабыз да, бер тәүлеккә суыткычка куябыз. Икенче көнне, суын сөзеп, шуңа шикәр комы кушабыз һәм янә утка куеп, кайнатып чыгарабыз. Пыяла банкаларга кайнар килеш агызып, калай капкач белән томалыйбыз.

ЛИМОНАД

Җәй көне балаларны сыйлау, үзегез дә сыйлану өчен менә бу эчемлекне әзерли аласыз. Сусауны да шәп баса, витаминнары да үзендә.

Кирәк:

- 6-8 лимон;
- 6-8 стакан чишмә суы;
- 1-1,5 стакан шикәр комы.

Эш барышы:

лимонны әйбәтләп юып, сутын сыгабыз. Кувшинга лимон суты, чиста су һәм шикәр комын салып, шикәре эреп беткәнче яхшылап болгатабыз. Күңеле ачыракны теләүчеләр лимон сутын күбрәк, шикәрен азрак куша ала, баллы яратучылар исә, киресенчә. Шушы ук эчемлекне бөтнек һәм лимон кабыгы кушып та ясарга була. Аның өчен: кайнап торган суга шикәр, бер уч бөтнек, һәм ваклап туралган лимон кабыгы салып, шикәр эреп беткәнче 1-2 минут кайнатабыз да, уттан алып, ярты сәгать төнәтәбез. Суынгач, сөзеп, лимон суты һәм чиста су өстибез.

ХУШ ИСЛЕ БОЗ

Боз катыра торган контейнерның һәр шакмагына икешәр кура җиләге һәм бөтнек яфрагы салып, чишмә суы (фильтр аша чыгарылганы да ярый) агызабыз да, туңдырырга куябыз. Кыш көне шуны җиләкле-бөтнекле боз шакмагын салып чәй эчәрбез. Хуш исле булуы өстенә, кайнар чәйне суытыр өчен дә менә диген ул.

PRESSA.RU

Алия – Арча педагогика көллиятендә укучы студентларны рәсем ясау серләренә өйрәтә. Карап торышка үзе дә студент кызлардан әллә ни аерылмаган яшь ханым ире Илдар белән өч бала үстерә икән. Бик кызыксынучан, һәртөрле яңалыкка ачык ул Алия. Арчада төрле мастер-класслар оештыра, үзе белгәннәрне башкалар белән дә уртаклаша. Бүген ул безне сәяхәт китабы ясарга өйрәтәчәк. Җәйнең иң күңелле мизгелләрен хәтерләткән матур фотоларны, сәяхәткә ачкыч булган билетларны, гомумән, сәяхәткә бәйле һәртөрле истәлекне саклый торган бик кадерле китап булачак ул. Җәйге ялыгызны искә төшереп, балаларыгыз белән бергә сез дә ясый аласыз аны.



Мастер-классны Алия ФАЗДАЛОВА үткәрә.



СӘЯХӘТ КИТАБЫ



Кирәк:

• тышлык ясау өчен бөгәрләнми торган нык һәм каты катыргы. Ул ике кисәк кирәк. Үлчәме: 17x21 см;
• тышлыкка ябыштыру өчен ике табак бертөсле скрап-кәгазь. Үлчәме: 21x25 см;
• китапның форзацын ябыштыру һәм эчтәге битләрен ясау өчен: 16,5x20,5 үлчәмле юка катыргы кәгазь (крафт кәгазь), шул ук зурлыкта киселгән дәфтәр битләре (без исә әзер блок-битләр кулландык), үтә күренмәле папка (папка-уголок), ике конверт кирәк. Конвертның әзерен генә сатып алырга да була, скрап кәгазьдән үзеңә ясарга да мөмкин. Ничек ясарга икәнлеге хакында соңрак сүз булыр;
• алгы һәм арткы форзацка кесә итеп ябыштыру өчен ике төрле скрап кәгазь;
• «Момент» җилеме (үтә күренмәлесе), ПВА җилеме, кайнар җилем;
• кәгазьне тишү өчен махсус җайланма (дырокол). Ул булмаса, без белән дә тишәргә мөмкин;
• 1 м чамасы сүс бау (бечевка) һәм шундый ук озынлыктагы җитен тасма (киңлеге 2,5 см. Тегү кирәк-яраклары кибетендә сатыла);
• кәгазь кисү өчен махсус пычак; калай линейка;
• өстәл өслеген бозмас өчен макет келәме яки теләсә нинди берәр такта.

Бизәү өчен:

(Ирекле эш. Һәркем үз китабын үзенчә бизи ала.)

• Безнең очракта исә – диңгез дулкыннары, кораб, якорь сурәтләре төшкән скрап кәгазь кисәкләре;
• диңгез кабырчыклары;
• бака кашыклары;
• диңгез стилендәге матур сәдәфләр;
• кечкенә генә челтәр кисәге;
• журналлардан кисеп алган матур рәсемнәр (алар безгә кирәкле теманы чагылдырырга тиеш);
• битләр арасына рәсемнәр беркетү өчен зур кыстыргыч (скрепка);
• 10 см озынлыгындагы кызыл һәм зәңгәр төстәге репс тасма кисәкләре; зәңгәрсу төстәге кәгазьдән кисеп алган түгәрәк;
• бәләкәй якорь яки штурвалише диңгез атрибутикасы;
• бизәкне күләмле итү өчен кәгазь араларына ябыштырырга калынрак катыргы кисәге.



Эш барышы:

■ Тышлык өчен киселгән катыргыларга «Момент» җилеме белән скрап кәгазь ябыштырабыз. Аның читләре катыргыдан икешәр сантиметр чыгып кала.

■ Аларны бөкләгәнче, язмый торган каләм, ыргак яки бәйләм энәсе кебек очлы әйбер белән сызып, бөкләм эзен төшерәбез. Почмакларын исә кыйгачлап кыеп алабыз.

■ Кәгазьнең дүрт читен дә бөкләп, катыргыга ПВА җилеме белән ябыштырабыз. Ябыштыруның да үз тәртибе бар: башта аскы һәм өске як, аннары ике кыры ябыштырыла. Тагын бер мөһим әйбер: почмаклар тип-тигез булсын өчен, почмактагы кәгазьне берәр очлы әйбер белән сыпырып, яссыландырабыз.

■ Тышлыкның ике форзацына да скрап кәгазьдән киселгән кисәләр ябыштырыла. Алгы кисә 19,5x11 см үлчәмендәге кәгазьдән гыйбарәт. Аның ике читеннән һәм аскы ягыннан 1,5 см эчкә кереп, бөкләм эзе ясыйбыз. Кисәне әлеге «колаклар»ыннан «Момент» җилеме белән форзацка ябыштырабыз. Өске ягында исә ярымтүгәрәк уем ясыйбыз. Арткы форзацның кисәсе вертикаль ябыштырыла. Анысының үлчәме 11x23,5 см (*бишенче рәсем).*

■ Ике төрле скрап кәгазьдән конвертлар ясыйбыз. Аларның зуррагы 28,5x28,5 см үлчәмле шакмакны бөгеп ясала *(алтынчы рәсем).*

■ Икенчесе өчен скрап кәгазьдән 23x30 см зурлыгындагы турыпочмаклык кисәбез. Озын ягыннан эчкә таба 1,5 см кереп, бөкләм эзе ясыйбыз. Кыска ягыннан аска таба 5 см һәм 14 см үлчәп, ике эз сызабыз. Шушы эзләрдән конвертны бөклибез. Кайчы алып, конвертның ике читендәге бөкләм эзе буйлап, өске яктан 19 см араны кисәбез. Киселми калганы ябыштыру өчен «колаклар» була. Конвертны «Момент» җилеме белән ябыштырабыз.

■ 2,5 см киңлегендәге җитен тасманы урталай кисеп, китабыбызның алгы һәм арткы тышлыгына ябыштырып куябыз. Тигезлегенә һәм дөреслегенә игътибар итегез. Алгы якта тасма ябыштырылган урын бизәк астында калачак. Арткы якны исә без диңгез дулкыны төсендәге скрап кәгазь һәм якорь белән капладык (*сигезенче рәсем).*

■ Алгы тышлыкны фантазиябезгә таянып бизибез. Ниндидер мөһим кагыйдәсе юк. Сайлаган бизәкләрегез темага ярашлы булсын. Бизәк күләмле булсын өчен, кәгазь араларына кечерәк кенә калын катыргы ябыштырып калдырабыз. Алар күре-

PRESSA.RU







неп тормаска тиеш. Бака кашыклары, диңгез кабырчыклары, тукыма кисәге, җитен сүсе, сәдәфләр – бар да эшкә ярый.

■ Кәгазь тишкеч белән һәр ике тышлыкка да икешәр тишек тишәбез. Игътибарлы булыгыз, тишекләр бер-берсенә туры килерлек булсын. Аннары эчке якка дип әзерләгән катыргы, дәфтәр битләре, үтә күренмәле папка, конвертларны тигезләп куеп, тышлыкларны тишкән эздән аларны да тишәбез.

■ 1 м озынлыгындагы сүс бауны урталай кисеп, аның берсен – өстәге тишек аша, икенчесен астагы тишек аша уздырабыз. Икешәр тапкыр урагач, бау очын күбәләкләп бәйләп куябыз. Өстәге бауга, матурлык өчен, без әле бәләкәй штурвал да бәйләп куйдык.

■ Соңгы эш итеп скрепкаларны бизибез. Аларның икесенә репс тасма тактык. Моның өчен 10 см озынлыгындагы тасманы скрепкага тагып, урталай бөклибез дә ике «койрыгын» «Момент» җилеме белән ябыштырабыз. Калган скрепкаларга кайнар җилем белән диңгез кабырчыгы, матур сәдәфләр ябыштырабыз. Кайнар җилем булмаса, «Момент» белән дә ябыштыра аласыз.

■ Инде мастер-классның иң рәхәт, иң кызыклы мизгеленә якынлаштык – китап эченә кадерле истәлекләребезне тутырабыз. Беренче кесәгә юл билетларын салып куйыйк. Конвертларга – фотоларны. Ә иң-иң истәлеклесен скрепкалар белән битләр арасына да кыстырып куярга була.

■ Мондый китапларны Алия сәяхәт форсатыннан гына түгел, яшьлек туе, бәби туу сөенече, юбилей хөрмәте, туган көн бүләге итеп тә ясый. Кызыксынсагыз, аңа заказ бирә аласыз.

КИҢӘШ

■ Скрапбукингта билгеле бертөсле генә катыргы яки фәкать скрап кәгазь кулланасы дигән катгый таләп юк. Китап битләрен катыргыдан түгел, ә акварель кәгазеннән дә ясарга була. Әмма кәгазь сайлаганда бер нәрсәгә игътибар итегез: аның составында лигнин дигән матдә һәм кәгазь җепселләрен ныгыта торган кислоталар булмасын. Югыйсә хезмәтегез ярты елдан ук саргаеп, яме югалачак. Китап тышлыгын да матур тукыма белән тышлап, йомшак итеп ясарга була.

■ Скрапбукинг өйдәге барлык фотоларны бергә тутырып кую өчен ясалмый. Ул нинди дә булса берәр вакыйга уңаеннан ясала, һәм аның эченә шушы вакыйгага кагылыш булган истәлекләр туплана.

■ Альбомның битләрен җыйганда, бауны бушрак итеп бәйләгез (тимер боҗрага җыярга уйласагыз, шулай ук боҗраның бик кечкенәләрен алмагыз). Битләр җиңел генә ачылырлык булсын. Аннары, фотоларны тутырганнан соң, китапның шактый калынаячагын да истән чыгармагыз!

■ Бер биткә бик күп фото куймаска тырышырга кирәк. Алай иткәндә, күз йөгереп, фотоларның берсенә дә юньләп игътибар ителми. Бер үк темага багышланган фотоларның барысын да бер биткә куярга теләсәгез, иң матурын алга чыгарып, калганнарын аның артына резинка белән кыстырып куярга була. Ул биткә кесә ябыштырсагыз, анда да салып куя аласыз.

■ Китап кызыклы һәм мавыктыргыч килеп чыксын өчен, фото кырыена аны төшерү тарихын һәм башка кызыклы мәгълүматларны өстәгез. Еллар үткән саен, алар хәтердән дә чыгып китәргә мөмкин бит. Мәсәлән, сез балагызга багышланган альбом төзисез, ди. Аның ике генә тешен җемелдәтеп төшкән фотосы кырыена, бу энҗе бөртекләренең кайчан күренүен, кем күрүен язып куя аласыз. Ә шул ук биттәге кесәдә аларны сакларга да була әле.

■ Фотолар белән бергә, бу китап тормышыгызның шул күңелле мизгеле шаһиты булган башка хатирәләрне саклый ала. Мәсәлән, сәяхәттән алып кайткан вак-төяк, кунакханә истәлеге булып калган беләзек, шул вакытта алган буклетлар, кесә төбендә калган вак акча...

■ Беренче генә китабын ясаучыларның иң төп хатасы – китап битләрен артык чуарлау. Болай да чуар фотоны аллы-гөлле кәгазьдән ясалган биткә беркетү хата. Битне ачып җибәргән кешенең карашы шунда ук фотога яки башка мөһим мәгълүматка текәлергә тиеш. Максатыбыз – детальләрнең бер-берсен тулыландыруына ирешү.


Кучкар. Катлаулы һәм мәшәкатьле ай булса да, аны начар дип әйтеп булмый. Алдыгызда яңа перспективалар ачылырга тора, аларга игътибар итегез. Айның икенче яртысы эш өчен дә, гаилә тормышы өчен дә уңышлы булачак.


Үгезбозау. Эшнең күп булуы ачуыгызны китерергә мөмкин. Өстәвенә, элек ашык-пошык башкарган эшләрдә хаталар табылып, аларны да төзәтергә туры килмәгәе. Кыскасы, сабырлык һәм көч-куәт сезгә!


Игезәкләр. Төп урында өй һәм гаилә, башкалары көтеп тә торыр. Гаилә мөнәсәбәтләрен ныклап анализларга һәм кирәксә, җайлап җибәрергә туры килүе ихтимал. Эшкә килгәндә исә, бу айда тиз уңышка өметләнәсе юк.


Кысла. Хәрәкәт һәм үзгәрешләр ае бу. Ә аларның уңышлымы, түгелме икәне, фәкать сездән генә тора. Тирә-юньдәгеләр белән сак булыгыз, юктан гына башланган сүзнең ызгышка әверелүе ихтимал.


Арыслан. Беренче урынга акча мәсьәләсе калкып чыгар. Зур әйберләр сатып алудан, кредиттан, шикле килешүләр төзүдән тыелыгыз. Иҗат эше белән шөгыльләнүчеләргә уңыш елмаячак, табыш алу мөмкинлеге дә туачак.


Сөмбелә. Уңышлы, әмма ыгы-зыгылы ай. Эшегез болай да күп, аның өстенә гаиләдә дә мөнәсәбәтләрнең катлауланып китүе ихтимал. Ял алып, өйгә ремонт ясату яки документларны тәртипкә китерү өчен яхшы вакыт.


Бизмән. Уңышлы ай. Эштәге күңелле үзгәрешләр, кызыклы вакыйгалар белән үтәчәк ул. Болар бар да нәкъ сезнең йолдызлык аша узучы Юпитер планетасы тәэсире. Нәрсәгә генә алынсагыз да, ахыры яхшы тәмамланачак.


Чаян. Катлаулы эшләргә алынмый торыгыз. Уйларда, хисләрдә, мөнәсәбәтләрдә тәртип булдырыр өчен яхшы вакыт. Күптән күрешмәгән танышыгызны очратырсыз. Элеккеге мөнәсәбәтләрнең кабат ялганып китүе ихтимал.


Укчы. Таулар күчерерлек көч тоярсыз. Алга куйган максатларыгызны яңадан барлып чыгарга туры килер. Гел башкалар хакында гына кайгыртып, үзегезне икенче урынга калдырмагыз, бераз үҗәтлек күрсәтсәгез дә начар булмас.


Кәҗәмөгез. Уңышка ирешү вак-төяк нәрсәләргә бәйле булачак. Шуңа күрә ашыкмагыз, һәрнәрсәне уйлап эшләгез. Ай башында бернинди дә мөһим карар кабул итмәгез. Артык ашыгыч булмаган эшләрне дә киләсе айга калдырсагыз хәерле.


Сукояр. Тирә-юньдәгеләр белән бәхәс килеп чыгарга мөмкин. Дөреслегегезгә башкаларны да инандыра алырсыз. Әлегә зур эшләр башлаудан тыелып торыгыз. Шулай ук әҗәткә акча бирү яки алу өчен кулай вакыт түгел.


Балык. Эшегез бер нәрсәне таләп итә, күңелегезгә икенчесе хуш килә – шулар арасында бәргәләнерсез. Кыенлыклар акрынлап артка чигенәчәк. Көтелмәгән күңелле вакыйгалар шаһиты булуыгыз ихтимал. Күптәнге хыялыгызның тормышка ашуы мөмкин.

августта кабынган йолдызлар

Татарстан



Дания Нуруллина (23.08.1946) – **Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты.**

Кечкенәдән бию түгәрәгенә йөрсә дә, медик булырга хыяллана. Ләкин укытучысы – элеккеге балерина З. Чаришина аңа театр училищесына керергә киңәш итә. Икенче курста укыганда ук аны Камал театрына – «Ай тотылган төндә» (М. Кәрим) спектаклендә Шәфәкъ ролен уйнарга чакыралар. Янып торган күзләр, ташып торган темперамент – Дания Нуруллинаны тамашачы бер күрүдән әнә шулай истә калдыра. Камал театрына ул 1966 елда килә. Шул ук елны аңа «Миркәй белән Айсылу»да (Н. Исәнбәт) Айсылу ролен бирәләр. Бүген дә сәхнәдә –«Үлеп яратты» (Р. Зәйдулла), «Сөясеңме, сөймисеңме?» (Ф. Бүләков) һ.б. спектакльләрдә уйный.

Россия



Фаина Раневская (27.08.1896–19.07.1984) – **СССРның халык артисты**

«XX гасырдагы бөек рус артистларының берсе», «Икенче план патшабикәсе», аның турында еш кына шулай диләр. Тамашачылар һәм режиссерлар Раневскаяны беренче тапкыр «Пышка» драмасында Луазо ханым ролендә күрә. Үз гомерендә кинода утызлап роль башкарса да, гомере буе театрга тугры кала. Актерлык эшчәнлеген төрле шәһәр театрларында башлаган артистка чирек гасырга якын Моссовет исемендәге театр сәхнәсендә уйный (1949–1955, 1963–1984), өч тапкыр Сталин премиясенә лаек була. Туган шәһәре Таганрогта аның исемендә урам бар, ул туган йортка элмә такта беркетелгән.

Чит илләр



Хэлли Берри (14.08.1966) – **кино артисты.**

АКШның Кливленд шәһәрендә туган кыз мәктәптә укыганда ук төрле чараларда катнаша. 1986 елгы матурлык конкурсында «АКШ гүзәле» исемен ала. Шул ук елны «Дөнья гүзәле» конкурсында катнашып, алтынчы урынга чыга. Моңарчы кара тәнле бер генә кызның да анда катнашканы булмый. Кино сәнгате белән дә шушы елларда шөгыльләнә башлый. Спайк Ли төшергән «Тропиклар бизгәге» фильмында башкарган роле аңа азмы-күпме танылу китерә. Ә инде «Монстрлар балы» фильмында уйнаган роле өчен 2002 елда «Оскар»лы була. Кино тарихында төп рольне башкарган өчен кара тәнле актрисага бирелгән беренче «Оскар» бу. Иң күп гонорарга эшләүче актрисаларның берсе ул бүген.

PRESSA.RU





КАНАТЛЫ РӘССАМ

Ай йөзле бу кызны мин ерактан ук абайладым. Ул да минем уңышлы кадрлар эзләп, фотога төшереп йөрүемне кызыксынып күзәтте. Инде объективны үзенә төбәгәч, сөйләшеп тә киттек. «Мәрьям Садердинова булам мин. Мәскәү Рәссамнар берлеге әгъзасымын. Әтием белән җырчы якташларыбызга һәйкәл ачу тантанасына кайттык. Минем әтием шушы төбәктә – Петрякс авылында туып-үскән. Мәскәү авиация институтын тәмамлаган». Рәссам-график икән Мәрьям. Китапларга иллюстрацияләр ясау белән мәшгуль. Әмма аның майлы буяу белән эшләнгән сюжетлы картиналары да байтак.

Бу яшь кенә күренгән туташның инде үзенең башка рәссамнар өчен остаз булуын белгәч, соклануым тагын да арта төште. Югыйсә аның бар булмышында чагылган тыйнаклыгы бу инсафлы татар кызын өй мохитеннән бер дә читкә җибәрмидер кебек тоелган иде. Ул, әнә, В. И. Суриков исемендәге Мәскәү дәүләт академия сәнгать институтын тәмамларга да, Россия Рәссамнар берлегенең дипломанты булырга да, Англиядә, Франциядә, Иранда, Словакиядә төрле елларда үткәрелгән конкурсларда лауреат исемен алырга да өлгергән.


Ул бизәгән китаплар арасында Шекспир трагедияләре җыентыгы, Ф. Рабленың «Гаргантюа һәм Пантагрюэль» романы, А. Пушкинның «Борис Годунов» әсәре аерым бер урын алып тора. Күрәсең, китап бизәү эшенә Россиянең халык рәссамы, профессор В. Пановтан өйрәнү, Россиянең халык рәссамы, профессор Ю. Иванов янында стажировка узулар эзсез калмагандыр.

Татар укучысы Мәрьям Садердинованың Мәрҗани китап йорты чыгарган татар әкиятләре җыентыгына ясаган эшләрен аеруча хуп күрә. «Өч күгәрчен» әкияте аның үзенә дә кечкенәдән таныш. Кайсы татар баласы әкият тыңламыйча гына йокларга ятсын инде! Ул әкиятләрдә канатлы атлар да, батыр егетләрне очыртып кына алып китә торган Сәмруг кошлар да бар. Әнә шул канатлы очышлар турында хыяллану әтисен авиация институтына юнәлткән булса, кызны канатлы иҗатка алып килгән. Чыннан да, татар һәм кырымтатар әкиятләренә ясалган иллюстрацияләрдәге егетләр, грек әкиятләрендәге Икар кебек, күккә талпынып очалар. Һәр әкияттәге кебек, аның рәсемнәрендә дә урманнар кап-кара, күлләр сер тулы, аждаһалар явыз. Әмма барысында да яхшылык җиңеп чыга.


Татар әкиятләрендәге кебек, рәссам Мәрьямнең дә иҗат юлы җиңүле. Ул инде 2001 елдан бирле Мәскәү, Бөтенроссия, чит илләрдәге күргәзмәләрдә катнашып килә. 2012, 2013, 2015 елларда аның үзенең персональ күргәзмәләре дә булган. Исем булгач, иҗатына ихтыяҗ да бар. Мәрьям Садердиновага акварель, гуашь, темпера, акрил, тушь белән язылган эшләргә заказлар килеп кенә тора.


Аның хезмәтләре Россиянең һәм дөньяның төрле коллекцияләрендә урын алган. Алар хәтта Бөекбритания королевасы Елизаветаның шәхси фондында да бар. Франция, Словакия, Америка сәнгатьсөярләре – җәмгысы 11 шәхси коллекция үзләрендә Мәрьям Садердинова әсәрләрен булдырган.

Асия ЮНЫСОВА











МӘРЬЯМ САДЕРДИНОВА

PRESSA.RU

ИГЪТИБАР!
«Сөембикә» журналының индексы үзгәрде



«Почта России»ның «Подписные издания» (ПАП) рәсми каталогы буенча ЖУРНАЛЫБЫЗНЫҢ ЯҢА ИНДЕКСЫ П2204



Татарстаннан читтә яшәүчеләр әлегә «Роспечать» каталогындагы элеккеге индекс буенча языла алалар: 73002

1 ИЮЛЬДӘН 2017 ЕЛНЫҢ БЕРЕНЧЕ ЯРТЫЕЛЛЫГЫНА ЯЗЫЛУ БАШЛАНДЫ. БҮГЕНГЕ БӘЯДӘН ЯЗЫЛЫП ӨЛГЕРЕГЕЗ!

Журналыбызга онлайн режимда : http://podpiska.pochta.ru сайтында (регистрация узып) яки безнең сайтыбызның онлайн язылу бүлегендә дә язылырга мөмкин



Электрон версиягә язылган очракта, яңа санны компьютерда, планшетларда, барлык мобиль җайланмаларда PDF форматта укырга була. iPad һәм iPhone кулланучылар «Сөембикә» журналының электрон версиясен App Storeдагы «Pressa.ru» киоскына кереп, хатын-кызлар өчен журналлар арасыннан таба ала.

Электрон версиягә язылу турында тулырак мәгълүматны «Сөембикә» журналының сайтында «Язылу» бүлегендә табып була (www.syuyumbike.ru).

16+